# Казан утлары

ФЕВРАЛЬ 1966

№ 2

*Журналыбызның бу саны
герой шагыйрь **Муса Җәлилнең**
туына 60 ел тулуга багышлана.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*КЫРЫК БИШЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

**2**

**ФЕВРАЛЬ**

**1966**


## Бу санда:


МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

П. Хузангай. **Син урнаштың дөнья күкрәгенә.** Шигырь . . . 3
М. Дудин. Мәңгелек җыр. Шигырь . . . 4
С. Баттал. **Син — политрук.** Шигырь . . . 5
Х. Туфан. **Европа өстендә Җәлил тавышы.** Шигырь . . . 6
Х. Камалов. **Синең язмышың.** Шигырь . . . 7
Г. Латыйп. **Ромашкалар.** Шигырь . . . 8
М. Җәлил турында совет язучылары . . . 9
Н. Юзиев. **А. Фадеев һәм Җәлил.** Мәкалә . . . 13
Г. Кашшаф. Аның шигырьләреме? Мәкалә . . . 17
Р. Мостафин. **Талант һәм хезмәт.** Мәкалә . . . 28

ПОВЕСТЬ ҺӘМ ШИГЫРЬЛӘР

Г. Хуҗиев. **Кайбыч урманнарын сагынып; Фәридә Кудашеваны тыңлагач; Җитенкәй; Кошлар китә җылы якларга; Үз юлы бар һәрбер чишмәнең; Күзләр җитсә.** Шигырьләр . . . 36
З. Нури. **Кичке күренешләр.** Шигырьләр . . . 38
Г. Гобәй. **Корьян серләре.** Повесть . . . 40
Редакция сорауларына язучыларның җаваплары . . . 41—47

М. ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Б. Бикбай. **Күңел аша үткән яктылык** . . . 98
Х. Максуд. **Иптәш, дус һәм туган** . . . 99
Х. Салихов. **Якташым** . . . 102
С. Алишев. **Көрәштәшләр** . . . 103



КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

И. Дәүләтшин. Идел өстендә таң. Очерк . . . . . 104

## ЯЗУЧЫ БЛОКНОТЫННАН

С. Сөләйманова. Легендар Ленинградта татар язучылары . . . . . 117

## М. ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Ф. Исхаков. Аны комсомол тәрбияләде . . . . . 125
Р. Таһиров. «Алман илендә» шигыре турында кайбер фикерләр . . . . . 132
Ә. Кәримуллин. Шагыйрь турында чит ил матбугаты . . . . . 135
Г. Ахунов. Химкида җәлилчеләр . . . . . 142

## САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Ш. Галиев. Сөзгәк үгез мажаралары. Поэма . . . . . 144

## УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

Хатлардан юллар . . . . . 154
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . 156

*Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Муса Җәлилнең тууына 60 ел

*Педер Хузангай*

# Син урнаштың дөнья күкрәгенә

Кайдан алды егет мондый көчне,
Кайдан алды мондый ялкынны?

*М. Җәлил—«Егет көче».*

**Мондый көчне болай кайдан алдың?**
**Кадерлем, син һаман хәтеремдә!**
**Татарстанны, Россияны, димәк,**
**Вөҗданың күк йөрткәнсең бергә.**

**Актык көндә исеңә төште Павло *,**
**Йөрәгеңдә, димәк, яшәгән**
**Украина иле, —**
**Бөек дуслык белән коткарылган**
**Газаплардан, уттан, дәһшәттән.**

**Кайгыдан чал кергән Павло күрде:**
**Төз атладык дошман явына.**
**Аның йөрәк тавышы ишетелде**
**Набат булып Урал ягыннан.**

**Кырып, мыскыл итеп халыкларны,**
**Европада дошман йөргәндә,**
**Башкортны дус иткән украинлы,**
**Ана телен аның өйрәнгән.**

**Белми киттең, Муса, славяннар**
**Улы, оныгы, нәселе Павлоның**
**«Батьківщина» дигән сүз артыннан**
**Башкортчалап**
**«Ватан» дигән сүзне язганын.**

**Бу сүз шулай синең телеңдә дә,**
**Аннан олы сүз юк дөньяда:**
**Ватан-ана! Улы булып әнә**
**Шагыйрь антлар иткән бит аңа.**

* Павло Тычина — украин шагыйре. М. Җәлил соңгы васыятендә аның исемен телгә ала.

Син сугышчы каны тамган гөлне —
Ромашканы иҗат иткәндә,
Яңа Болгария шагыйренең
Саркылгандыр каны идәнгә.

Әйе, Вапцаров ул җәй аенда,
Кырык икенче елда атылган,
Синең кебек чын коммунист булган, —
Баш тартмыйча үлгән антыннан.

Дәртле шагыйрь кайнар, саф күңелдән
Дулкынланып үлем алдында,
Үлемсезлек эшенә ышаныч белән,
Сигез юл җыр язып калдырган.

Бер-берегезне бер дә белми торып
Йөрәкләрегез бергә типкәннәр,
Шигъри көчләр янар таулар булып
Үлемгәчә сезне илткәннәр.

Трубадурлар, бардлар һәм скальдлар—
Сезнең белән иде барысы да:
Сезнең күңелләрдә Бухенвальдлар
Көлгә очты үлем каршында...

Егерменче гасыр шагыйрьләре
Без давылда, дауда яшьнәдек,
Халыкара дуслык, туганлыкка —
Зур максатка ышанып яшәдек.

Безнең белән бергә яңа җырлар
Солдат булып барды зур яуга.
Пышылдады безгә соңгы юллар
Нәфрәт сөйләп курку, каушауга.

Утка эверелделәр сүзләрең дә,
Очырып казематлар тузанын...
Син урнаштың дөнья күкрәгенә,
Әй кордашым, дустым, туганым!

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәсе.

*Михаил Дудин*

## Мәңгелек җыр

Изсәләр дә таптап шагыйрь җырын,
Атсалар да төбәп йөрәккә,
Ул җыр, илче булып, ирек нурын
Тузан аша илтә еракка.

Җыр югалмый, ул мәңгегә туган.
Юк азагы аның, юк башы.
Пушкинга да эстафета булган
Билгесез бер җырчы юлдашы.

Җаным өшеп китә үткәннәргә,
Хәтер төер булып буа бик:
Юксына күк аһ-зар Тукайларны,
Җәлилләрне шомлы Моабит.

Әнә палач баскан баш очына,
Зәһәрлесен ата ул укның.
Карга аккан каннан төтен чыга,
Ыңгыраша ташы Машукның.

Палач чаба Фучик-батыр ирне,
Җанын ала шагыйрь-Мусаның.
Шулай да җыр алга өнди җирне,
Канатыннан кагып тузанын.

Тәрҗемә дә кирәк түгел аңа,
Яшәү юлы ачык, нык аның:
Ул халык һәм синең язмышыңда,
Язмышында азат дөньяның!

МӨХӘММӘТ САДРИ тәрҗемәсе.

*Салих Баттал*

## Син—политрук

Безнең өчен һаман
Син — политрук.
Син тезәсең безне бер сафка,
шигъри казанышлар ранжирында
иң танылган ирләр — уң якка!

Бу юбилей түгел, — көчне туплау:
— Кайда Фатих Кәрим? — дисең син,—
кайда безнең батыр Демьян Фәтхи, —
уң флангта күрмим! — дисең син.

Тукай клубына үткән чакта
мәрмәр исемлектә кемнәр бар —
һәммәсе дә безнең ирек өчен
сугышып үлгән Байрон бит алар!

Син әйтәсең: тереләр дә бергә
бу почетлы безнең сафта, — дип, —
Әйдә, Баттал, син дә кыю атла,
Иҗат күген уяу сакла! — дип.

*Хәсән Туфан*

## Европа өстендә Җәлил тавышы

Арагызда кем бар Цеткин улы,
Тельман егетләре кайсыгыз?
*М. Җәлил.*

В последний раз — опомнись, старый мир!
*А. Блок. («Скифы»)*

Син беренче идең:
Син күтәргән идең беренче кат
Яшь давылның тәүге байрагын;
Пролетарның туган җире, Гареп
Һәм Маркснын — тәүге мәйданы
Син идең.

Син беренче идең... Люмпеннарың
Тәү набатны көткән кичләрдә,
Пролетарий кызлар мансардларда
Коммунага байрак чиккәндә
Син беренче идең...

Еракта син, Гареп, ул көннәрдән,
Еракта син хәзер,
Бер гасырлык ара артында:
Катып калган анахронизм син
Ирек алган азият каршында.

Кайда синең
Чартистларны биргән,
Маратларны биргән илләрең?
Кайда синең
Гильотиналарда
Король башын кискән ирләрең
Кайда инде?

Кем син хәзер, кем син?
Әйтерсең лә,
Яман улы — яхшы атаның:
Чуен корольләре кулы аша
Коммунарга хәнҗәр кададың...

Вәхшинең дә кулы бармый аңа —
Шигырь асу, шигырь суюга....
О бюргерлар! —
Поэзия каны,
Җәлил каны сезнең муенда!

Бу кан өчен нацист кына түгел,
Черчилең дә мәсьүл, көнбатыш...
Шулмы сезнең «без мәдәни» дигән,
«Без элита» дигән дөньягыз?

Гуман чорың кайда, Бонн һәм Лондон?
Юк, сез моны
«Аңламыйсыз»ла:
О, ни оят! — биш йөз депутатка —
Бер коммунист... парламентында!

Җәлил йөри, тере тавыш йөри
Җырны аскан илләр ягында,
Блок бара якын юлдаш сыман,
Блок бара Җәлил янында...

Россианлар исемен ишетү белән, —
Мәдәни дә гәрчә үзегез, —
Урта гасыр иезуиты йөзен
Хәтерләтә башлый төсегез.

«Татар» сүзе «тартарары» белән
Синоним дип йөргән бюргерлар,
Монахларыгыз язган сафсатага
Нигезләнгән сезнең бу «җыр»лар.

Кем коткарды сезне, кем коткарды
Көрән реванш динозаврыннан? —
Кызларыңның, толларыңның канын
Көрән елан имгән чагыннан,
Кем коткарды
Ярты Европаңны
Нацист итеге изгән чагыңнан,
Кем коткарды?

Җәлил килә, тере тавыш килә
Кара йөзле җәллад каршына.
Блок килә аның белән бергә,
Терәк булып хаклык тавышына.

*Хисам Камалов*

## Синең язмышың

Безнең язмыш күбрәк дус кулында
Коткарган да, батырган да шул!
Сатса да тик таныш-белеш сата,
Чит кеше бит безне белми ул.

Чын дусларың, Муса, бик кайгырган!
Кайберләре куркып калганнар...
Күңелдәге чыгарудан элек,
Семьяларын уйлап алганнар...

Андыйлардан син югары булдың.
Нинди хәлгә тик төшмәдең син?!
Язмыш атты тирән упкыннарга,
Ләкин бер дә бирешмәдең син!

Туган илне, дусларыңны җуеп,
Алга бардың кырып дошманны
Күз яшеңне кайчак йота-йота,
Уйладың син тугры дусларны.

Фашистларның йөзенә төкерә алдың.
Көрәш тынмас алар бетмичә.
Зур бәрелештә җиндең,
Илеңә дә,
Дустыңа да хыянәт итмичә!

*Галимҗан Латыйп*

## Ромашкалар

Ерак түгел моңаеп
Утыра ромашка кызы,
Тик чуклары ак түгел,
Кан шикелле кып-кызыл.

МУСА ҖӘЛИЛ.

Ромашкалар, ромашкалар,
Ничә тапкыр керде җырга.
Ромашкалар күңелләрдә,
Ромашкалар үсә кырда.

Ромашкалар ап-ак чуклы,
Ромашкалар кызыл чуклы.
Кызыл чуклы ромашкалар
Хәтерләтә янган утны.

Әйе, кызыл ромашкалар —
Әйтерсең, таң шәфәкъләре.
Тамган аңа Алиш каны,
Тамган аңа Муса каны.

Кырда үскән ромашкалар
Вакыт үткәч коелалар.
Кызыл чуклы ромашкалар
Мәңгелеккә җыеналар.

Беләсезме! Волхов шаһит —
Анда кызыл ромашкалар!
Кар астыннан чыга да ул
Күтәрелә яз башыннан:

Берәү, икәү, ун, егерме,
Йөз һәм миллион ромашкалар.
Бухенвальдта, Моабитта,
Шпандауда ромашкалар,

Ут шикелле тора янып,
Бирешми ул салкыннарга.
Кар өстендә чәчәк ата,
Янмый хәтта ялкыннарда.

Кызыл чуклы ромашкалар
Күчә шулай күңелләргә.
Исе китми кар-буранга,
Баш ими ул үлемнәргә.

Ромашкалар, ромашкалар,
Ничә тапкыр керде җырга.
Ромашкалар күңелләрдә,
Ромашкалар үсә кырда.

# ЖӘЛИЛ ТУРЫНДА СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ

*Татарстан дәүләт музее татар халкының бөек улы Муса Жәлил поэзиясен, аның героик тормышын өйрәнү, пропагандалау һәм материаллар туплау буенча бернична ел эчендә күп кенә эшләр башкарды. Шагыйрьнең алтмыш еллыгына зур күләмдә юбилей күргәзмәсе әзерләнде. Андагы экспонатлар Жәлилнең иҗат һәм тормыш юлы турында гына түгел, ә бәлки герой шагыйрьнең үлемсезлеге, безнең илдә, шулай ук чит илләрдә киң танылуы хакында да сөйли. Экспозициянең бер бүлеге «Жәлил турында совет язучылары» дип исемләнгән.*

*Узган ел җәй аенда без кайбер танылган язучыларга Жәлил һәм аның поэзиясе турында үзләренең фикерләрен язып җибәрүләрен сорап мөрәҗәгать иткән идек. Беренче хат, дөресрәге посылка (биш китап) казакъ шагыйре Жубан Мулдагалиевтән килеп төште. Ул безгә туган телендә, шулай ук татар, рус, үзбәк, таҗик телләрендә басылып чыккан «Жыр турында җыр» поэмасын җибәргән.*

*Шуннан соң хатлар илебезнең төрле почмакларыннан: Мәскәүдән һәм Тбилисидән, Ленинградтан һәм Бакудан, Киевтан һәм Ашхабадтан, Уфадан һәм Вильнюстан, шулай ук бүтән җирләрдән килә башлады. Ул хатлар шагыйрьнең гражданлык һәм поэтик батырлыгына тирән соклану һәм хөрмәт белән сугарылганнар, алардагы һәр юлда дулкынлану, мәхәббәт сизелеп тора.*

*Безнең үтенечебезгә шулай теләп җавап биргән, безгә Муса турындагы язмаларын, автографларын, үзләренең фоторәсемнәрен җибәргән язучыларга чын күңелдән рәхмәт әйтәбез.*

*С. ПИСАРЕВА,*
ТАССР дәүләт музееның өлкән фәнни сотруднигы.

●●●

*Мин үз гомеремдә Муса Жәлилне бер тапкыр да күрә алмадым, ләкин күз алдыма аны шул кадәр яхшы китерәм, әйтерсең, мин аның белән күптән һәм яхшы таныш. Аның шигырьләрен укып, мин, әйтерсең, аның халыкка һәм партиягә тугрылыклы йөрәге белән сөйләшәм. Ул үзенең шигырьләре белән хак эшкә куркусыз барган поэзиянең батырлык икәнен, горур һәм азат шигъри сүзне бернинди сынаулар да җиңә алмавын исбат итте.*

*Аның «Моабит дәфтәре» — кешенең рухи батырлыгына һәйкәл, бу шигырьләр киләчәк буыннарны да дулкынландырыр һәм аларда да аңа ошарга тырышу хисе тудырыр.*

*Әгәр артка борылып карасак, аның комсомолда узган яшьлегенә кайтсак, Жәлил шигырьләренең совет кешеләренең батыр хезмәтенә багышланган булуларын һәм хәзер дә заманча яңгырауларын, эчтәлекле икәнлеген күребез. Аларның үсеш юлы туры һәм чиста. Аларның көче нинди дер гаять зур югарылыкка күтәрелергә, гаять көчле каза-*

нышта күренергә тиеш булган. Һәм аяусыз көрәштә сыналган «Моабит дәфтәре»нең һәм якты, һәм ачык, һәм кырыс илһамы барлыкка килгән.

Муса Җәлилгә — беренче шагыйрьгә — бөтенхалык Ленин премиясенең бирелүе югары гаделлек, безнең барлык шагыйрьләребез өчен югары үрнәк булды.

Муса Җәлилнең зур исеме — совет поэзиясенең горурлыгы һәм даны!

Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңгырар җыр булып!

Чыннан да шулай — Җәлил җыры, Җәлил тормышы җыр булып мәңге яңгырар!

НИКОЛАЙ ТИХОНОВ.

● ● ●

Минем өчен Муса Җәлил сынаулар һәм үлем каршында гражданлык һәм язучылык батырлыгы күрсәткән кешеләрнең бер үрнәге булды һәм шулай булып кала.

Ул — зур шагыйрь генә түгел, ә бәлки көчле рухлы батыр. Ул — безнең аңа карата рәхмәт хисе йөрткән хәтеребезгә нәкъ шулай булып урнашкан зур кеше.

КОНСТАНТИН СИМОНОВ.

● ● ●

Муса Җәлил!
Бу ике сүз: поэзия һәм ирләрчә батырлык белән тулы.
Муса Җәлил!
Исән чагымда, йөрәгем типкән чакта мин бу ике сүзне кабатлаудан туктамаячакмын.

СТЕПАН ЩИПАЧЕВ.

● ● ●

Бөтен дөнья культурасы тарихында, гитлеризм агуына каршы аның көрәше тарихында, кара фашизм төнендә, Муса Җәлил, Юлиус Фучик белән беррәттән, иң якты фигураларның берсе булып басты. Бу кешеләр — интеллигент, әдәбиятчы үрнәге. Алар — тупас физик көч өстеннән рухи көчнең тантана итүен, үз карашларыңа ышану тирәнлегенең хәтта төрмәдә, вакытыннан алда тантана иткән явызлыкны таш капчыкта да җиңүен күрсәткән кешеләр.

Минем өчен Муса Җәлил гитлеризмга каршы безнең героик көрәшебездә калыккан иң гүзәл фигураларның берсе булып гомерлеккә калыр.

СЕРГЕЙ СМИРНОВ.

● ● ●

Ул минем күңелемә иң якын кешеләрнең һәм сөекле шагыйрьләрнең берсе буларак керде.

Мин Җәлилне укыганда һәм уйлаганда, аның бөтен гомере батырлык булып килеп баса. Аның белән замандашларыбыз горурлана һәм килер буын кешеләре дә аңа охшарга тырышырлар.

Аның «Моабит дәфтәре» Памирның иң ерак кышлакларына хәтле килеп җитте. Кем җиңеп үлә, ул — үлемсез. Муса Җәлил венгр халык

*шагыйре Петефи һәм чехословакия улы Юлиус Фучик белән беррәттә. Җәлилнең тормышны раслый торган героик поэзиясе халыкларны якты киләчәк өчен көрәшкә чакыра, ул гасырлар буе балкып торыр.*

Сезнең *МИРЗА ТУРСУН-ЗАДЕ.*

● ● ●

*Палач балтасы каршында шундый зирәк, Ватанга чиксез мәхәббәт, ә фашистларга җимергеч нәфрәт тулы, ялкынлы юллар язу өчен тимер, сыгылмас ихтыярлы, якты акыллы, зур һәм кайнар йөрәкле кеше булырга кирәк. Муса Җәлил әнә шундый шигъри юллар язды.*

*Шагыйрь җиңүгә нык ышанды, һәм ул җиңү килде. Ватан тантанасы өчен тормышларын биргән күп санлы геройлар арасында Муса Җәлил исеме сүнмәс йолдыз булып һәрвакыт янар.*

*ПЕТРУСЬ БРОВКА.*

● ● ●

*Һәр шагыйрьнең үз язмышы була. Муса Җәлил — героик язмышлы шагыйрь. Героиканың мәгънәсен белгән грузин халкы ерак Татарстанның мәшһүр улы Муса образын кайнар ярата. Ватаныбызның барлык халыклары кебек үк, без дә куркусызлыгы һәм батырлыгы белән бөтен дөньяны таң калдырган яшь һәм сокландыргыч шагыйрьне үзебезнең йөрәкләребездә сакларбыз.*

*ГЕОРГИЙ ЛЕОНИДЗЕ.*

● ● ●

*Тугандаш татар халкының бөек улы Муса Җәлил истәлеге гасырлар буе яшәр. Ул зур кеше, зур гражданин һәм зур шагыйрь иде. Советлар Ватанына мәхәббәтен ул үзенең сокландыргыч, гүзәл шигырьләрендә җырлады. Совет Ватаны өчен тормышын бирде.*

*Аның шигъри батырлыгы тормыш батырлыгы белән кушылды. Бу батырлык фаҗигале, ләкин һәркемне көнләштерерлек. Муса Җәлилнең язмышы һәм фидакарь поэзиясе миңа Литва шагыйрен — Бөек Ватан сугышында фашист палачлары кулыннан һәлак булган Витаутас Мотвил язмышын һәм иҗатын хәтерләтә.*

*«Моабит дәфтәре»нең литва теленә тәрҗемә ителүе, бөек шагыйрьнең үлемсез даны, бөтен дөньядагы кебек үк, минем хәтеремдә дә яшәве миңа шатлык бирә.*

*АНТАНАС ВЕНЦЛОВА.*

● ● ●

*Мин аның белән 1936 елда таныштым. Тиз арада «Джим» поэмасын — фашистлар Германиясе турындагы, төрмәләр, шуларның берсендә шагыйрь үзе дә һәлак булачак төрмәләр турындагы әсәрен тәрҗемә иттем. Тәрҗемә өстендә автор белән даими иҗат бәйләнеше тотып эшләдем. Ул чакта шагыйрь Мәскәүдә тора, ул миндә була, ә мин аның Столешников тыкрыгындагы квартирында була торган идем.*

*Ул мөлаем, нечкә хисле, бөтен табигате белән музыкаль кеше иде.*

*СЕМЕН ЛИПКИН.*

● ● ●

*...Кешелек хыялы, кешеләргә ут таратып биргән өчен таш кыяга кадакланган Прометей образын тудыра. Бу образ, җирдә кешеләр бәхете хакына көрәшкә һәм батырлыкка чакырып, миллион йөрәкләрдә*

*меңнәрчә еллар буе яшн. Муса Җәлил үзенең батырлыгы белән Прометейдан да югары күтәрелде дияр идем мин: ул күңеленең сүнмәс утларын таратуны Моабитның таш стенасына кадакланган хәлдә дәвам иттерде. Аның көче шунда, үлемсезлеге шунда.*

КИРӘП МӘРГӘН.

●●●

*Муса Җәлил шигырьләрен мин һәрвакыт каушау һәм дулкынлану хисе тоеп тәрҗемә иттем. Бу сокландыргыч кешенең һәм яхшы шагыйрьнең фаҗигале язмышы хакында уйламыйча, аның әсәрләренә кагылырга ярамый.*

АННА АХМАТОВА.

●●●

*Муса Җәлил тирән ихтирамга һәм соклануга лаек кеше булып яшәде һәм шулай үлде. Аның «Моабит дәфтәре» — какшамас ышану, гаять зур ихтыяр көче, якты, актив гуманизм хакында сөйләүче документ.*

*Гражданин һәм шагыйрь Муса Җәлил батырлыгында туган татар халкының рухи матурлыгы, көчле зур җаны, бетмәс-төкәнмәс каршы торучанлык куәте чагылды.*

РӘСУЛ РЗА.

●●●

*Муса Җәлил — татар халкының сокландыргыч улы, аның җырчысы һәм аның герое — бөтен совет халкының сөекле шагыйренә, данына һәм горурлыгына әверелде.*

*Моабит палачлары Җәлил поэзиясен үтерә алмадылар. Җәзалап үтерелү алдыннан, ул богауланган кулы белән: «Гомерем минем моңлы бер җыр иде, үлемем дә яңгырар җыр булып», дип язды.*

*Җәлил хаклы. Аның яшәве үлемнән көчлерәк булды, чөнки аның батырлыгы мәңгелек, ә җыры үлемсез.*

МАРК ЛИСЯНСКИЙ.

●●●

*Шагыйрь — кешедән аерылгысыз. Аның тормышы һәм иҗаты бер эздән ага. Әгәр шагыйрьнең шигырьләре кукрәүләрдә һәм давылларда туса, бу хәл аеруча әһәмият казана.*

*Поэзиянең куркусыз батыры үлемне җиңгән, өстендә палач балтасы күтәрелеп торган бер вакытта, кара фашист тоткынлыгында, каты кул һәм нык рух белән үзенең «Моабит дәфтәре»н иҗат иткән. Кешеләргә тугрылык, Ватанга тугрылык турындагы шигъри ант аның тиздән тибүдән тукталачак йөрәгендә мәңгелек чишмәсе төсле ургыла.*

*Ул үзенең кыска, ләкин якты поэтик юлында, үз каны белән беркетелгән иҗат батырлыгында безгә тынгысыз васыять һәм нәказ калдырган. Моны киләчәк буыннар исләрендә изге бурыч итеп тотарлар.*

*Әсир ителгән, ләкин буйсынмаган сугышчы-шагыйрьнең чәнечкеле юлы Литва җире аркылы да узган. Тик үлемсез геройның безгә шулай кадерле булуы моның белән генә аңлатылмый. Легендалар белән бизәлгән, яктылыгын һичкайчан җуймаячак дан белән бүләкләнгән герой хәзер дә үзенең рухланып язылган шигъри юллары белән туган Татарстанына эндәшкән кебек. Неман буе халкына, безнең бөтен Ватаныбызга, ирек сөюче кешеләргә, Поэзиянең һәм Азатлыкның бөтен дөньядагы барлык дусларына мөрәҗәгать итә.*

ЭДУАРДАС МЕЖЕЛАЙТИС.

*Нил Юзиев*

# А. ФАДЕЕВ ҺӘМ ҖӘЛИЛ

Татар язучылары А. Фадеевны олы таланты өчен генә түгел, ә гадилеге, кешелеклелеге, әдәбият турында А. М. Горький шикелле үк аталарча кайгыртучанлыгы өчен яратып искә алалар.

Муса Җәлилнең фашист тоткынлыгында, төрмәдә үлем алды сәгатьләрендә А. Фадеевка мөрәҗәгать итеп хат язуы һич тә очраклы хәл түгел иде. Бу — татар язучыларының А. Фадеевка булган ышанычы һәм мәхәббәте турында сөйли торган әһәмиятле күренеш. Җәлилнең бу соңгы хатын Берлинны алучы совет солдатлары 1945 елның маенда табып алалар һәм аны Мәскәүгә, Язучылар союзына, А. Фадеевка салалар. А. Фадеев үзе бу истәлекле кәгазь кисәге турында түбәндәгечә яза: «Кәгазьнең кырыйларына Залиловның якынча түбәндәге эчтәлекле сүзләре теркәлгән иде: «Мин танылган татар шагыйре Муса Җәлил, Моабит төрмәсенә политик гаепләнү ташланган әсир буларак ябылдым, һәм, мөгаен, тиздән мине атарлар. Әгәр бу язу руслардан кемгә дә булса эләксә, минем Мәскәүдәге язучы иптәшләргә миннән сәлам тапшырсын». Аннан соң фамилияләр саналган иде. Алар арасында минем фамилия дә бар иде, ә калганнарын инде онытканмын. Аннары — семьясына хәбәр итү үтенече һәм семьясының адресы, шагыйрьнең имзасы бар. Числосы да куелган иде, анысы хәтердә калмаган, тәгаен ул 1944 ел түгел идеме икән әле? Җәлил язуының читләрендә тагын ике төрле кул, ике төрле каләм белән, күрәсең, төрле вакытта язылган ике өстәмә язу да бар иде. Аларның берсе — «бәлки, Залилов исән калыр әле» дигән өметне чагылдыра. Икенчесе, үтә грамотасызы, Совет властена дошман эчтәлектә язылган иде һәм анда «сезнең Җамбулыгыз хәзер тере түгел инде» (наданлык аркасында бу сүзләрне теркәүче Җәлил фамилиясен Җамбул фамилиясе белән бутаган) дигән мәгънә әйтелгән иде». (А. Фадеев. Әсәрләр җыелмасы. Биш томда. Бишенче том. Госполитиздат, М. 1961, 352 бит.)

А. Фадеев М. Җәлил һәм аның иҗаты белән Бөек Ватан сугышына кадәр, 30 елларда ук таныш булган, аны талантлы зур шагыйрь дип исәпләгән. Бу танышлык кайчан башланып киткән — Җәлил Мәскәү дәүләт университетында укыгандамы, әллә «Коммунист» газетасында эшләгәндәме, әллә Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы татар студиясендә әдәби бүлек мөдире булып торгандамы — хәзергә ае, елы белән тәгәл кистереп әйтүе кыен. Әмма шунысы шиксез, М. Җәлил Татарстан Язучылары союзының җитәкчесе булып эшләгән елларда (1939—41) ул инде СССР Язучылары союзының генеральный секретаре А. Фадеев белән яхшы ук таныш булган, байтак тапкырлар очрашып, Татарстан язучылары оешмасына караган аерым мәсьәләләр буенча аңардан файдалы киңәшләр һәм тиешле ярдәм алган.

М. Җәлилнең 1941—42 елны армиядән язган хатларында А. Фадеев еш кына телгә алына. Тормышында хәл ителәсе катлаулы мәсьәләләр чыкканда, Җәлил һәрвакыт, иптәшләрчә киңәш сорап, А. Фадеевка мөрәҗәгать итә, аның кешелеклелегенә, ярдәменә таяна. Менә, мәсәлән, Җәлилнең 1942 елның 26 февралендә Әминә ханымга язган хатыннан бер өзек:

«Фадеев белән сөйләштем. Һәм шагыйрь Липкин аркылы генерал-полковник Городовиков белән сөйләштем. Милли частьларны формировать итү аңа тапшырылган

икән. Мине татар-башкорт частена җибәрүләрен сорадым. Язучылар союзы милли частьларга җибәрергә тәкъдим ителәчәк язучыларның исемлеген төзи. Минем фамилия беренче булып язылган. Бу исемлек Глав. ПУРККАда каралырга тиеш, һәм ул шушы исемлек буенча, безне РККАның милли кадрлары итеп төзеләчәк милли частьларда файдаланырга тиеш... Фадеев мине «Кызыл Татарстан»ның спец. военкоры итеп билгеләргә тәкъдим итүен әйткән иде. Әгәр обком һәм газета үзе, Фадеев рекомендациясенә кушылып, шул турыда ПУРККАга язсалар, моның тормышка ашуы мөмкин».

А. Фадеев фронттагы татар язучыларын, шул исәптән Муса Җәлилне газета хәбәрчеләре, журналистлар итеп тарту, аларның гомерләрен саклап калу буенча шактый күп хезмәт куя. Җәлилне «Кызыл Татарстан» газетасының махсус хәрби хәбәрчесе итеп тәкъдим итүе, Язучылар союзындагы исемлектә Җәлилнең беренче булып язылуы югарыдагы өзектән ачык күренә. Әмма бу кәгазь тиешле оешмаларга барып җитеп, хәл кылынганчы Җәлилнең язмышы көтелмәгән икенче вакыйгалар — тоткынлык белән бәйләнеп китә.

А. Фадеев татар язучыларын армиядән чакырып алып, матбугат эшенә күчерү буенча 1943 елны да эш алып бара. Бу яктан, мәсәлән, аның 1943 елның 21 октябрендә СССР Язучылары союзы президиумының утырышында сөйләгән чыгышы әһәмиятле.

«Татарстанда язучыларны югалту 20 процентка җитә — 54 язучыдан 11—12 кеше һәлак булган. Ә без 750 язучыдан 83 язучыны югалтканбыз, үлгән язучыларның проценты кимрәк. Мин бу мәсьәлә буенча үзем иптәш Щербаковка[1] хат язачакмын һәм ул безгә ярдәм итәчәк». (Сәнгать һәм әдәбиятның үзәк архивындагы материаллардан.)

А. Фадеев чыннан да татар язучыларын фронт газеталарына күчерү буенча президиум утырышыннан соң зур гына эшләр башкара: үзәк хәрби оешмаларга мөрәҗәгать итә, мәсьәләне КПСС Үзәк Комитеты белән хәл кыла. Әлеге утырышта татар әдәбиятына кагылышлы әһәмиятле мәсьәләләр карала, безнең язучылар турында кызыклы фикерләр әйтелә, әдәбиятны үстерүгә бәйле карарлар кабул ителә, татар язучыларының әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп чыгару кебек практик чаралар күрелә. А. Фадеев җитәкчелегендә үткән бу президиум утырышы материаллары белән миңа үткән елны Мәскәүдә СССР сәнгате һәм әдәбиятының үзәк дәүләт архивында танышырга туры килде (631 фонд, 665 саклау берәмлеге, 3—13 битләр). Чыгышлар үз вакытында стенографистка тарафыннан язылып, машинкада басылган хәлдә сакланалар. Машинкада басылганнан соң, беркетмә чыгыш ясаучылар тарафыннан редакцияләнмәгән. Шуңа да аерым урыннарда төшереп калдырылган яки аңлашылып бетмәгән җөмләләр дә очрый.

1943 елның 21 октябрендә СССР Язучылары союзы президиумында татар әдәбиятына кагылышлы махсус мәсьәлә — «Бөек Ватан сугышы көннәрендә татар язучыларының эше» дигән көн тәртибе тикшерелә. Утырышта татар язучылары да катнаша. Башта шушы темага доклад белән Г. Кашшаф чыгыш ясый. Президиумда катнашучы рус язучыларына доклад нык тәэсир итә. Алар өчен татар язучыларының сугыш елларындагы эшчәнлеге чын-чыннан көтелмәгән зур яңалык була. Алар татар язучыларының фидакарь хезмәтенә соклананалар, батырлыкларына зур бәя бирәләр, татар язучыларының әсәрләре белән рус һәм башка милләт укучыларының мәңгача таныш булмауларына пошыналар. Мәсәлән, күренекле әдәбият белгече П. Г. Скосырев чыгышында шундый юллар бар: «Татар халкы сугышта батырларча көрәшә. Язучыларының да күпчелек проценты сугышта катнаша. Алар катнашып кына калмыйлар, иҗат та итәләр. Татар язучылары үзләренең әсәрләре белән совет әдәбиятына зур өлеш кертәләр. Ләкин без, кызганычка каршы, бу турыда бернәрсә дә белмибез икән... Г. Кашшаф докладын тыңлагач, мин аңладым, һәм без барыбыз да моны танырга тиешбез: татар әдәбияты алдында безнең гаеп гаять зур. Без татар язучылары алдында зур бурычлы...»

---

[1] А. С. Щербаков (1901—1945) — 1941 елдан ВКП(б) Үзәк Комитеты секретаре, 1942 елдан ПУРККА начальнигы.

А. Фадеев кемнәрнең нинди әсәрләр язуы белән дә, сугышта Язучылар союзы членнарыннан ничә кешенең һәлак булуы һәм хәбәрсез югалуы белән дә кызыксына. Ул М. Җәлил язмышына аеруча нык әһәмият итә, шагыйрь язмышын ачыклаучы сораулар бирә. Г. Кашшаф Җәлилнең Волхов фронтында хәбәрсез югалуы турында сөйли. М. Җәлил үзе фронтка киткәнче үк (1942 елны) русча чыгару өчен Гослитиздатка шигырьләр җыентыгын төзеп калдырган була. А. Фадеев бу китапның язмышы өчен дә борчылу белдерә. Дәүләт нәшриятының ул вакыттагы җаваплы эшчесе Деев М. Җәлил китабының басылмыйча ятуының сәбәпләре итеп шагыйрьнең фронтта хәбәрсез югалуын, югалу шартларының томанлы булуын күрсәтә. А. Фадеевны бу җавап һич тә канәгатьләндерми. Ул Җәлил китабын чыгару буенча ашыгыч чаралар күрү, консервациядән алу кирәклеге турында сөйли һәм фронтовик татар шагыйренең җыентыгына гаять салкын каравы өчен нәшриятны каты шелтәли. Шул ук көнне, президиум утырышыннан соң СССР Язучылар союзында татар комиссиясенең утырышы үткәрелә, комиссия татар әдәбияты антологиясен русча хәзерләү һәм Җәлил шигырьләрен 1944 елны басып чыгару мәсьәләләрен карый һәм карар кабул итә. Җәлил үзе төзегән җыентык Гослитиздатта эзсез югалса да, Җәлил шигырьләре эзсез югалмый. Аның фронт шигырьләре 1944 елны Казанда «Письмо из окопа» исемендә басылып чыга.

Хәбәрсез югалуга берничә ел үтүгә һәм һәртөрле шикләргә, «томанлы хәл»ләргә карамастан, А. Фадеев Җәлилгә кеше һәм язучы буларак күңелендә тирән ышаныч саклаган һәм бу ышанычын һәртөрле шикләрдән өстен куйган. А. Фадеев президиум утырышындагы соңгы сүзендә дә Җәлилне «танылган зур шагыйрь» буларак телгә ала, «аны туры-дан-туры хәрби эш белән бәйләнмәгән башка бер армия эшенә күчерү буенча гадәттән тыш күп тырышуы» турында сөйли.

1944 елның мартында Икенче имперский германский суд М. Җәлилне һәм аның көрәштәш иптәшләрен үлем җәзасына хөкем итә. Шул ук 1944 елның август аенда алар үтереләләр. Ә шул ук елны, шул ук вакытларда шагыйрьнең туган илендә, аның үлемсезлеген раслагандай, рус телендә шигырьләре басылып чыга, шагыйрьнең көр авазы, шигъри анты яңгырый. Шагыйрьнең яшәвен аның шигырьләре дәвам итә... А. Фадеевның Җәлил китабын чыгару өчен көрәше, шул рәвешчә, шактый тирән мәгънә алып китә.

Шунысын да әйтеп узарга кирәк, А. Фадеев Җәлил исемен аклау буенча сугыштан соңгы елларда да зур эш һәм көрәш алып барды, аның исемен кабат халыкка һәм әдәбиятка кайтаруда ярдәм итте. Беренчеләрдән булып, ул Җәлил иҗатының бөтен совет әдәбияты күләмендә тоткан гаять зур ролен билгеләде. Совет Язучылары союзы правлениесенең XIV пленумында сөйләгән докладында ул совет әдәбиятының алтын фондын төзүче бөек язучылар: Горький, Маяковский, А. Толстой, Фурманов, Макаренко, Н. Островский, Я. Купала, А. Акопян, Җамбул, Хәмзә исемнәре белән рәттән М. Җәлил исемен дә атады.

Кабат президиум утырышына кайтыйк әле. А. Фадеевның чыгышыннан аның башка татар язучыларына да зур игътибар һәм хөрмәт белән каравы, күп кенә язучыларның әсәрләре белән таныш булуы күренә. Аның чыгышы бай тарихлы татар әдәбиятына зур хөрмәт белән сугарылган:

«Татарстанның Язучылар союзы язучыларның иң эре оешмаларыннан санала. Бу чыннан да шулай, хәтта ул кайбер союздаш республика оешмаларыннан да зуррак. Әдәби традицияләр ягыннан да татар әдәбияты шактый бай классикалы әдәбият. Татарстанда яшәүче язучылар арасында әдәбиятта күптәннән эшләп килүче, төрле телләргә тәрҗемә ителеп, Татарстаннан еракта да танылган язучылар бар. Биредә катнашучы язучылардан без Г. Кутуйны, Ә. Еникине, Н. Исәнбәтне күптәннән беләбез. К. Нәҗми — олы язучы, зур әдип. Тагын да байтак исемнәрне санарга мөмкин булыр иде», — дип сөйли А. Фадеев. Аннары ул татар язучыларының сугышның авыр көннәрендә рус язучыларына туганнарча ярдәм итүенә тукталa:

«Безнең тормышның авыр бер дәверендә, эвакуация белән Казанга килергә тиеш булган бер чорында, без Казан иптәшләребез йөзендә бик кунакчыл хуҗалар белән очраштык. Бу бик авыр вакытлар иде, күп кыенлыклар кичерергә туры килә иде. Чөнки эвакуация белән килүчеләр гаять күп иде. Язучылар безгә карата бик җылы мөнәсәбәттә булдылар. Бу вакытларда алар тулысы һәм бөтенләе белән безнең белән

шагыйрьләре белән кешеләрдә, бөтен нәрсәдә безгә ярдәм иттеләр. Турысын әйтергә кирәк, без аларга, хуҗалар буларак, илебез өчен авыр вакытларда безнең Язучылар союзына ярдәмнәре өчен күп нәрсәләрдә бурычлыбыз. Һәм соңга калып булса да, моның өчен без аларга рәхмәт әйтергә тиеш. Без анда булган дәвердә татар язучылары белән тыгыз бәйләнеш урнашты һәм ныгыды дисәк, һич тә арттырып әйтү булмас. Бу бәйләнешне ныгыту буенча Татарстаннан киткәннән соң кайбер нәрсәләр эшләнде. Рус шагыйрьләре татар поэзиясе үрнәкләрен тәрҗемә иттеләр. Ләкин болар без эшләргә мөмкин булганнар белән чагыштырганда бик тә аз әле. Бу — безнең гафу ителмәслек хатабыз. Без шагыйрьләрне генә түгел, драматургларны да, проза буенча да тәрҗемә итәргә булдыра алыр идек, әгәр ул дәвердә өлгерә алмаганбыз икән, күп вакытлар соңрак та эшли ала идек. Казан бездән ерак урнашмаган бит. Татар язучылары белән бәйләнеш ныклы булырга тиеш...».

Мәгълүм булганча, А. Фадеев үзе Казанда Ватан сугышының беренче елларында бернича тапкыр булып китә. Бернича көн ул Таҗи Гыйззәт квартирасында тора, ике атна чамасы режиссер С. Булатовта, ай чамасы һәйкәлче С. Ахунда яши, Ш. Камал һәм күп кенә башка татар язучылары белән таныша. 1941 елның октябренда ул, мәсәлән, Казанда татар язучыларының киңәшмәсендә «Ватан сугышында совет язучылары» дигән темага доклад ясый. Шул ук елның 7 ноябрендә «Красная Татария» газетасында «Бөтенесе җиңү өчен» дигән мәкаләсен бастырып чыгара. А. Фадеев Чистайда да өч атна чамасы торып китә, анда да чыгышлар ясый.

Әмма А. Фадеевның Татарстан һәм татар язучылары белән дуслыгын Ватан сугышының беренче авыр еллары белән генә чикләү дөрес булмас иде. Ул татар әдәбияты һәм аның күренекле вәкилләре белән егерменче елларның ахырларында ук таныша башлаган, шул дәвердән башлап татар әдәбиятының үсешен кызыксынып күзәтеп барган. А. Фадеевның әлеге чыгышында аның татар әдәбиятының торышы, аерым әдипләре турында кызыклы гына күзәтүләрен очратырга мөмкин:

«Миңа 15 ел дәвамында эпизодик рәвештәрәк булса да татар поэзиясе, прозасы һәм драматургиясе белән даими танышып барырга туры килде. Хәтта мин татар әдипләренең русча беренче җыентыгын да редакцияләдем».

А. Фадеев үзенә Галимҗан Ибраһимов кебек өлкән буын татар язучыларының яхшы ук таныш булуы, аларның кайберләренең әсәрләре тик политик биографияләренә бәйле рәвештә басылмаулары турында сөйли. Галимҗан Ибраһимовның исеме телгә дә алынмаган бер заманда А. Фадеевның аны татар әдәбиятының олы художнигы буларак искә алуы кыюлык турында сөйләмимени?! «Мин әйтергә телим,— ди ул шуннан соң ук, — татар классикларына үз хезмәтләренә карата тәнкыйтьчел мөнәсәбәт хас. Алар художестволы әсәр өстендәге хезмәтнең нәрсә икәнлеген яхшы төшенеп эш итәләр иде». А. Фадеев татар классикларының әсәрнең стиле өстендә җентекләп эшләүләрен, югары художестволылыкның язучы стилендә ачык гәүдәләнүен билгеләп үтә.

«Алыйк, мәсәлән, иҗат юлын үз белемен үзе күтәрү юлы белән үткән Гафуриның. Ул Горький белән шәхси бәйләнештә иде. Горький да аны белә һәм аның турында «Гафурида зур әдәбиятның сулышы сизелә» — дип әйтә торган иде. [? [1]] — бу чыннан шигъри әйбер. Тик подстрочниклар гына уңышлы эшләнмәгән. Һәр фразада язучының стиль өстендә эшләве күренеп тора, ул яхшы тел белән язылган. Ә менә яшь буын татар язучыларының әсәрләренә күз салсак, бу һәйбәт традициянең йомшый төшүен, онытылуын күрәбез. Яшь язучыларның әсәрләрендә талымсызлык, ашыгучанлык сизелә.

Драматургия өлкәсенә килсәк — Татарстанда зур әдәби стажлы һәм тәҗрибәле драматурглар бар. Алыйк Нәкый Исәнбәт әйберләрен — аларны тәрҗемә итәргә кирәк».

А. Фадеев һәм татар язучылары дигән тема әдәбият тарихының үткән сәхифәләренә караса да, ул әдәбият тарихының актуаль һәм әһәмиятле мәсьәләләрен үз эченә ала, бүгенге әдәби процесска да турыдан-туры килеп бәйләнгән урыннары бар.

[1] Әсәрнең исеме беркетмәдә язылмаган. Г. Кашшаф А. Фадеевның «Шагыйрьнең алтын прискасында» әсәре турында сокланып сөйләве турында әйтә.

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

*Гази Кашшаф*

# АНЫҢ ШИГЫРЬЛӘРЕМЕ?

*(Муса Җәлил шигырьләре дип уйланылган әсәрләр турында)*

Шагыйрь Муса Җәлил соңгы сулышына чаклы шигырьләр язган. Аны һәм Муса-ның дусларын үлемгә озатып калган италияле Ланфредини:

— Муса төрмәдә язды, ләкин алар шигырьләр идеме, белмим, — дип белдерә. Ә шагыйрь шигырь язмый нәрсә язарга тиеш соң?

Үлем көткәндә дә, башны палач балтасына тоткан килеш тә ул каләмен ташламаган, шигырьләр язган. Нинди генә хәлләр башыннан кичмәсен, нинди генә вакыйганың шаһите булмасын, Муса күңеленә алар шигырь булып, үч һәм нәфрәт ялкыны булып язылып барганнар.

Шигырь булып чыга үч ялкыны
Яраланган лачын йөрәктән, —

ди ул үзе дә.

Волхов фронтында сугышканда, камалган хәлдә дә, ул төнге сугышчан дәһшәт серлелеге турында сокланып яза. Алгы сызыкта, тира-якта үлем биеп торган чакта да, кар астыннан яңа калкып чыккан язгы чәчәкләргә тыныч кына карый алмый. Чәчәкләр аның романтик хисләрен уяталар, аның күңеленә шигырь булып язылалар. Әсирлеккә төшкәч, аның шигъри ялкыны моңа кадәр күрелмәгән куәт белән дөрләп китә. Йөрәктә кайнаган хисләрне, тоткын күңелендәге җан тетрәткеч уй-тойгыларны әйтеп калдырырга, буйсынмаган хөр табигатьнең җәрәхәтләнү газабын сурәтләргә омтыла.

Бөтенесе үлеп бетмәс, дип уйлый шагыйрь, унысы үлсә, берсе исән кайтыр һәм шигырьләр саф күңелнең нинди газаплар кичерүен, Ватанга, совет халкына турылыклы булганлыгын, батыр солдат булып көрәшкәнен дусларга, гаиләгә сөйләр!



Берлинда Шпандау төрмәсендә М. Җәлил белән бер камерада утырган италияле Р. Ланфредини.

Әкияттәге серле йомгак булып,
Җырым калды сүтелеп юлымда.
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Мине шушы йөрәк җырымда.

Бу юлларны инде Муса Җәлил Моабит төрмәсендә утырганда, 1943 елның 12 декабрендә яза. Алар үтелгән юлның йомгагы төсле язылганнар, һәм без, чыннан да, аның шигъри юлларыннан атлап китсәк, таң калырлык героик тормышны күз алдына бастырабыз. Ләкин Мусаның барлык шигырьләре дә әле табылмаган. Серле йомгакны сүткәндә, безгә бик кызык та, үкенечле дә булган вакыйгалар белән очрашырга туры килә.

Тормыш — тормыш инде ул, катлаулы һәм киң. Кешеләр характеры да искиткеч күп төрле һәм катлаулы. Берәүләр шигырьне укырга яратмыйлар, ә рәхәтләнеп тыңлыйлар; икенчеләре, шигырь ятлауга сәләтсез, ләкин бик бирелеп укый; өченчесе ятламый, ләкин күчереп ала һәм аңа бер күңел күтәрә торган нәрсә дип карый. Бер ишесе шигырь аша үз тормышын күрә, үз якыннарын таный һәм алар белән әңгәмә кылып йөри. Шигырьне йөрәк яры итеп тә, сердәш һәм юлдаш итеп тә кабул итәләр...

Муса Җәлил төрле тип укучыларга очрый, аны шагыйрь итеп тә, укытучы итеп тә тыңлаучылар була. Аны игътибар белән дә тыңлыйлар, сагаеп та калгалыйлар...

Муса әйтеп торып яздырганда, элек һичкайчан шигырь укымаган, тере шагыйрьләрнең берсен дә күрмәгән, гомумән тормышта шигырьдән башка да яшәп була, диган фикер белән килешеп яшәүче кешеләргә дә очрый. Ләкин Муса шигырьләрен укыганнан соң, әнә шул җәһәннәм базында, ач килеш, юеш землянкаларда ятканда, ул кешеләрдә поэзиягә мәхәббәт уяна. Шигырь аларның юлдашы булып китә! Без андый иптәшләр белән дә очраштык!..

Кызганычка каршы, андый иптәшләрнең бер өлеше һәлак булган, бер өлеше шигырьләр язылган дәфтәрләрен югалткан яки яндырырга мәҗбүр булган, бер өлешенең инде хәтере хыянәт итә башлаган...

Йөрәк каны белән язылган шигырьләр яралы солдат күңеленә турыдан-туры күчкәннәр; шигырь юллары аларның хәтерләрендә мәңге югалмаслык буразналар салган. Ташка уеп язган шикелле хәтердә сакланган. Ләкин еллар, газаплы, канлы еллар ташларны да шомарткан, күңел буразналарын да күмеп киткән...

Менә безнең каршыбызда зәңгәр күзле, яшь чырайлы, егетләрчә җитез хәрәкәтле Богачев утыра. Сугыш елларында аңа әле бары егерме яшь кенә булган һәм кеше ышанмаслык дәрәҗәдә хәтерле булуы белән аерылып торган. Хәрби газета редакциясендә эшләгәндә, берәү дә ул барында энциклопедиягә, справочникларга карап тормаган. Әле дә ул бер тапкыр укыган китапны яттан, сүзгә-сүз сөйләп чыга ала. Ә менә иң кирәклесен ул да оныткан...

1945 ел. Безнең хәрби газета Свинемюнде шәһәрендә чыгарыла. Бар нәрсәгә дә өлгер, яшь корреспондент информацияләр җыя, совет солдатларының батырлыклары турында очерклар яза...

Көннәрдән бер көнне типографиядә эшләүче Лотта Елфи Костя Богачевка мөрәҗәгать итә.

— Сезне бер немец күрергә тели, сөйләшергә тели! — ди.

Богачев немец белән очраша.

— Ул — Вилли исемле немец иде. Беренче дөнья сугышында флотта хезмәт иткән, бу сугышта бөтенләй катнашмаган... Ул үзе белән берничә бит герблы кәгазь һәм Свинемюнде шәһәре картасын алып килде. Кәгазь саны төгәл хәтердә калмаган. 5—6 биттән дә ким түгел. Кәгазьнең бер почмагында Гамбург яки Бремен шәһәрләренең гербы төшерелгән иде. Югарыда ниндидер бер немец фамилиясе язылган һәм аның Штеттин вокзалы районында яшәве күрсәтелгән иде.

Соңыннан, Берлинда эшли башлагач, без Тауфикъ Мансуров (аны без Юрка дип йөри идек) белән шул адрес буенча немецны эзләп бардык, ләкин йортны бомба җимергән иде, ул немецны белүче кеше табылмады.

— Ә кәгазьләрдә нәрсә язылган иде? — дип сорадык без.

— Бөтен хикмәт тә шунда... Вилли бер татар шагыйре турында сөйләде.

Костя Богачев еллар узганнан соң гына, аның Гумеров турында сөйләгәнен, ә инде Гумеровның Муса Җәлил булуын хәтергә төшерә.

— Ул кәгазьләрне татар шагыйре Гумеров язган, ләкин мин танымый да, белми дә торган шрифтта. Мин аны Мансуровка да күрсәтеп карадым, ул штабта фотограф булып эшли иде. 1927 елда туган Мансуров гарәп хәрефләрен танымады. Соңыннан

печатник Әхмәт Ганиевкә күрсәттек. Ул гарәп хәрефе белән язылганын әйтте, укый алмады.

Берәү дә укый алмаган кәгазьдә нәрсә язылганын 20 елдан соң ачыкларга тырышу, әлбәттә, җиңел түгел. Хәзер Богачев ул кәгазьләрнең кайда икәнен дә белми. Берәү дә укый алмагач, гомумән алар аны кирәкле нәрсә дип уйламаганнар да.

Ә бит анда кешенең язмышы язылган булуы мөмкин!

ГДРда Леон Небенцаль һәм Эрих Мильштат иптәшләр Богачев әйткән Виллине эзлиләр, тик әле табылганы юк.

Безнең кулыбызда Муса Җәлил шигырьләре дип төрле кешеләр тарафыннан тапшырылган дәфтәрләр саклана. Болар — Тәлгать Гыймранов блокноты, Гарәф Фәхретдинов дәфтәре, Бакый Абдрашитов язып алган шигырьләр, Гариф Хафизов һ. б. язып алып кайткан парчалар, өзекләр.

Гыймранов блокнотындагы 18 шигырьнең кайберен тулысынча, кайсыларын кисәкчә укырга мөмкин. Калганнары, гади карандаш белән язылганлыктан, бозылып, сертеләп беткәннәр. Ләкин бу блокнот арада иң бәхетлесе һәм иң данлыклысы булып чыкты. Аны өйрәнергә өлгергәнче, Ю. Корольков русчага тәрҗемә иттереп, «Литературная газета»да (3 март, 1956 ел) бастырып та чыгарды. Соңыннан тикшерә башлагач, аларны шик астына алырга туры килде. Муса язганмы соң аларны?

Мондый сорау һәркайчан безнең алдыбызда торды. Башкача булуы да мөмкин түгел. Әсирлектә яшәгәндә, шигырь язучылар шактый күп булган, чөнки шигырь бердән-бер юаныч, рухи азыкка әверелә. Анда әсирнең якты уйлары да, өмете дә, кайгы-хәсрәте дә чагыла. Шигырьне бер-берсеннән күчереп алганнар, бер-берсенә әйтеп яздырганнар, ләкин авторы кем булуын тикшереп тормаганнар. Шигырь кулъязма төсендә кулдан-кулга күчеп йөргән һәм күчерүче аны үзенчә эшкәрткән, өстәгән яки кыскарткан.

Абдулла Гафуров бер шигырьне «Ил батыры» исеме белән күчереп алган. Гыймранов дәфтәрендә ул «Безнең батыр» дип атала һәм алты юлга кимрәк, шуның өстенә, соңгы строфалары башкача. Менә ул шигырь:

## ИЛ БАТЫРЫ

Әнә күрәсезме, киң яланның
Тармагында тора бер авыл.
Күмелсә дә карга кыш көннәре,
Җәй житкәчтән матур була ул.

Чит-читләре аның матур урман,
Хәтфә җәйгән кебек һәр ягы.
Шылтыр-шылтыр ага чишмәләре.
Көн-төн сайрый сандугачлары.

Шул авылның аргы бер читендә,
Җыйнак өйдә тора кыз бала.
Айга карап тора бик моңаеп,
Авыр сулап кына тын ала.

Киткән икән аның сөйгән яры,
Киткән икән туган иленнән.
Куар өчен дошман залимнәрне,
Карт Уралдан — туган җиреннән.

Акбуз атка менеп, кылычын болгап
Алдан бара егет баш булып.
. . . . . . . . . . . . .
. . . . . . . . . . . . .
Ул кычкыра борылып, гайрәт белән,
Тавышы аша аның һавага.
Каршы килгән дошман гаскәренең
Йөрәгенә барып кадала.

Куып китте шулай дошманнарны,
Көнен белми, төнен аямый.

Каршы килгән дошман гаскәренең
Кара көчен көчкә санамый.

Акбуз аты, мескен, мәжрухланды,
Тәмам хәлсезләнде бу юлы.
Көтмәгәндә егет күкрәгенә
Ялгыш килеп тиде бер пуле.

Үлгәндә дә, мескен, чын каһарман,
— Алга, дуслар, алга юл! — диде.
Айга карап торган матур кызның,
Сөйгән яры әнә шул иде.

Гафуров шигырьнең кайбер юлларын оныткanлыгын әйтә. Һәм бу сизелә дә. Мин шул ук шигырьнең, шул ук иптәш язып биргән икенче нөсхәсен дә алдым (берсе аның «Совет Татарстаны»на моннан берничә еллар элек җибәрелгән, берсе әле күптән түгел миңа тапшырылган иде). Бер үк кеше тарафыннан искә төшереп язылган ике вариантта да аерым сүзләр алышынырга өлгергән һәм бер строфаның урыны күчкән.

Тагын бер нәрсәгә ачыклык кертергә кирәк. Шигырьдә кызның сөйгән егете дошман яуларын туган җиреннән — карт Уралдан куарга киткән. Бу нәрсә? Поэтик бизәкме, әллә аңлы рәвештә җибәрелгән шигъри иркенлекме? Мондый атамалар башка шигырьләрдә дә очрый. Шуңа күрә без аны ачыкларга тырыштык. Әсирлектә булган иптәшләр, Муса-Алишлар, Саттар-Курмаш-Симаевлар белән якыннан аралашкан көрәшчеләр мондый юлларның язылу сәбәбен немец цензурасының күзен томалау өчен аңлы рәвештә язу дип аңлаталар. Немец хәрби цензурасы «Идел», «Урал» дигән сүзләрне бик яраткан һәм, шигырьнең эчтәлеген тикшереп тә тормастан, аны сөйләргә, эстрадаларда башкарырга рөхсәт иткән. Ә укучылар яки тыңлаучылар, Гафуров әйткәнчә, «үзенчә аңлаганнар».




Н. Терегуловка француз партизаннары биргән хәрби билет. Ул М. Җәлил шигырьләрен Казанга алып кайтты.

Муса шигыреме соң бу? Әйе, шигырьнең алымнары Мусаның яшьлек чорындагы иҗатын хәтерләтә. Акбуз ат образы да Мусаның яраткан образларыннан берсе. Хәер, без Гафуровны тыңлап карыйк. Бу шигырь Деблин крепостенда аның кулына кергән. 1943 елны Деблинга «уртача буйлы, бер якка кыек салган кара чәчле, ак күлмәк өстеннән кара костюм кигән, галстук бәйләгән, үзе ялан-баш бер яшь кеше килде» дип сөйли Гафуров. Бу тышкы рәсем — Муса рәсеменә охшый. Башка иптәшләр дә аны шулай сурәтлиләр. Мусаның 1943 елда Деблинда булуы да билгеле. Ләкин Гафуров бераз аның вакытын дөрес күрсәтми, ул «көз булса кирәк» дип яза. Чынында бу бераз иртәрәк, җәй айларында була.

Гафуров болай сөйли:

— Шул көнне әсир татарларны бер баракка җыйнадылар да, анда кичә кебек бернәрсә ясадылар. Шушы кичәдә ул килгән кеше төрле шигырьләр, кайбер көлке әйберләр укыды.

Ул вакытта аның нинди фамилиядә булуын хәтерләмим. Чыгышында ул совет ягын да, немецларны да телгә алмады. Ләкин күп әсирләр ул кичне аның туган илне, халыкны сагынуга, илгә кайтып яшәүгә, гаилә бәхетләренә багышланган шигырьләрен тыңлап, аларны үзенчә аңладылар.

Без ул вакытта аның үзен ничек тә аңлый алмадык. Чөнки ул сакчысыз иркен йөри, лагерьга да керә алган иде. Ә үзе туган ил турында, халык турында сөйли; нигә качмый икән соң ул, — дип уйладык без. Шулай итеп, без аның немецлар яклымы, совет яклымы икәнен аңламый калдык.

Ул, билгеле, безнең белән бернәрсә дә сөйләшмәде. Шулай да лагерьда аны белүчеләр булган, күрәсең. Соңыннан аның шагыйрь Муса Җәлил икәнлеге турында хәбәрләр таралды һәм кайбер шигырьләре әсирләр арасында телдән-телгә сөйләнеп ятланды. Әсирләр ул шигырьләрне бик яраталар иде.

Тагын бер сорау туа. Муса-Алишлар, Курмаш-Симаевлар әсирләргә шигырьләр укыганда, үз шигырьләрен генә укыганнармы, әллә башка иптәшләренең әсәрләрен дә файдаланганнармы? Бу сорауга җавап бирү өчен көрәш максатын истә тотарга кирәк. Шигырь — көрәш коралы, әсирләрне патриотизм рухында тәрбияләүгә хезмәт иткән шигырьләр, фашизмга каршы көрәшкә өндәгән әсәрләр барысы да пропаганда эшендә файдаланылганнар. Кем язган — анысы икенче планда торган. Максат — теге яки бу шагыйрьнең иҗатын популярлаштыру түгел, бәлки — көрәшне җәелдерү.

Гарәф Фәхретдинов Гайнан Курмаштан яңа шигырьләр алган саен, аларның авторларын сораган. Аңа каршы Курмаш:

— Син тикшермә, синең эшең аларны легионерлар арасында тарату, уку, — дип җавап биргән. Һәм шигырьләр күбесенчә авторы күрсәтелмичә таралганнар.

Әсирләр Муса Җәлил дип таныган кеше Демблинда бик күп шигырьләр калдырган. Гафуров аның тагын берсен хәтеренә төшерә. Менә ул:

Белмәгәнмен кадерен үткәннәрнең —
Саран булдым йомшак сүзләргә.
Төштә генә булган безнең тормыш
Калды хәзер сагынып сөйләргә.

Суздың миңа йомшак кулларыңны,
Алар шундый йомшак иделәр.
Минем өчен синең йомшак куллар
Мәңгелеккә бәхет бирделәр.

Бу шигырьнең баштагы дүрт юлы Абдулла Алишның «Мин ул төшне кабат күрермениме?» исемле Рокыяга багышланган шигыреннән үзгәргән. Нигъмәт Терегулов күчереп алган Алиш шигырендә ул юллар болай:

Белмәгәнмен кадерең, саран булдым
Иркәләргә, җылы сүзләргә,
Ул төш булган икән безнең тормыш,
Калды хәзер сагынып сөйләргә.

Калган дүрт юлы Рәхим Саттар, Гарәф Фәхретдинов, Тәлгать Гыйммранов дәфтәрләрендә юк. Бәлки, ул башка бер шигырьнең өзегедер? «Йомшак куллар» сүзенең өч тапкыр кабатлануы да аның озын шигырьнең төрле юлларыннан җыелган булуына ишарә ясый. Һәрхәлдә, бу шигырьнең башы да, азагы да серле һәм башка белүче әсирләрнең раславын көтә.

Рухы белән шушы мәхәббәт шигыренә аваздаш тагын бер шигырь бар. Аны Бакый Абдрашитов «Сөю җыры» дип искә төшерә:

Егетләрнең каны түгелә...
Шунда Ватан данга күмелә.
Ут чәчрәтми, яшен яшьнәтми,
Корбан бирми халык яшәми.
    Мәхәббәтнең кадерен белмәгәнбез,
    Белмәгәнбез ничек сөясен!
    Әгәр илгә кайтсам, сөяр идем,
    Ничек сөйгән Таһир Зөһрәсен!

Ике шигырьдән кушылганы күренеп тора. Эчке логик бәйләнеш сизелми. Һәм ул чыннан да шулай. Аның беренче дүрт юлы Рәхим Саттар шигыре. Аның дәфтәрендә шул дүрт юллык үзенә башка шигырь. Калган дүрт юл, чыннан да, «Сөю җыры» һәм ул башка язмаларда күренми. Билгеле, ул дүрт юллык кына булмаган. Иска төшерүче аның күп юллары онытылган икәнлеген яшерми. Ләкин ничек кенә булмасын, төрле вакытта, төрле кешеләр кулына килеп кергән шигырьләрнең тема берлеге (мәхәббәт) бар. М. Җәлилнең «Соңгы үпкә» исемле шигырендә, дөньяны Ләйлә итеп күреп, «Мәҗнүн гыйшкы белән яраттым» дип әйтелә. Монда да шул ук, Таһир Зөһрәсен ничек өзелеп сөйсә, илгә кайткач, шулай сөячәген ышандыра.

Күрәсез, поэтик бизәкләр бер тирәдә йөри.

Бу шигырьләр Абдрашитовка ничек килеп кергәннәр соң? Моның тарихы шулай ук кызыклы һәм игътибарга лаеклы. Абдрашитов, башка бик күп әсирләр кебек, сугыш елларында Европа илләрендә фашистлар чыбыркысын нык татыган кешеләрнең берсе. Ул Германиядәге лагерьда була. Аннан Франциягә алып китеп, шахтада эшләтәләр. Чыдый алмыйча, ул аннан кача. Франция, Германияне үтеп, Польшага килеп җитә. Аны тотып алалар. Яңадан шахта. Аннан Дармштад шәһәрендәге паровоз төзү заводында. Анда кан эчкеч немец начальнигын үтерүдә катнаша, тагын берсен үтергәч, иптәшләре белән качалар. Ләкин тотылалар. Шуннан соң ул үзенең кая китереп ташланганын да белми. Эсэсчылар аны үтергәнче диярлек кыйныйлар да бер төрмәгә китереп ябалар.

Билгеле, Бакый Абдрашитовны ул төрмәдән исән чыгармаган булырлар иде, ләкин берәр айлап утырганнан соң союздаш гаскәрләрнең авиациясе төнлә белән шәһәрне бомбага тота һәм бер бомба нәкъ төрмә өстенә килеп төшә. Бакый, аңын югалтып, җимерек таш, тимер-томыр, тузан арасында күпме ятканын белми.

— Камераның бер як почмагы бөтенләй юк, урам күренеп тора. Ә баштан кан ага.



А. Тиммерманс хатыны Жанна белән.

Бакый күлмәге белән башын бәйләп, ачык җирдән урамга чыга. Аның бәхетенә, төрмә шәһәр читендә булган һәм ул бомбага тотылган шәһәр урамыннан, тузан, төтенгә ышыкланып, шәһәрдән чыгып киткән.

Бу — Франкфурт-на-Майне шәһәре төрмәсе була һәм ул анда коңгырт чәчле, аны бер якка тараган, калын гына иренле бер кеше белән очраша. Ул аның исемен дә сорашмый, ни өчен бу төрмәгә эләгүе белән дә кызыксынмый. Үз хәлем-хәл, дип уйлый, баштагы көннәрдә аңа авыз ачып сөйләшүе дә читен була.

Янына килеп, хәлен сорашып, ярдәмләшеп йөрүче кешене сугыш бетеп, туган илгә кайткач, Муса Җәлилнең әсәрләре басылып чыккач кына:

— Минем төрмәдәшем Муса Җәлил булгандыр дип уйладым,— ди Абдрашитов. Ләкин ул сөйләгән портрет Мусага охшап бетми.

— Тән мена нинди хәлгә керде, энем,— ди иде Муса абый.— Тәнена бармак, камырга баткан кебек, чокыр калдырып кера иде.

Ачлыктан шешенгән, җәзаланган кеше сугышка хәтле төшкән рәсемнәренә охшамаска бик мөмкин. Җитмәсә аны һаман җәфалап, газаплап торганнар. Көн саен өчәрдүртәр тапкыр допроска чакырганнар. Ул аннан соң тагын да хәлсезләнеп, йончып кайта торган булган. Ул үзен Татарстанның бер колхозы председателе идем, дип таныткан.

Байтак көннәр узганнан соң, бу шешенгән тоткын Бакыйга бер дәфтәр биргән һәм үзе әйтеп торып шигырьләр яздырган:

— Әнем, исән булсаң, мине искә алырсың, — дигән ул. Бер утыруда дәфтәргә уникеләп шигырь язганнар. Абдрашитов шул шигырьләрне күңеленә ятлаган. Дөрес, еллар узган саен шигырьләр онытыла барган. Ләкин хәтердә калганнары да игътибарга лаеклы. Абдрашитовка «колхоз председателе» иң элек «Әнкәмә хат» дигән шигырьне әйтеп торган. Аннан башкаларын. Шулар эчендә «Кошчык», «Төн» шигырьләре бар.

«Әнкәмә хат» исемле шигырьнең баштагы строфалары инде Абдрашитовның хәтерендә калмаган. Ә соңгы ун юлы бар һәм ул юллар Рәхим Саттарның шул исемдәге шигыреннән алынганнар. «Кошчык» Муса Җәлилнең Моабит дәфтәрләрендәге атаклы шигырь. Тулы килеш аның да хәтердә сакланмаган, ләкин нәкъ шул шигырь.

«Төн» исемле шигырь безне аеруча кызыксындыра. Бу шигырь моңа чаклы да бәхәс тудыра иде. Фәрит Солтанбеков аны Тегель төрмәсендә Курмаштан алган һәм авторын да Курмашов дип раслый. Рушат Хисаметдиновка ул шигырь шул ук төрмәдә кулына килеп кергә һәм ул аны Муса Җәлилнеке дип ышана. Гарәф Фәхретдинов та шул ук фикерне куәтли һәм ул аның истәлекләрендә басылып та чыккан иде.[1] Абдрашитов искә төшергән «Төн» 7 строфадан тора һәм элекке варианттагыча беренче строфа соңыннан кабатланмый:

Ил язмышы хәл ителгән чакта,
Җанкай кочагында ятмадым,
Сине кидем, шинель, сине алдым, мылтык,
Синнән артык юлдаш тапмадым.
Ачы язмыш җиле кире исте,
Ирек тә юк миндә, мылтык та.
Ә йөрәгем әле һаман тибә —
Ишетәмен төнге тынлыкта.

Төн. Төрмә. Тирән тынлык.
Бер тавыш юк бүлмә эчендә.
Тик тыштагы төнге часовойның
Аяк тавышы гына ишетелә.
Йокы алмый, никтер йөрәк ярсый,
Күңел китә ерак-еракка.
Кемдер шунда, харап булдың, диеп,
Пышылдаган кебек колакка.

Күпме генә әле мин яшәдем?
Күпме эш күрсәттем халкыма?
Күңелемдә минем бер юаныч:
Тугры уләм биргән антыма.
Йокы алмый, никтер йөрәк ярсый,
Төрле уйлар килә күңелгә.
Бөреләнеп җиткәч яшь алмый
Шиңәрмен күк инде гомергә.

Әгәр шулай булса, кышкы җилләр,
Шул егетнең зарын тыңлагыз.
Яшь егетнең мәгърур соңгы сүзен
Илдән илгә күчереп җырлагыз!

Бу бөтенләй яңа вариант, яңа шигырь. Рәхим Саттар дәфтәрендә ул юк. Гыйммрановта да шулай ук. Бәхәс бары Солтанбеков белән Фәхретдинов арасында бара, ә аларга Абдрашитов кушыла.

[1] «Муса турында истәлекләр». ТКИ. 1964. 210—211 битләр.

Түбәндәге шигырьләрне Абдрашитов: «Муса абый синең үзеңә багышлыйм, дип диктовать итте» — дип сөйли. Моны да ул, башка шигырьләре кебек, һичнинди язуга карамыйча, ятланган шигырь төсендә әйтеп торган. Ул «Саубуллашу» дип атала.

Сау бул инде, дустым, көрәшалмабыз,
Ерак кала безнең арабыз.
Кайнар яшьләр түгеп артыгыздан,
Якты юллар теләп калабыз.
Син бәхетле, чиксез зур бәхетле,
Син кайтырсың туган илеңә,
Яшьли уйнап үскән кырларыңа,
Кара кашлы нечкә биленә.

Мин каламын монда төрмәләрдә,
Мәңге сүнмәс хәсрәт эчендә.
Ялгызлыкта, кояш нуры күрми,
Үлем көтеп көндез, кичен дә.
Әйт бәгыремә соңгы сүзләремне,
Сагынып көтмә дип сөйгән ярыңны,
Сөйлә аңа үлем тырнагында
Тәмамланган көрәш җырымны.

Сау бул инде, башка көрәшалмабыз
Кулны кулга сузып дусларча.
Кайт илеңә, сөйгән ярың белән шат яшә!

Моның да бер юлы онытылган, кайбер сүзләре шулай ук алышынган булуы ихтимал.

Муса Җәлил әле әсирлеккә төшкәнче үк якын дусларына шигъри истәлекләр калдыра килгән. «Окоптан хат», «Иншәр сеңелгә», «Дуска истәлек» (Латыйф Әмирханга) һ. б. шигырьләре матбугатта билгеле. Хәрби курсларда укыганда, төнге сакта торганда, ул Солтан Зариповка аның соравы буенча, күрәсең, бер шигырь язып биргән. Бу — Солтан исеменнән аның хатыны — Бануга хат формасында язылган һәм ул Мусаның билгеле булган «Соңгы кич», «Хуш, акыллым» шигырьләренең строфаларын яраштырып эшләнгән. Ләкин ике строфасы яңа һәм башка шигырьләрендә булмаган юллардан тора:

Таң атканда мине иң соңгы кат
Суырып үптең дә син кузгалдың.
Таң алдыннан баткан ай шикелле,
Бик еракта калдың, югалдың...
Яна бәгырем, яна йөрәгем,
Баса алмыйм аның януын.
Төшләремә кереп иркәлисең,
Җанкисәгем, бәгырем Бануым.

Әсирлек богаулары кигәч, бәхетсезлекне бергә күтәреп барган иптәшләренә Муса әүвәлгечә бер җылы сүз әйтеп калдырырга тырыша, иптәшләренең күңеленә бер нур сирпеп китә. Бу аның олы җанлылыгын, кеше язмышын үз күреп, йөрәгенә алып яшәвен күрсәтә торган факт. Моабит дәфтәрләрендәге:

Читен дә соң артык һичбер вакыт
Көрәшмәсне сизеп аерылу;
Мәхәббәт һәм дуслык җир йөзендә
Булган чакта бөтен байлыгың, —

дигән юлларның тирән мәгънәсе бар. Һәм ул «Аерылу» исемле шигырьдә дуслыкның тылсымлы көчен гаять матур итеп, кайнар сулыш белән сурәтли. Чуссний лагерендә очраган Гариф Хафизовка «Гариф дуска» исемле шигырен яза. Бу «Истәлекләр» китабында басылган. Рушат Хисаметдиновка да ул истәлек язып бирә. Моабит дәфтәрләрендә аның бөтен дөньяга танылган «Дуска» шигыре бар. Аның Абдулла Алишка багышланган булуын беркем шик астына алмый. «Саубуллашу» шигыренең бер камерада утырган дус тарафыннан язылуына ышанырга кирәк. Димәк, аның авторы чыннан да шагыйрь? Әйе, шагыйрь. Ә соң Муса Франкфуртта булганмы? Монысын

ачыкларга безгә Фәйзелхак Мингалин булыша. Берлин төрмәсендә утырганда, прогулка вакытында Мингалин белән Муса Җәлил очрашалар һәм ул аңа төрмәдән чыккан тәкъдирдә Франкфуртка барырга, анда икенче вокзал янында сыра заводын табарга һәм баракларның берсенә кереп, Шилов исемле кешене сорарга куша. Димәк, Мусаның Франкфурттагы төрмәдә утырган булуы да, шәһәрдә бәйләнеш тота торган дуслары булуы да бик мөмкин. Рәхим Саттарның шигырен әйтеп яздыруына да гаҗәпләнмәскә мөмкин. Алар инде бер-берсе белән Вустрауда (Берлин тирәсе) очрашкан булганнар.

Бакый Абдрашитовның хәтерендә калган тагын берничә шигырьне укып карыйк. Беренче карашта алар сагаерга мәҗбүр итәләр, чөнки рифма да, ритм да чын шагыйрьнең иҗатына охшамыйлар, алар җимерелгән. Поэтик бизәкләр дә төссезләндерелгән — башка прозаик сүз белән алыштырылган. Моның өчен Абдрашитов гаепле түгел, билгеле, заман, вакыт... Бәлки, аларны төгәлләүчеләр табылыр, хәтергә төшерүчеләр килеп чыгар, төзәтерләр, ачыклык кертерләр. Арада «Авыру сызмалар» шигырен хәтерләткән авыр тойгы белән язылганнары да бар. Аның берсе «Газап чигү» дип атала:

Мин туганда дәрья дулкынланып,
Сулар кире якка аккандыр.
Әнкәй мине газап чиксен өчен
Бер дөмеккән төндә тапкандыр.
Нәрсә өчен яшьли газап чигәм
Ялгызлыкта, кайгы-хәсрәттә?
Нигә күпләр шулай шатланышып
Көн итәләр ирек, рәхәттә?
Әллә мин бер көзге кара төндә
Кеше канын коеп кайттыммы?
Я булмаса, явыз юлбасардай,
Кеше малын талап саттыммы?
Минем ирек тә юк, рәхәт тә юк,
Яшьлек үтә төрмә эчендә.
Рәхәт килер! диеп күңел уйлый
Көннәр буе, һаман, кичен дә.

## ЮГАЛМАС

Нинди кайгы эчендә булса да,
Барын җингән кебек кылана.
Үз иленә кайтып, туганнары белән
Рәхәт тормыш итү уенда.
Туган иле, сөйгән халкы өчен
Батырларча егет көрәште.
Ләкин дошман аны сизеп алып
Җир йөзеннән үзен юк итте...
Юк, юк! Бу бит фәкать хыял гына,
Һич югалмас Ватан уллары,
Гасырларга аны һәйкәл итеп,
Күтәрерләр калган дуслары!
Даны калыр тарих йөзләренә (битләрендә?),
Халык сөйләр сөйгән батырын.
Сылу кызлар, сагынып, сокланырлар (?)
Югалткандай җәүһәр, алтынын.
Тыныч йокла дустым, каберендә,
Син эзләгән теләк (?) табылыр.
Дошман этләре юк ителеп,
Ил өстендә ал таң кабыныр.

## СӘЛАМ ХАТ

Арысландай ярсып, ерак илдә
Ирек яулап йөргән яшь егет
Мәңге ялгыз хәзер, читлектәге коштай,
Сагынып уйлый, сезгә баш иеп.
Сәлам сиңа, бәгырем, сәлам миннән,
Сәлам сиңа яшьлек ярыңнан,
Сәлам сиңа ерак чит илләрдән,
Сәлам сиңа, бәгырем, зинданнан!

Бер кайтырбыз сиңа, туган илем,
Ирек яулап бәгырем-иркәмә.
Шат елмаеп каршы алырсың син,
Зәңгәр шәлең салып җилкәнә.
Оркестрлар уйнар җиңү маршын,
Иөрәкләрдә — шатлык дулкыны!
Безгә карап дуслар сокланырлар,
Безне мактап балкыр таң нуры!

Шушы ук шигырьнең беркадәр үзгәртелгән варианты белән безне Гараф Фәхретдинов та таныштырган иде. Радом — Едльня лагерьларында, легионерлар арасында Гараф аны җырлап йөргән һәм «Сәлам сиңа» дип башланган строфаны кушымта итеп кулланганнар. Кушымта югарыдагы вариантта сөйгән иркәсенә, ялгыз кешегә багышлануга карамастан (Гараф вариантында ул дус егетләргә мөрәҗәгать итә), моныеының гомуми эчтәлеге көчлерәк һәм юл саны да артык.

Билгеле булганча, Гараф Фәхретдинов — Муса Җәлил белән якыннан аралашкан, Гайнан Курмашов группасында яшерен оешма эчендә актив катнашкан иптәшләрнең берсе. Ул капелланың җырчысы буларак, башкару өчен текстларны Муса Җәлилнең үзеннән дә алган, күбесенчә Гайнан Курмашовтан алган. Капелланың художество җитәкчесе буларак, репертуарны ул карый, аны Муса белән киңәшләшеп төзи һәм башкарырга биргәндә дә, пропаганда өчен таратканда да авторны күрсәтми.

— Гайнан Мусаның шәкерте иде, — дип сөйли Хисаметдинов, — аңардан өйрәнеп, консультация алып яза иде.

Гараф Фәхретдинов безгә утызга якын шигырь, җыр тапшырды. Аларның кайберсе, моны Муса үзе әйтеп торып яздырды, дигәннәре «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы № 5 санында басылган иде. «Таң маршы», «Азатлык маршы», «Кайту маршы», «Үлгән улыңнан хат», «Язлар килер», «Соңгы сүз».

Гараф тапшырган «Вислага», «Шагыйрь» шигыре вариантлары да матбугатта тиешле чагылыш таптылар инде. Шуңа күрә аларга тукталып тормаска мөмкин. Шуны әйтергә кирәк, ул шигырьләр басылып, халыкка таралганнан соң, бер җирдән дә «бу Муса шигыре түгел» дигән хат-фәлән килмәде. Аларны башка телләргә тәрҗемә итү вакытлы булыр иде.

Фәхретдинов хәтердә саклаган бик күп җырларның кигезендә халык җырлары ята, алар, көрәш шартлары таләбенә туры китереп, бераз үзгәртелгәннәр, аерым төскә кертелгәннәр. Мәсәлән, Тукай маршына:

Кояш нуры нигә кирәк,
Күрер күзең булмагач,
Күз яшьләрең ник түгәсең,
Каршы көрәшә алмагач, —

кебек җыр чыгарганнар.

Яки:

Сахраларга чыксам, ялгыз башым,
Чулпан йолдыз минем юлдашым,
Чулпан йолдыз булса, ай, юлдашым,
Мең дошманга тора бер башым, —

дип җырлый идек, ди Фәхретдинов.

Гараф үзендә булган җыр-шигырьләрнең күбесен Муса яки Курмаш шигырьләре дип кистереп әйтә алмый. Блокноты юкка чыгу аркасында, ул аларны хәтергә төшереп язган һәм шуңа күрә кайбер шигырьләр икенче исемдәге шигырьләр белән тутырылган кебек сизеләләр. Җырчының хәтере яхшы була, шулай да җырчы Гараф барлык җыр-шигырьләрне дә истә калдыра алмаган, аларның кайбер сүзләре онытылган яки строфалары белән үк истән чыккан. «Әнкәема» дигән шигырьнең ул 2—3 строфасын хәтеренә төшерә алмый. «Ант» исемле шигырь дә шактый таушалган һәм аңа һәркемнең кулы тигән кебек тоела.

Анда шундый юллар бар:

Туган илем, синең ялкыныңның
Чаткылары белән янармын.
Чәчрәп чыккан ялкын үзәгенең
Чаткысы дип үзем санармын...

Бөек илем! Кайнар яшең түгеп,
Көткәнсеңдер ярдәм улыңнан.
Ант итәмен, илем, кире кайтмам
Син өйрәткән тормыш юлыннан.

«Дулкын» исемле шигырьдә дә икенче шигырьдән кергән юллар бар тосле, шуңа күрә аның үзеген генә күчереп китик:

Мин еракта, Балтик ярларында,
Чайкаламын дулкын эчендә.
Калмас идем, кире китәр идем,
Әгәр булсам дулкын көчендә (?)

Әй, син, дулкын, уйнаганың карап,
Йөрәк серем белән әйләндем.
Алып киттең ерак, тозак салып,
Балтик ярларына бәйләдең.

«Сине сагынам» (Иркәмнән хат) исемле шигырь турында бер-ике сүз. Гарәф аны эстрада да башкару өчен Гайнан Курмашовтан алган.

— Ләкин мин аның кем шигыре икәнен белмим, барлык җыр-шигырьләрне Муса абый карап уздыра иде ич. Башкару алдыннан алар, менә монысын сөйлә, монысын җырла, дип күрсәтмә биреп торалар иде.

Бу шигырь Т. Гыйммранов блокнотында да бар, үзгәреш берничә сүздә генә. Менә ул шигырь:

Тын далада үскән ак каеннын
Яфраклары тавышын тыңладым.
Аңа охшатып татар кызкаеның
«Сине сагынам» җырын җырладым:

«Ирек өчен үткен кылыч тагып,
Намус өчен мылтыгын асып,
Китте минем бәгырем сугышка,
Юл салырга матур тормышка.

Мин көтәмен бары көн саен,
Дан казанып аның кайтуын.
Озак көткән бәхет кояшының
Безнең өстә тагын калкуын.

Йөрәгемдә сөю хисләрем,
Синең өчен, батыр көрәшчем.
Хезмәт белән күмеп үземне,
Үткәрәм мин яшьлек гомерем,

Кайт, бәгырем, җиңеп дошманны,
Тетрәтеп утлы яуларны,
Сине сагынам, минем күз нурым,
Бул гомергә тормыш йолдызым».

Нокта куярга һәм ныклы нәтиҗә чыгарып сөйләшергә хәзергә иртәрәк кебек тоела. Мусаның өченче дәфтәре табылса, Ланфредини әйткән сүзләр чын булып, җәзалап үтергәндә камерада калган нәрсәләр килеп чыкса (ә ул соңгы сулышына кадәр язган), бәлки, күп нәрсә ачыкланыр. Төрмә надзирательләренең берсе Көнбатыш Германиядә бер ресторанда эшли, имеш, дип хәбәр килгән иде. Без ул кешене хат аша юллап карадык, тик хәзергәчә нәтиҗәсе булмады. Шулай да көтмәгәндә яңа язмалар табылуына өмет юк түгел.

Безнең кулда булган шигырьләрнең кайберсе Гайнан Курмашовныкы, аның стиле үк үзенчәлекле, ә кайберсе күмәк иҗат булырга мөмкин. Кабатлап әйтсәк, көрәшчеләр өчен авторлыкны саклау мөһим нәрсә булып исәпләнмәгән, бәлки, кешенең намусын тәрбияләү, туган илгә тугрылыклы итеп калдыру күздә тотылган. Шуңа күрә булган һәм тупланган шигырь-җырларны көрәшчеләрнең уртак иҗаты итеп карыйсы килә һәм алар көрәшчеләргә рухи бер һәйкәл булып әверелерләр төсле тоела.

**МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ**

*Рафаэль Мостафин*

# ТАЛАНТ ҺӘМ ХЕЗМӘТ

Язучылык хезмәтеннән кала, башка бер генә һөнәр кешеләре турында да адәм ышанмаслык легендалар бу кадәр сөйләнмидер, дөреслектән шактый ерак торган берьяклы карашлар болай күп таралмагандыр, мөгаен. Берәүләргә язучылык хезмәте күңел ачу кебегрәк үтә гади һәм җиңел бер нәрсә булып күренә. Килдең, күрдең, яздың — вәссәлам. Икенчеләр исә, киресенчә, иҗат сәләтен берничек тә аңлатып булмый, бары тик сирәк кешеләргә генә бирелә торган гадәттән тыш тылсымлы көч дип уйлыйлар. Хәлбуки, бу карашларның һәр икесе хакыйкатьтән бик ерак тора.


Язучылык хезмәтен аңлауда шундый капма-каршы карашлар яшәп килгәнгә күрә дә, безгә, матбугатка чыккан әзер әсәрләр турында сөйләү белән бергә, әдипләрнең иҗат процессларын да өйрәнергә, тикшерергә кирәк. Бу, берьяктан, әдәби алмаш тәрбияләү, язучыларга үзара тәҗрибә уртаклашу өчен файдалы эш булса, икенче яктан, киң катлау укучылар массасы өчен дә кирәк: шул юл белән генә укучыларны язучы хезмәтен дөрес аңларга һәм аңа хөрмәт белән карарга өйрәтергә мөмкин. Бу мәкаләдә мин, сөекле шагыйребез Муса Җәлилнең иҗат эшчәнлеге мисалында, әлеге катлаулы мәсьәләнең кайбер якларына тукталмакчы булам.

* * *

Үзенең төп эшеннән — язучылык хезмәтеннән — тыш башка берни белән кызыксынмаучы әдипләр дә була. Муса Җәлил андыйлар рәтенә керми: ул беркайчан да профессиональ әдәбиятчы, «саф шагыйрь» генә булмаган. Язучылык эшеннән тыш, гомер буе кайда да булса хезмәт иткән, еш кына берьюлы ике-өч урында эшләгән, шул ук вакытта зур җәмәгать эшчәнлеге дә алып барган.

20 еллар азагында, Мәскәүгә күчеп килгәч, ул, мәсәлән, бер үк вакытта Мәскәү дәүләт университетында укый, «Кечкенә иптәшләр» исемле балалар журналында редактор һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Татар-башкорт секциясендә бюро члены була. «Кечкенә иптәшләр» журналы редакциясендә, аның үзеннән тыш, бары бер әдәби сотрудник эшләвен исәпкә алсак, редакторлык вазифасы шагыйрьдән күпме вакыт, көч һәм энергия таләп иткәнлеген күз алдына китерү артык кыен булмас кебек. Укучы хатларына җавап язудан корректура укуга кадәрге барлык эшне аның үзенә башкарырга туры килә. Шулар янына Мусаның тау хәтле җәмәгать эшләрен кушарга кирәк. Татар-башкорт секциясенең бюро члены булып эшләү белән бергә, ул тагын Мәскәүдә чыга торган «Яшь эшче» журналының редколлегия члены һәм Халык мәгариф комиссариатының азчылык милләтләр советында ВЛКСМ Үзәк Комитеты вәкиле дә. Муса халык алдында төрле темаларга докладлар укый, лекцияләр сөйли, авыл хуҗалыгы эшләре вакытында партия оешмасы аны колхозларга җибәрә. Әдәбиятка яшь алмаш әзерләү юлында да ул күп тырышлык күрсәтә. Мәскәү яшьләренең Муса Җәлил җитәкләгән иҗат түгәрәгеннән соңыннан танылган журналистлар, язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләре чыкты. Күренекле язучыларыбыздан Габдрахман Әпсәләмов — шул түгәрәктә тәрбияләнүчеләрнең берсе.

Университетта уку үзе күп вакыт сорый. Муса атаклы профессорларның лекцияләрен тыңлый, кичләр буе уку залыннан чыкмыйча, семинар дәресләренә, зачетларга һәм имтиханнарга хәзерләнә, докладлар яза... Кайчагында шулкадәр эшләрне 22 яшьлек бер егетнең башкарып чыга алуына ышанасы да килми. Монда



М. Җәлил «Октябрь баласы» журналында. Сулда журналның художнигы Красильников.

игътибарга лаеклы, иң әһәмиятле әйбер шул: халкыбыз, илебез тормышына шулай якыннан катнашып яшәү М. Җәлилнең иҗат эшчәнлегенә бөтенләй комачауламый, киресенчә, аны тагын да күтәреп, активлаштырып җибәрә. Шагыйрьнең бөтен иҗат гомере шул турыда сөйли. 30 еллар ахырында Муса Җәлил Татарстан язучылар союзы идарәсенең председателе итеп сайлана. Бер үк вакытта ул Татар дәүләт опера һәм балет театрында әдәби бүлек мөдире, шәһәр советы депутаты буларак, күптөрле җәмәгать эшләре дә алып бара. Шагыйрьнең бу еллардагы тормышы турында Г. Кашшаф болай яза: «Муса Җәлил һәрвакыт берәр эш белән мәшгуль булыр, һәрвакыт бер оешмадан икенчесенә ашыгыр; ул һәркемгә кирәк, аны урамда да, берәр оешманың коридорында да, матбугат йортында да туктаталар һәм озак җибәрми торалар. Каршы килергә, тыңламый китәргә базмаганга, ул драматург һәм артист, шагыйрь һәм композитор, журналист һәм тәрҗемәче, эшче һәм хезмәткәр, сайлаучы, студент, укытучы, кыскасы, кем туктата шуның белән әңгәмә алып барырга мәҗбүр. Кеше белән сөйләшкәндә, аның акыллы карашы кайдыр еракка төбәлгән була, беренче карашка, ул сине, ничектер, теләмичәрәк, таркау тыңлый кебек. Ләкин шунда кинәт,

аңгамадашен игътибар белән тыңлавын һәм аңа ярдәм итәргә әзер торуын күрсәтеп. аның йөзенә я ачу шәүләләре төшә, яки ул рәхәтләнеп, шаулатып көлеп җибәрә.

Ул тормышны ярата иде, һәм кайда яңалык өчен көрәшкә көрәш барса, ул шунда ашкынды. Муса, комсомолларга хас ашкыну һәм кайнарлык белән, көрәшкә ыргылып яшәде, үзенең көчле, эмоциональ шигырьләрендә зур ләззәт белән шул көрәш турында сөйләде».

* * *

Шулай баштанаяк тормыш эчендә кайнаган, исәпсез-хисапсыз җәмәгать эшләренә күмелгән кеше язарга, иҗат итәргә ничек вакыт тапкан соң? Бу сорауга җавапны шагыйрьне яхшы белгән, аның иҗат итү, эшләү үзенчәлекләрен якыннан күзәткән кешеләр бирә ала.

«Гел ыгы-зыгы эчендә кайнаганга, — дип яза Ә. Җәлилова, — ул теләсә нинди шартларда: эш урынында да, урамда йөргәндә дә, кешеләр белән сөйләшеп торганда да иҗат итәргә гадәтләнгән иде».

Шул ук фикерне Г. Кашшаф та куәтли:

«Ул теләсә кайда, теләсә нинди урында эшли ала иде... Үткен эпиграммаларын, төрле мәсьәләләргә багышланган шигъри шаржларын ул җыелышларда, киңәшләрдә, хәтта кунак мәҗлесләрендә дә иҗат итә. Әзер әйберләрен тәмәке кәгазьләренә, обой кырларына, әйбер төрә торган кәгазь кисәкләренә күчерә. Башында туган фикерләренең эзен җуймаска, күңелендәге шигъри хисләрен куып җитәргә теләгәндәй, ашыгып язар, күбрәк гади карандаш белән генә язар. Шулай ашыгып-кабаланып эшләгәндә, еш кына язылган кәгазь битләренә номер сугарга, бит саннарын күрсәтергә дә оныта».

Даими рәвештә киеренке иҗат эшчәнлеге белән яшәү Мусада үз-үзен онытучанлык, «оешмаганлык» кебек бик үк әйбәт булмаган гадәтләр дә тудыра. Иптәшләре шагыйрьнең бу сыйфатларын яхшы белгәннәр. Шуның өчен дә, урамда очрашып үзганда Муса алар белән исәнләшмичә, хәтта бөтенләй күрми үк китә икән, алар моның өчен үпкәләмәгәннәр: бу минутларда ул тулысынча образлары дөньясында яшәгән. Әмма, шул сыйфатлары аркасында, аның үзенә һәм якыннарына күп тапкырлар шактый уңайсыз хәлләрдә калырга да туры килгәләгән.

Шулай бер вакыт, «Алтынчәч» операсын язганда, Муса композитор Асафьевның шәһәр читендәге дачасына өйдә киеп йөри торган тапочкалардан барып керә. Тагын шул кадәресе дә бар: эш белән мавыгып, башта моны берсе дә күрмиләр. Инде киредән өйгә кайтырга җыенгач кына, Мусаның нинди хәлдә килүе ачыклана.

Икенче вакыт Муса кайдадыр портфелен калдырып кайта һәм берничә көн, ни эшләргә белми аптырап йөри. Ярый әле, ахыр чиктә, портфель шулай да табыла. Юкса, ел буе көч куеп, тырышып эшләгән хезмәт бер файдасызга әрәм булыр иде. Эш урынына да, театрга да һәм хәтта үз операларының репетицияләренә дә Муса еш кына соңга калып килә торган була. «Алтынчәч»не сәхнәгә әзерләгәндә режиссер Баратов: «Мусаның 11 гә килеп җитүен телисез икән, аны иртәнге тугызга чакырыгыз», — дип шаярта иде, диләр.

Мусаның «оешмаганлыгы» аркасында бигрәк тә Әминә күп җәфа чигә. Әйтик, алар кая да булса барырга планлаштырганнар. Әминәнең бөтен эше беткән, ул күптән әзер. Муса исә әле һаман да өстәл артында. Кызу-кызу нәрсәдер яза, инде язып бетерә генә дип көткәндә, бөтенесен сызып ташлый да, яңадан тотына. Үзе, Әминәнең ашыгырга, тегеләргә кушып әйткән сүзләренә җавап биреп, «хәзер, хәзер!» диган була. Ниһаять, вакыт тәмам җитеп, көтәргә түземлеге беткән Әминә, чыгып китәргә дип, ишек тоткасына тотынгач кына, өстәл артыннан атыла-бәрелә Муса тора, язган әйберләрен кабалана-кабалана портфеленә тутыра башлый...

Бервакыт Муса Әминәдән «Севиль чәчтарашы» исемле операның клавирын күчереп бирүен сорый. Бу эшкә Әминә күп вакыт бирә, зур көч куя. Һәм аның кичләр, төннәр буе йокламыйча башкарган шул эшен, көннәрнең берендә, Муса кайсыдыр бер троллейбуста калдырып кайтмасынмы. Хәер, моның өчен үзенең дә бик нык кәефе кырыла. Шул очрактан соң, тагын берәр әйберсен онытып калдырудан куркып, ул трамвай-троллейбусларга утырудан бөтенләй баш тарта: җәяү генә йөри башлый.

Шагыйрьнең үз сүзләренә караганда, язасы әйбер күңелендә тәмам туып, ачыкланып җитмичә, Муса өстәл янына утырмаган. Аның каравы, бер утыргач, мавыгып, илһам һәм бетмәс-төкәнмәс иҗат дәрте белән, гаҗәп дәрәҗәдә кызу һәм ашкынып эшләгән. Менә шуңа кайбер кешеләр Муса шигырьләрен бик ансат һәм җиңел яза иде, дигән карашта торалар да инде. Шигъри рифмаларны тиз һәм ансат таба алуы белән аерым очракларда Муса үзе дә горурлана торган була. Балалык дусларының сөйләвенә караганда, җыр яки шигырь чыгару сәләте Мусада кече яшьтән үк көчле була.

«Һавада очып барган кошны күрдеме, аның турында шигырь чыгара иде», — дип сөйли Мусаның авылдашы Гобәйдә Даутова.

30 еллар азагы булса кирәк. Якты, җылы июнь тәнендә, Мусалар, җыйнаулашып, дачадан Казанга кайтып киләләр. Тумыштан шат күңелле Муса юл буенча шаярып кайта. Анекдотлар сөйли, рәхәтләнеп көлә, башкаларны көлдерә, «Алтынчәч» операсыннан аерым өзекләр уйнап күрсәтә. Шулай шаярып кайтып килгәндә, юлдан бер кәгазь кисәге табып ала бу. Карасалар, мәхәббәт хаты, кемдер төшереп калдырганмы, әллә кирәксезгә санап, ташлап киткәнме?.. Муса, башта көлә-көлә, хатны кычкырып укып чыга һәм шунда ук, әлеге хат уңае белән, «Югалган хат» исемле шигырь иҗат итә.

Тагын бервакыт Галия Кайбицкаяга, имтиханда башкару өчен, композитор Верди операсыннан Леонора ариясенең татарчасы кирәк була. Һәм ул, ярдәм сорап, Муса Җәлилгә мөрәҗәгать итә.

«Муса тиз генә сәгатенә күз төшереп алды, ә аннан, гадәтенчә, ягымлы итеп бер елмайды да, — ди артистка, — күп булса ярты сәгать вакыт эчендә шактый катлаулы арияне тәрҗемә итеп тә бирде». Татар опера студиясе артистлары, теге яки бу романсны, җыр яки арияне тәрҗемә итүен сорап, Муса Җәлилгә еш мөрәҗәгать иткәннәр. Муса бервакытта да аларның үтенечләрен кире какмаган, күп очракларда «заказчикның үзе янында ук» әйбәт тәрҗемәләр эшләп биргән. Еш кына күп вакыт һәм зур көч сорый торган күләмле әсәрләрне дә Муса Җәлил искитәрлек дәрәҗәдә тиз иҗат итә алган.

Шагыйрь турындагы истәлекләрендә Г. Кашшаф бик кызыклы шундый бер мисал китерә. 1938 елда татар шагыйрьләре, комсомолның 20 еллыгына багышлап, коллектив поэма язарга булалар (ул елларда андый әсәрләр язу шактый модада була). Поэманың төп бүлекләреннән берсен язу эше М. Җәлилгә тапшырыла. Идел буендагы иҗат йортында коллектив поэма язучы шагыйрьләр өчен уңай шартлар тудыралар. Һәм бик кыска бер вакытта — нибары 15 көн эчендә — эшне дә төгәлләргә кирәк була.

«Эш гөрләп барды, — дип яза Гази Кашшаф, — шагыйрьләр, үзара очрашканда, кемнең күпме эшләве турында да сөйләшә башладылар, берәүләр, каралама хәлендә төгәлләп, тәзәтергә, эшкәртергә дә керешкәннәр иде инде. Бер Муса гына һичнәрсә язмый, көннәр буе көймәдә йөри, пляжда кызына, урманнарда, алма бакчаларында йөри, волейбол уйный, колхозчылар белән сөйләшеп утыра, балалар белән шаяра. Беркем аның кулында каләмдер, кәгазьдер күрмәс. Бу хәлгә башкалар инде борчыла да башладылар. Чынлап уйлаганда, борчылырлык та бит: поэмадагы иң җаваплы бүлекнең әле бер генә юлы да язылмаган. Бер көнне, төшке ашка җыйналгач, кайсыдыр:

— Муса, без инде эшне төгәлләп киләбез, ә син һаман сузасың... Син болай безне дә тоткарлыйсың бит, — дип әйтеп куймасынмы.

— Минем инде күптән бөтенесе әзер, — ди бу, бик тыныч кына.

Берәүләр бик нык гаҗәпләнде, икенчеләр моны шаяруга санады, өченчеләр исә, ышанырга да ышанмаска да белмичә, иртәгә үк кульязмаларыңны күрсәт, дия башладылар. Муса риза булды.

Һәм ул бер төн эчендә план буенча үзе язарга тиешле 400 юл шигырьне дәфтәргә күчереп бетерә! Мусаның архивында бу дәфтәр хәзер дә саклана: тагын шунысы гаҗәп, тикшерү вакытында шагыйрьләр Муса язган бүлеккә бернинди үзгәртүләр кертмиләр, ничек язылган булса, ул шулай басылган да. Баксаң, Муса үзенә кирәкле поэтик буяуларны һәм әдәби образларны, бүлмә тынлыгында эзләмичә, табигать кочагында, җанлы кешеләр арасында тапкан икән».

* * *

Ләкин Муса Җәлил бөтен әсәрләрен дә шулай җиңел генә иҗат итмәгән. Күпчелек әсәрләре өстендә ул кайта-кайта, озаклап һәм җентеклап эшләгән. Күп төрле җәмәгать эшләре башкарып бик нык арыганнан соң, 1935 елның башында Муса ике айга ял ала. Язучыларның иҗат йортында уздырган шул айларда ул, дусты Җ. Фәйзи исеменә җибәргән хатында зур горурлык белән хәбәр итканчә: «Директор һәм кояш» исемле 730 юллык күңелле поэма, «Гөлҗамал яки сыңар галош» исемле 6 картиналы комик пьеса, «Җиһан апа» исемле 350 юллык сюжетлы шигырь һәм тагын берничә шигырь» яза. Кыска гына бер арада мең юлдан артык шигырь һәм тулы бер пьеса! Тагын кайсы язучыда шундый иҗат темпы табылыр икән?!

Монда тагын менә нәрсә игътибарга лаек. Шушы ике ай вакыт эчендә язылган әйберләренең берсен дә шагыйрь матбугатта бастырырга ашыкмаган. 1938 елда, ягъни өч ел гомер үткәч кенә, яңадан эшкәртелеп, тулы канлы поэма дәрәҗәсенә җиткерелгән «Җиһан» әсәре басыла. «Директор һәм кояш» исемле поэма белән «Гөлҗамал» пьесасы исә шагыйрь үлгәннән соң гына беренче мәртәбә дөнья күрәләр. Менә шунда инде безнең алда шагыйрь иҗатының тагын бер үзенчәлеге ачыла. Язасы әсәре күңелендә тәмам формалашып, ачыкланып җитеп өстәл янына утырганда, Муса бик кызу, ашкынып иҗат итә. Ләкин, кагыйдә буларак, язган әйберен матбугатка бирергә, бастырырга ашыкмый: әзрәк суынгач, аек күз белән кабат карар өчен, бераз вакытка өстәл тартмасына салып куя. Еш кына шул ук әсәрне яңадан эшләп чыга һәм тагын «суынырга» сала. Муса архивында кайбер әсәрләрнең дистәләрчә вариантлары бар. «Алтынчәч» либреттосы, мәсәлән, унбер мәртәбә төзәтелгән. Муса күп кенә әсәрләрен бөтенләй эшләнеп беткәннән соң да еллар буе бастырмый тора.

«Хат ташучы» поэмасы, инде тәмам эшләнеп беткәч тә, авторның хөкемен көтеп, ике еллап өстәл тартмасында ята. Күп кенә әйберләре исә Муса үзе исән чакта дөнья йөзен бөтенләй күрми калалар. «Мусаның васыятендә үзем исән чакта язылган әйберләремнең күп булса утыз-утыз биш процентын гына бастырдым, дигән юлларны укыгач, мин бик нык гаҗәпкә калдым», — дип яза Г. Кашшаф үзенең истәлекләрендә. Гаҗәпләнерлек тә бит, исән чакта Муса болай да актив басылучы шагыйрьләр рәтендә йөргән. Күп санлы тәрҗемәләрен, мәкаләләрен, рецензияләрен һәм рус телендә чыккан җыентыкларын санамыйча да, Муса уннарча либретто һәм пьеса, шигырь һәм поэма җыентыклары авторы була. Инде Мусаның архивын якыннан өйрәнә башлагач, Г. Кашшаф васыятьтәге сүзләрнең, чыннан да, дөрес икәнлегенә ышана. Муса Җәлилнең 1955—56 елларда чыккан сайланма әсәрләренең беренче томы яртылаш диярлек, ә өченче томы тулысынча үз вакытында матбугатта чыкмаган әсәрләрдән төзелгән. Шуның өстенә, Мусаның барлык кульязмалары инде табылып бетте дип расларга бик иртә бит әле.

* * *

Без т а л а н т сүзен артык еш кулланабыз һәм бу турыда бик күп язабыз. Ләкин бер нәрсәне онытабыз, беркем дә, хәтта зур талант иясе дә, тырышмыйча, көнтөн эшләмичә үсми, алга китә алмый. Мусаның иҗат практикасы бу фикернең никадәр дөрес булуын артыгы белән раслап тора. Тышкы яктан карaганда, никадәр генә «оешмаган, таркау» булып күренмәсен, төбендә ул бик җыйнак, максатка омтылышлы һәм нык ихтыярлы кеше була. Үзенең бөтен гомерен ул олы бер максатка багышлый, зур тырышлык һәм ныклык белән, шул максатын тормышка ашыру өчен көрәшә. Мусаның гадәтләнгән, бер дә бозмыйча саклый торган көндәлек эш режимы бар иде, дип сөйли Әминә Җәлилова. Кагыйдә буларак кичке 4—5 ләрдән дә соңга калмыйча, ул эштән кайта һәм шунда ук йокларга ята. Көндезге йокы эш ыгы-зыгысы белән арган башка ял, яңадан иҗат эшенә тотынырлык көч бирә. Шулай йоклап, бераз хәл җыеп алгач, кичке 8—9 ларда Муса язарга утыра.

«Бу вакытта инде,— дип яза Ә. Җәлилова,— безнең Мәскәүдәге бүлмәдә тынлык урнаша. Ук квартирадагы ук семья, кичке ашны ашап, ял итә. Күрше бүлмәдә ишек тавышы да сирәк ишетелә башлый. Безнең Чулпан йоклый. Зур коридордагы тавышлар тына. Көндез туктаусыз шаулап торган кухня да тынып кала». Бер дә күзгал-

мыйча диярлек, иртәнге 5—6 ларга кадәр Муса язу өстәле артында утыра. Иртән торуга болай да кечкенә бүлмәдә аяк басарлык та урын калмый: урындыклар, өстәл өсте, тәрәзә төбе язылган кәгазь битләре белән тулган була. Бер-ике сәгать йоклап, хәл җыйгач, Муса, торып, иртәнге зарядканы ясый һәм, һәрвакыттагыча күтәренке күңел, җыйнак өс-баш белән, көндәлек эшенә китә. Һәм бу режим бер дә үзгәрмичә саклана, эштә күпме генә армасын, кайтып бер-ике сәгать ял итеп алуга, яисә һавада йөреп керүгә, ул яңадан төн буена иҗат итәргә утыра. Иптәшләре белән уздырган һәм бик сирәк эләгә торган күңел ачу сәгатьләрен исәпләмәгәндә, Мусаның бөтен гомере киеренке хезмәттә үтә. «Тазалык әнә кайчан кирәк булган икән: сәламәтлеге йомшак кеше шулай көн-төн эшләүгә түзә алмас иде»,— дип язды ахырдан Ә. Җәлилова, бу мәсьәләгә тукталып. Хәтта Моабит төрмәсендә яшәгәндә дә, җан өшеткеч җәзалар һәм допрослар тукталып, фашист следовательләре аз гына тынычта калдыруга, Муса, ныклы бер тәртип белән, иҗат эшен дәвам иттерә. «Камера тормышы бер көенчә уза торды. Иртәнге алтыда йокыдан торгызалар. Муса беренче булып уяна. Уянгач, салкын су белән тәннәрен ышкый, юына һәм иртәнге зарядканы ясый. Шуннан ашарга китерәләр. Иртәнге 9 лар тирәсендә һавага алып чыгалар. Камерага әйләнеп кайтуга, Муса тизрәк язарга утыра. Яза-яза да, күп битләрне ертып ташлый. Ерткannan калганнарын яңадан күчерә һәм шулай төшке аш вакытына кадәр эшләп утыра. Төшке ашны көткән арада Муса белән төрле темаларга әңгәмә алып барабыз. Бирелгән шулпаны эчеп алгач, сәгать икеләргә кадәр ял итәбез. Шуннан Муса тагын иртәнге эшенә тотына. Язылган битләр саны торган саен арта бара. Ул аларны, кайта-кайта, укып карый, ерта, кабат яза һәм, вакыт-вакыт, язган әйберләрен куен дәфтәренә күчерә... Аңарда язу эшенә читтән тыш һәвәслек бар иде». (А. Тиммермансның П. Чумакка язган хаты. «Огонек» журналы, 1957 ел, 18 сан, 7 бит.)

Язарга һәвәслек... Беренче карашка беркатлырак яңраган бу сүзләрдә тирән мәгънә бар. Әйе, иҗат эшенә ашкынып тору — Муса Җәлил шәхесен характерлаучы төп сыйфатларның берсе. Иң каты җәзага хөкем ителеп, үлем белән күзгә-күз очрашкан чагында да ул йөрәгендә тулган хисләрен кәгазьгә төшерерлек зур көч, эчке ихтыяҗ тоя. Мусаның бөтен гомере буена башкарган фидакарь хезмәтен без дан, акча артыннан куу дип тә, шагыйрьлек бурычын үтәү өчен генә башкарган эш дип тә карый алмыйбыз. Ул йөрәге кушканга, язмыйча яши алмаганга күрә язган!

1944 елның августында Шпандау төрмәсендә А. Тиммерманс тагын бер тапкыр һәм соңгы мәртәбә Муса Җәлил белән очраша. Төрмә душында бергә юынырга туры килә аларга. Шул чак Тиммерманс Мусага дәфтәрен ышанычлы кулларга тапшырылды, дип пышылдый. «Ул бәхетле иде!» — ди А. Тиммерманс.

Бәхетле иде... Һәр көн саен үлем көтеп яшәгән кеше турында шундый сүз әйтү үзе үк, ничектер, сәер яңгырый. Әмма бу, чыннан да, шулай бит. Моабит төрмәсендә ятканда, читтән тыш газаплар күрү белән бергә, Муса Җәлил иң зур шатлык хисе — иҗат шатлыгы да кичерә.

* * *

Җәлил шигырьләре астына куелган даталарны тикшерә торгач, тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Г. Кашшаф шагыйрь иҗатының тагын бер үзенчәлеген ача. Аның шигырьләренең зур күпчелеге, шуның өстенә, сәнгатьчә иң көчле эшләнгәннәре, яки пленга эләгүенең беренче айларында, яки үлем карары чыгарылганнан соң язылганнар. 1942 елның ноябреннән 1943 елның августына кадәр, ягъни «Идел-Урал» легионында уздырган 9 ай вакыт эчендә, М. Җәлил нибарысы унлап шигырь язган. Ә инде 43 елның сентябрь-декабрь айларында, ягъни барысы 4 ай вакыт эчендә, ул 65 исемдә мена дигән шигырь иҗат итә. Күрәсез, легионда эшләгән чорда аена бер, инде үлем җәзасы көтеп төрмәдә ятканда һәр ике көн саен бер шигырь туры килә. Шушы фактларга таянып, Г. Кашшаф бик тә дөрес бер нәтиҗә ясый. Димәк, нәкъ менә иң хәтәр айларда шагыйрьнең иҗат активлыгы бермә-бер көчәеп китә, тормышының киеренке моментларында ул аеруча тиз һәм кызу, илһамланып эшләгән икән. Бу күзәтү Җәлилнең элекке, баштагы чор иҗат эшчәнлеге белән дә туры

кила. 1942 елның кышында, эшсезлектән аптырап резервта йөргәндә, Муса юньле-башлы бернәрсә дә язмый диярлек, инде Волхов фронтына эләгеп, бер минут та буш вакыты калмый башлагач, кыска гына ара эчендә ике дистәгә якын мена диган шигырь язып ташлый. Үлем алдыннан язылган «Була кайчак» исемле шигырендә иҗат процессының бу үзенчәлеген М. Җәлил бик матур итеп әйтеп бирә:

Була кайчак гаҗәп күңел каты,
Бернәрсәгә юньләп ис китми.
Үлем җиле исә күңел гөлена,
Яфрагын да ләкин селкетми.

Йөздә бары мәгърур көлемсерәү,
Уйдан ерак дөнья мазасы.
Шул вакытта менә әллә нигә
Тик язасы килә, язасы!..

Үтерсәгез, әйдә, үтерегез,
Котырыгыз аннан, биегез!
Тик шагыйрьгә кара китерегез,
Һәм кулыма каләм бирегез!

* * *

Шагыйрьнең иҗат процессы, эшләү үзенчәлекләре турында сөйләгәндә, алда әйтелгәннәргә өстәп, аның искиткеч яхшы хәтерле кеше булуын да билгеләп үтәргә кирәк. Иншар Әлкәрамова, бала чакта аны шаккатырган, шундый вакыйга турында сөйли. Минзәләдәге хәрби-политик курсларда укыганда, М. Җәлил кичләрен еш кына Иншарларга кереп утыра торган була. Шулай бервакыт, сөйләшеп утыра торгач, Мусаның «Хат ташучы» поэмасы телгә алына. Һәм Иншарнең әнисе поэманы авторның үзе башкаруында тыңларга теләгәнен әйтә. Муса бик теләп риза була, алай гына да түгел, 2300 юллык поэманы, бер генә җирдә дә ялгышмыйча, яттан сөйләп тә чыга. Бу хәлгә кечкенә Иншар гена түгел, хәтта зурлар да гаҗәпкә кала.

— Муса, син әллә һәр шигырьеңне шулай яттан беләсеңме? — дип сорый Иншарнең әнисе.

— Барысын да түгел дә соң, шулай да күбесен беләм,— ди Муса.

Муса, хәтер көченә ышанып, күп кенә шигырьләрен теркәп тә бармаган: кирәк чакта ул аларны кәгазьгә хәтердән күчерә алган. Мусаның бөтен иҗат мирасын тулы хәлендә җыю шуның өчен кыен да инде.

Үз шигырьләреннән тыш, Муса замандашларының меңнәрчә юллык әсәрләрен хәтердә саклаган. Инде үзләре үк күптән онытып бетергән шигырьләрен сөйләп, ул каләмдәш дусларын да бик еш таңга калдыра торган була. Соңыннан Муса Җәлилгә хәтеренең бу әйбәт яклары бик ярап куя. Лагерьдан лагерьга күчереп йөрткәндә, арестлар һәм тентүләр вакытында, ул күп тапкырлар блокнотсыз, куен дәфтәрләрсез кала. Ләкин, беренче җай чыгу белән үк, ул аларны хәтердән кабат кәгазьгә күчерә. Яңадан күчергәндә, шигырьләренең тулы текстларын хәтерләү белән генә чикләнмичә, һәркайсының кайчан, нинди числода язылуына кадәр онытмый. Курган кешеләрнең сөйләүләренә караганда, «Идел-Урал» комитетында эшләгәндә Мусаның һәрвакыт үз янында йөртә торган куен дәфтәре була. Мусаның әлеге дәфтәргә нәрсәләрдер язып баруын һәм аны бик нык саклап йөртүен күргәч, «Идел-Урал» комитетында секретарь булып эшләүче Кунафин дигән бер сатлык җан аңардан:

— Менә бу шигырьләр дәфтәрең югалса, син нишлисең инде? — дип сорый.

— Ул шигырьләр менә монда язылганнар,— ди Муса һәм бармагы белән башына төртеп күрсәтә.

Үзенең һәм иптәшләренең күп санлы шигырьләрен яттан белү белән бергә, аның хәтерендә бик зур белем багажы да сакланган. 9—10 яшьләрендә чагында ук Муса Оренбург шәһәр китапханәсендә булган барлык татар китапларын укып чыга. Китап сорап килгәндә, китапханә эшчеләре аңа нәрсә бирергә дә аптырый торган булганнар. «Мөхәммәдия», «Бакырган», «Йосыф һәм Зөләйха», «Таһир һәм Зөһрә» кебек борынгы әдәбият үрнәкләрен Муса әйбәт белгән, ләкин аның иң яраткан шагыйрьләре Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Мәҗит Гафури була. Муса, бик яшьли, Көнчыгыш

шагыйрьләренең иҗаты белән кызыксына. Тиздән алар иҗаты белән ул шулкадәр кызыксынып китә, Хаям, Хафиз, Руми, Ширази, Р. Тагор кебек шагыйрьләрнең бик күп әсәрләрен хәтердән белә башлый.

Казан рабфагында һәм Мәскәү университетында укыган чорларда Җәлил рус, Көнбатыш Европа әдәбиятларын тирәнтен өйрәнә, иҗтимагый-политик һәм фәлсәфи фәннәрне ныклап үзләштерә, сынлы сәнгатьне, музыканы аңлый башлый. Көнбатыш язучыларыннан Муса бигрәк тә Гейне һәм Гете әсәрләрен яратып укый. 30 елларда М. Максуд Гейне әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү өстендә эшли. Истәлекләрендә бу эшкә ул Мусаның да, якыннан торып, бик актив катнашуы турында язды.

Үләренә санаулы гына көннәр калгач та, Муса Шпандау төрмәсендә Гетенең немец телендә чыккан «Фауст» әсәрен укый. Төрмәгә ул китапны, Мусаның үтенүе буенча, Юрытко дигән бер священник алып килә.

Әминә ханымның сөйләвенә караганда, Җәлилнең иң яраткан композиторы Бетховен була. Бетховенның симфоник музыкасын тирән аңлау белән бергә, Муса аның вокаль әсәрләрен дә әйбәт белгән. Ул Бах, Брамс, Гендель әсәрләрен яратып тыңлаган. Язучының шәхси китапханәсендә Рихард Вагнер, Арнольде Шёнберг һәм башка немец музыкантларының иҗатларына багышланган китаплар сакланган.

Менә ни өчен Җәлилнең түбәндәге шигъри юллары шулай газаплы һәм тетрәткеч яңгырыйлар:

> Шулай дипме сине белә идем,
> Гете белән шашкан чагымда?
> Бетховенның кыю симфониясе
> Ник яңрамый мәрмәр залында?
>
> Хөр йөрәкле Гейне гашыйгына
> Хуҗаң тимер богау кигезде.
> Карл белән Роза каны тамган
> Төрмәләрнең бозын имезде.
>
> Мин күрмәдем синдә кояш нурын,
> Баскан аны канлы тузаның.
> Тик таныдым батыр Тельман яткан
> Подвалларның авыр йозагын.

Югарыда сөйләнгәннәрдән чыгып, без Мусаны үз заманының иң культуралы кешесе иде дия алабыз. Һәм югары культурага, тирән белемгә ия булу аның иҗатына зур уңай йогынты ясаган.

* * *

Муса Җәлил — күпкырлы, үзенчәлекле талант. Зур белем запасы, югары культуралылык һәм көндәлек киеренке хезмәт аңа талантын камилләштерергә, әдәбиятның төрле тармакларында җитди нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек биргән. Муса нечкә зәвыклы лирик та, көчле публицистик шигырьләр авторы да, балалар язучысы, драматург, тәнкыйтьче, либреттолар язучы һәм гаҗәп көчле эпик поэмалар авторы да.

«Алтынчәч» операсы һәм «Хат ташучы» поэмасы, балалар җырлары һәм үлемсез «Моабит шигырьләре» — болар бер татар халкы культурасының гына рухи казанышы булып калмадылар, алар бөтен дөнья культурасының рухи җәүһәрләрен баетуга да җитди өлеш керттеләр. Нәкъ менә шуның өчен дә бөтен җир шарының алдынгы кешеләре Муса Җәлил исемен бүген тирән хөрмәт белән искә ала.

□ □ □

*Гали Хуҗиев*

## Кайбыч урманнарын сагынып

Такташ сөйгән Тамбов урманнарын,
Җан азыгы алган алардан.
Һәм җырлары аша алар даны
Әкияттәге кебек таралган.

Ә мин сезгә гашыйк гомерем буе,
Урманнары туган ягымның.
Төшләремә кереп шаулыйсыз сез, —
Сезне тагын өзелеп сагындым.

Бердәй газиз миңа һәрберегез,
Күрми торсам — җаным ачына.
Язлар саен сезнең һәр бөрегез
Өметләрем кебек ачыла.

Үкендермәс мине үткән гомерем,
Сезне шулай сагынып яшәсәм; —
Язлар саен сезнең иманнәрнең
Бер яфрагы булып яшәрсәм.

## Фәридә Кудашеваны тыңлагач

Фәридәне тагын тыңладык,
Гашыйк булып таныш моңнарга.
Ләкин тагын тыңлап туймадык;
Гаҗәпләнмәс һичкем монарга. —

Үз халкының шатлык-сагышын,
Өмет-хыял, якты язмышын
Сыйдыра алган йөрәк тавышын
Мөмкинмени тыңлап туярга?!

## Җитенкәй

Зәңгәр күзле, сылу җитенкәй,
Дулкынландың нинди җилләрдә?
Ким түгел син бер дә ефәктән,
Ундын болай нинди җирләрдә?

Озакламый, тагын җитәр җәй,
Зәңгәр күзле, сылу җитенкәй,
Дулкынлан син тагын җирләрдә,
Игенчеләр күңеле сөенсен;
Иксез-чиксез бөтен илебез
Уңган кыздай матур киенсен.

Зәңгәр күзле, сылу җитенкәй,
Дулкынлан син тагын җирләрдә...

## Кошлар китә җылы якларга

Кошлар китә җылы якларга...
Юлларына моңсу җыр алып,
Күңелләргә тирән моң салып,
Кошлар китә җылы якларга.
Ә мин синең сәлам хатларга
Зар-интизар булган чакларда,
Канат итеп ике кулымны,
Якын итеп ерак юлымны,
Очар идем алар артыннан;
Куркып түгел кышкы салкыннан.
Очар идем Дунай ягына,
Ил чигенә — синең янына.
Юк, түгел мин ялгыз, бар кошым, —
Мәхәббәтем — гомер юлдашым;
Ышан, иркәм, шуны уйла да.
Минем өчен авыр еллар юк,
Минем өчен ерак юллар юк,
Син булганда якты дөньяда.
Ышан, иркәм, шуны уйла да;
Син булганда якты дөньяда,
Юк, күз салмам бер дә ятларга;
Кошлар китә җылы якларга...

## Үз юлы бар һәрбер чишмәнең

Үз юлы бар һәрбер чишмәнең,
Суының бар үзенә бер тәме.
Булса әгәр суын эчкәнең,
Хәтерлисең, соңмы-иртәме:
Ул да, дисең, озын гомерле,
Ярты юлда корып кипмәсә;
Агымына, әйтик, Иделнең
Азмы-күпме куәт өстәсә,
Җитә, димәк, барып диңгезгә;
Ә калганы мәгълүм сүзсез дә.

## Көзләр җитсә...

Көзләр җитсә, китә кошлар
Суларын ташлап.
Төшә тәүге кырпак карлар
Урләргә башлап.
Үз законы табигатьнең,
Ул — хуҗа үзе.
Берәүне дә үтми читләп
Гомернең көзе.
Инде безнең үрләргә дә
Кырпак кар төшә;
Ул, яшьлектән көнләгәндәй,
Чәчләргә күчә.
Ә гомернең җимешләре
Ник соңлап пешә?

*1965.*

*Зәки Нури*

# КИЧКЕ КҮРЕНЕШЛӘР

## Бу йортлар

Машина тиз чаба.
Ашыгып киләбез.
Яңа як, яңа төн
утлары каршылый.
«Килегез! Күрегез!
Керегез! — Менә без!»
Дигәндәй,
яшь кала йортлары каршылый.
Бу йортлар
Каманың үз яры ташыннан.
Елмаер картада
яшьлеге Каманың!
Юлларны без салган,
ташны без ташыган! —
Шулай ди төзүче —
батыры заманның.
Бу йортлар калкалар
киң басу түрендә.
Ә йортлар эчендә —
аннан да зур киңлек.
Ул киңлек — хыялда,
ул киңлек — күңелдә.
Бу йортлар —
җыр белән биюгә иркенлек.
Ялтырый тәрәзләр —
җемелди кәрәзләр.
Йорт саен күпме күз!
Һәммәсе ягымлы.
Җылы бер түрдә без
булырбыз бераздан.
Яратып туймам, ил,
синең бу ягыңны.
Бормалар. Күперләр.
Үрләргә менәбез.
Зур тизлек. Зәңгәр кич.
Якты юл. Ак йортлар.
Без монда
Симфония туасын беләбез,
Бу йортлар
шул Моңга беренче аккордлар.

## Кирпечләр һәм кыллар турында

Кирпечен ташый-ташый,
Егеткәй арымыйдыр.
Ә кечкенә Әлифбасы
Аның да «до, ре, ми»дыр.

Ничек чыдый икән дә
Өзелми нәзек кыллар,
Тиз-тиз тиеп үткәндә
Ташлар уйнаткан куллар?

Уены-чыны бергә,
Күпләр шулай уйлыйлар.
Ә кыллар тынмый бер дә,
Куллар һаман уйныйлар.

Көн дә уза дәресләр,
Куллар кылны чиртәләр.
Көйнең берсе дәрт өстәр,
Берсе назлар-иркәләр.

Бетховенның, Шопенның
Уйнап бирер кирәксә...
Кылда түгел, Шафиның
Моңы-чыңы йөрәктә.

Үзе җырлар кушылып
Үзе уйнаган көйгә:
«Бар теләгем шушыдыр:
Җыр керсен һәммә өйгә!

Без яңа йорт салабыз
Тезеп ташын-кирпечен.
Якты хистән яралып,
Җыр бизәсен өй эчен.

Музыкада ноталар —
Шул ук кирпеч бит алар,
Берәм-берәм аласың,
Җыр — нигезгә саласың.

Ә матур җыр күп кирәк
Картларга һәм яшьләргә.
Булыйм дисәң ут йөрәк,
Кирәк җырлап яшәргә!»

## Кайсы матуррак?

Әйдә, таптап епшек карны,
Тын урамга узыйк әле —
Йолдызлар күз кысышканны
Икәү бергә күзлик әле.

Күк йөзе — зөбәрҗәт диңгез,
Алтын таңкаләргә тулы:
Әнә күренә Зөһрә йолдыз,
Әнә еракта Каз юлы...

Йолдызлар бүген исәпсез,
Гел йолдыз күреп атлыйбыз.
Кайсы матуррак дисәң — без
Җир йолдызларын мактыйбыз.

Җир йолдызы — маяк уты,
Кабыза аны безнең куллар.
Ул торган чакта яктыртып
Якын тоела озын юллар.

Җир йолдызы — биш канатлы,
Һәм ул комач төсле йолдыз.
Дөнья балкышын яңартты
Безнең шушы көчле йолдыз.

Җир йолдызы — ул кызу эш
Илнең һәммә төшендә дә.
Балкый ул безнең төзелеш
Батырлары түшендә дә.

Җир йолдызы — солдат даны,
Ялтырый хәрби бүрекләрдә.
Азат илләр яуда аны
Куандылар күреп бар да...

Җир йолдызы күккә менсен
Салют биргән чакта туплар.
Бүтән йолдыз сүнсә сүнсен,
Җирдә янсын безнең утлар.

*Түбән Кама, 1965.*

*Гариф Гобәй*

# Коръән серләре

9

**СӘГАТЬ ГАЕПЛЕМЕ, ӘЛЛӘ СӘГАТЬЧЕМЕ?[1]**
**«СЫНАР ӨЧЕН ШУЛАЙ ЭШЛӘДЕМ».**
**БУ — ЭТЛЕК БУЛА ТҮГЕЛМЕ?**
**ТАГЫН АЛЛА ДИГӘНЧӘ БУЛМЫЙ.**

Алланың Иблис турындагы хөкеме — гадел хөкем түгел дә түгел. Ләкин анысында әле гаепләүче кулында тузан бөртеге хәтле генә булса да дәлил бар иде. Адәмгә сәждә кылмадымы? — Кылмады. Алла белән әрепләшеп маташтымы? — Маташты. Ә Адәм? Кабыргасын шытырдатып сындырып алган чакта йөзен генә дә чытмаган, әз генә дә зарланмаган Адәм? Туганына фәкать берничә көн үткән, берниндн тормыш тәҗрибәсе булмаган Адәм? Аңар карата гадел хөкем микән соң бу?

Мондый чакта дин әһелләре җаваптан бик ансат котыла. Адәмне алла кисәтеп куйдымы? — Куйды. Аннан килеп, Шайтан ләгыйннең мин кешеләрне теләсәм ничек аздырып йөриячәкмен дигәнен ишеттеме? — Ишетте. Адәм кайсын тыңлады? — Шайтан ләгыйнне тыңлады. Шулай булгач, үзенә үпкәли шул инде...

Юк, үпкәләми торсын әле! Дөрес, алла ерак бабабызга:

«...Әй, Адәм, Шайтан синең һәм хатыныңның дошманы, үзегезне җәннәттән чыгарып куймасын, — ди. Ләкин шуңар өстәп: — Ләкин Адәм хәтерсез булды, йомшак булып чыкты», — ди бит.

*(Коръән, «Таһә» сүрәсе, 114—117 аятьләр.)*

Ә кем соң аны хәтерсез итеп ясады, кем йомшак итте? Сәгатьнең дөрес йөрмәгәненә сәгать гаепләме, әллә сәгатьчеме? Арбаң шыгырдаганга арбаң гаепләме, әллә үзеңме? Ипинең чи калганына ипи гаепләме, әллә пешерүчеме?

Менә тагын бер сорау: ә соң алла ул тыелган агачны җәннәткә ни дип утырткан? Дөрес, бу сорауда Коръәндә җавап бар. Ләкин ул җавап аша без бары алланың тагын бер бик үк сокланырлык булмаган

[1] Дәвамы. Башы 1 нче санда.

сыйфатын күреп хәйраннар калабыз. Бу хакта аллабыз менә нәрсә ди:

«Коръәндәге каһәрләнгән агачны без кешеләрне вәсвәсәләндерү өчен күрсәттек...»

*(Коръән, «Исраил балалары», 62 аять.)*

Вәсвәсәләндерү өчен, ягъни күңелләрен аздыру өчен... Менә монысы аллача булган ичмасам! Үстереп кенә дә калмаган, күрми үтеп китмәсеннәр дип, хәтта үзе алып барып күрсәтеп йөргән бит, агай!..

Без — җир кешеләре, мисалны җирдән алыйк әле. Малай чакта мин бер бакчачыны белә идем. Алмалары пешеп-пешкән. Исе борыннарны ярып керә. Безнең түгел, олы кешенең күзе яна... Безнең куллар ихтыярсыз коймага үреләә... Кергәндә сүз әйтми бакчачы. Ә инде беренче алмага үрелүгә, әллә гена каян килеп чыгып, кычыткан белән!.. Гафу ит, алла агай, бу да синең шундыйрак бер мәкерең була түгелме соң? Нигә үрелүенә кулына сукмадың син ул Адәмнең?

Моңар җавабында алла күзен дә йоммыйча:

— Сынар өчен, энем, сынар өчен,— ди.

Монысы инде кызык ярым кызык. Димәк, алла Адәм белән Хаваның ашарларын-ашамасларын белмәгән?! Монысы белән алла үзенең чикләнмәгән кодрәт иясе түгел икәнен тагын бер мәртәбә фаш итә түгелме соң? Фәрештәләр, шул исәптән Иблис тә, алда ни буласын белеп тора, ә алла хәтле алла Адәмнең тыелган җимешне ашарын-ашамасын белми булып чыга, шулай түгелме? Бик шулай. Һәм бу ачы хакыйкатьнең үзеннән дә кызыграк койрыгы бар. Дин әһелләре аның турында эчтән тыналар, ә без аны рәхәтләнеп торып фаш итәбез. Менә ул аятьләр:

«Кешеләрне Иблис үзенә буйсындырды, — ди алла, — һәм безне онытырга мәҗбүр итте».

Сиздегезме, эшләр кай тарафка китте? **Иблис алла хәтле алланы оныттырсын әле, агай!..**

Ә мондый илаһи көчне Шайтанга кем бирде икән соң, мулла абзыйлар? Белмисез? Хәтерегезгә төшерим: Шайтан алла белән телгә килгәндә, «мин синең кешеләреңне телəсәм ничек аздырып йөрермен», дигәч, алла нәрсә диде әле? «Менә монысы безнеңчә дә тугры юл бу-

*УЙЛАР, ПЛАННАР, ТЕЛӘКЛӘР*

## *Мирсәй Әмир*



**Соңгы елларда мин укучыларымның һәм каләмдәш дусларымның игътибарын җәлеп итәрлек зур һәм җитди әдәби әсәрләр иҗат итә алмадым. Язучылар союзы идарәсенең рәисе буларак, төп вакытым һәм көчем әдәби хәрәкәтебез өчен котылгысыз булган оештыру эшләренә бирелә. Оештыру эшләре дигәнебез исә, әдәбият-сәнгать дөньясына карата әйтелгәндә, ул аеруча катлаулы һәм җаваплы процесс. Ул — күп гасырлы тарихы булган зур әдәбиятыбызның үткәненә, аның бүгененә һәм киләчәгенә кагылышлы чиксез күп һәм зур проблемаларга бәйләнгән: бүгенге әдәбиятыбызның идея сафлыгы, аның художество сыйфаты өчен көрәш, язучыларыбызга иҗат шартлары тәэмин итү, ягъни нәшрият, китап сәүдәсе, халык тормышы белән җанлы бәгләнышны ныгыта бару, тугандаш әдәбиятлар белән дуслык элементләре, ниһаять, каләм әһелләребезнең тормыш-көнкүреш яклары, үзара мөнәсәбәте, мораль мәсьәләләре — болар берсе дә рәисне читләтеп үтә алмыйлар.**

**Моның өстенә, миңа депутат һәм РСФСР Верховный Советы президиумы председателенең урынбасарларыннан берсе буларак та зур җаваплы эш йөкләнгән.**

**Ләкин мин боларны укучы каршында аклану өчен язмыйм. Чөнки бу эшләрне үземнең иҗатымнан аерып йөртәсем килми. Әдәби публицистика характерындагы мәкаләләр, язучыларыбызның иҗаты турында хисап доклады белән съезд алдында чыгулар, ара-тирә хикәя дә язгалап кую, әлбәттә, каләм кычытуын билге-**

ле бер дәрәҗәдә баса киләләр. Дөрес, бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек яңа роман, повесть, хикәяләр яки сәхнә әсәрләре язуның куанычы зуррак. Иҗат куанычы — һәр язучы өчен зарури ихтыяҗ ул. Мин үземне хәзерге хәлемдә дә бу тойгыдан бөтенләй үк мәхрүм димәс идем. Мине язучыларыбызның соңгы еллардагы иҗат активлыгы сөендерә. Һәр язучыбызның җитди уңышына мин үз иҗатымда ирешкән уңышка куанган кебек куанам дисәм дә арттырып әйтү булмас. Ә узган ике елда әдәбиятыбызда күңелгә куаныч китергән яңалыклар аз булмады.

Ул әсәрләрне атап күрсәтү бердән, озынга китәр, икенчедән, анкетага җавап төсендә генә язылган бу сөйләшүнең юнәлеше икенче якка бара башлар иде, шуңа күрә алар турында тулырак сөйләүне икенче вакытка калдырып, турыдан-туры үз иҗатыма кагылышлы мәсьәләләргә тукталам.

Татарстан китап нәшрияты минем өч томлык әсәрләр җыентыгымны чыгарырга планлаштырды. Үткән елда мин шуның беренче томын төзү өстендә эшләдем. Моңарчы башка китапларда чыккан әсәрләрне яңа җыентыкка күчереп кую турында гына сүз барса, бәлки, бу хакта язып торуның да кирәге булмас иде. Бу эш катлаулырак булып чыкты. Моңарчы М. Әмир иҗаты турында язган иптәшләр минем башлангыч чордагы әсәрләрем яныннан күбесенчә игътибарсыз гына үтеп китәләр, кайбер иптәшләр хәтта мине ул чордагы әсәрләремдә җитди хаталар ясаган итеп тә күрсәтәләр иде. Шундый карашлар йогынтысына бирелеп булса кирәк, мин үзем дә яшьрәк чакта язган әсәрләремә карата соңгы елларга кадәр игътибарсызлык күрсәтеп килдем. Хәзер килеп исә, — заман рухы этәргеч биргәндерме, әллә картая башлау билгесеме, — үткән юлыма борылып карарга, яшь чакта язып ташлаганнарыма җитдирәк итеп күз салырга ниятләдем. Вакытында төрле имзалар белән язылып, төрле журнал һәм газета битләрендә кайсылары гарәп, кайсылары латин хәрефләре белән бергә архивка ташланган әсәрләрем байтак икән. Һәм алар арасында бүген өчен дә әһәмиятен югалтып бетмәгән хикәяләр, вакытында теге-яки бу конкрет фактларга яки шәхесләргә нигезләнгән булып та, ята-ята үзләреннән-үзләре хикәягә әйләнгән фельетоннар да бар икән.

Хикәягә әйләнгән фельетон? Бу тагы нинди жанр дисезме? Әйе. Моннан утыз-кырык еллар элек басылган язмаларым арасында казына торгач, фельетон жанрының моңарчы мин игътибар итмәгән бер әһәмиятле үзенчәлеген күрдем. Фельетон, әгәр дә ул очраклы вакыйгага нигезлә-

лачак», — диде түгелме? («Әлхиҗр» сүрәсе, 41 аять.) Дөрес, алла шул ук сүрәнең 42 аятендә, бу мәсьәләгә ачыклык кертеп:

«Миңа ихлас күңелдән буйсынучылардан гайриләрен генәаздыра алырсың», ди. Ләкин монысы белән аллабыз бөтенләй хур була. Хәзер без аның алдына шундый сорау куябыз:

Ә Адәм? Ул ихлас күңелдән буйсынучылар җөмләсеннән түгелмени? Адәм хәтле Адәм дә ихлас күңелдән буйсынучы булмагач, башкага ни сан соң инде?!

Алла Адәмнең үзенә буйсынучылар җөмләсендә булмаганын «Балкортлары» сүрәсенең 101 аятендә тагын да ачыграк итеп әйтә:

«Дөреслектә, Шайтан аллага ышанган кешеләрне, аңар таянган кешеләрне аздыра алмый».

Хәзер без ике нәтиҗәнең берсенә килергә тиеш, яки атабыз Адәм аллага ышанмаган, чөнки Шайтан аны үзебез күз алдында аздырды. Яки Шайтанда алла белән ярышырлык, алланы җиңеп чыгарлык кодрәт бар... Түземебез җитеп, бу китапны ахырга тикле укып чыксак, алланың моңардан җитмеш җиде кәррә мәзәгрәк мәзәкләрен очратырбыз әле.

Алла Адәм белән Хаваны, күрәсең, юату өчен генә тормыш кирәклеген җирдә табарсыз дигән икән. Ул аларны җирдә бик авыр шартларга куя. Килеп төшсәләр, кием-салым юк, ут юк, ашарга юк. Бөтенесенә тир түгеп ирешергә мәҗбүр булалар. Дәресрәге, алла аларны үзе шуңар хөкем итә: үлеп туфрак булганчыга кадәр икмәгегезне маңгай тирегез белән үстереп ашарсыз, ди ул. Алай гынамы соң әле!.. Адәм белән Хавадан туачак балаларны, алардан таралачак бөтен кешене, ахыр заманга кадәр яшиячәк бөтен кешелекне, шул исәптән синең белән мине дә, мәрхәмәтле алла шул ук җәзага хөкем итеп куя!

Әлбәттә, мин биредә җәза сүзен алла үзе шулай дигәнгә күрә генә кулланам. Асылда эшләп ашауны без җәза димибез. Киресенчә, әгәр җирдә тир түгеп, ягъни эшләп ашау булмаса, бөтен дөнья әрәм тамаклар белән тулар иде, икмәкнең тәме дә, кадере дә булмас иде. Әнә бөек Тукай үзе дә:

«Булса калдырмак берәү ошбу җиһанда изге ат,
Тир белән тапсын ашарын, итсен, әлбәт,
иҗтиһад», —

ди бит. Икенчедән, өстебездә оят җирлә-

ребезне каплаган җәннәт яфрагыннан гайри бер нәрсәбез дә булмас иде. Җереп кунар куышыбыз булмас иде.

Ләкин әйтәсем килгәне хәзергә бүтән. Эш шунда ки, хөкем принципиаль дөрес түгел. Бу бит, мәсәлән, ат карагыннан туган һәм туачак балаларны, балаларының балаларын, аның дөнья беткәнче җирдә яшәячәк бөтен нәсел-нәсәбен үзләре туганчы ук төрмәгә хөкем итеп куюкебек дуамал хөкем. Әлбәттә, мондый хөкем иң кыргый илдәге иң кыргый патшаның да башына килмәгәндер.

Иңбашымда гамәл дәфтәрләремне тотып, ни әйтәсемне көтеп утырган фәрештәләр моның өчен миңа теләсә нинди гөнаһ язсыннар: мин, атабыз Адәм токымы буларак, бу хөкемгә аслан риза түгел. Аслан!.. Син дә минем белән килешсәң кирәк, укучы иптәш.

Алланың ул каһәр төшкән җәннәт бодае (Тәуратта алма) өчен биргән җәзасы моның белән генә чикләнми. Алда күрербез, бу алма өчен алла хатын-кызга аеруча бер каныгу белән каныгачак. Ә хәзер ул Хавага һәм аңардан таралачак бөтен хатын-кызларның җаннарына хитап итеп:

«Йөкле чагыгызда хәсрәтегезне арттырырмын. Балаларыгызны авырлык белән таба торган булырсыз» ди.

*(«Тәурат», «Яшәеш» 3 сурә, 16 аять.)*

Белмәсәгез белегез, аналар! Менә ни сәбәпле сезнең балаларыгыз агачтан алма өзелгән төсле ансат кына өзелеп төшми. Бу газапка сезне әнә кем хөкем итеп куйган — Коръәннең һәр битендә диярлек мин гадел, мин шәфкатьле дип шапырынучы, гамәлдә һәрдәм киресен эшләүче ходай тәгалә үзе! Менә шулай, аналар.

Ә сез, үзегезнең ни сәбәптән күрем белән газапланганыгызны беләсезме? — Шул ук җәннәт бодае өчен. Имештер, анабыз Хава бодай өзгәндә, гөнаһ шомлыгына каршы, ялгыш агачның бер ботагын сындырган була, бу хәлгә бодай агачы кан-яшь белән елый. Алла, шуны сылтау итеп, анабыз Хаваны, шулай ук аңардан таралачак барча хатын-кызны да кыяматкәчә күрем җәзасына дучар итә. Хәтта мөддәтенә кадәр билгеләргә онытмый: «Күбе ун көн, азы өч көн».

*(Рабгузи, Кыссас-эл-әнбия, 20 бит.)*

неп, анда катнашкан шәхесләрнең исем-фамилияләрен атау белән генә чикләнгән булса, аның гомере кыска. Басылып чыккан көннәрендә билгеле бер максатка файда китергән булса да, берникадәр вакыт үтү белән аның әһәмияте югала, әдәби кыйммәте калмый. Әгәр дә инде ул үз заманының рухын тоеп, типик вакыйгаларга нигезләнгән булса, тәнкыйть астына алынган геройларының фамилия яки хезмәт урыннарын әйтү белән генә чикләнмичә, аларның җанлы образларын гәүдәләндергән булса, андый фельетон вакыт үтү белән искерми генә түгел, киресенчә, матур әдәбиятның югарырак төренә — хикәягә әверелә икән. Моның өчен андагы персонажларның һәм телгә алынган учреждениеләрнең исемнәрен алыштыру җитә. Үз язмаларым арасында әнә шундый хикәягә әйләнгән берничә фельетон таптым шикелле.

Билгеле, бик күптән, әле тәҗрибәсез чакта язылып, вакытлы матбугат битләрендә басылган килеш яткан, кайберләре хәтта беркая да басылмаган көйгә архивка ташланган кулъязмаларны бүгенге укучыга тәкъдим итү өчен, аларны бик нык сайларга, сайлап алынганнары өстендә исә, бик зур игътибар белән каләм йөртергә туры килде. «Пар күгәрчен» повесте, «Бәхет порошогы», «Хафиз бармагы» кебек хикәяләр тәнкыйть тарафыннан бик озак еллар буенча минем гөнаһларым саналып килделәр. Баксаң, аларда кот очарлык берни дә юк икән. Һәм алар хәзерге көндә дә укучыларын табарлар дип ышанам.

Әлбәттә, язу тәҗрибәсе булмау өстенә, белем ягыннан да бик бәләкәй әзерлек белән әдәбият дөньясына килеп кергән, әле күбрәк интуиция көче белән иҗат иткән яшь кешенең язмаларында йомшак яклар күп булыр. Ләкин яшьлекнең аның берниндә тәҗрибә белән дә, белем белән дә ирешеп булмый торган рухи үзенчәлекләре бар бит. Шул якларына таянып, мин ул әсәрләремне җыелмамның 1 нче томына керттем дә. Һәм мәсьәләнең һәр ике ягын искә алып, ул китабымны «Яшьлек гөнаһларым» дип атадым. Бу китап шушы 1966 елда укучы кулында булырга тиеш.

Хәзерге көндә әсәрләр җыелмамның икенче, өченче томнарын төзү өстендә эшлим. Болары, әлбәттә, җиңелрәк булачак. Шуңа күрә төп игътибарымны яңа әсәрләр язуга багышларга уйлап торам. Уйлап куелган берничә хикәям бар. «Казан утлары»на быел шуларны эшләп бирергә тырышам. Алар өстенә үземнең тәрҗемәи хәлемә бәйле зуррак күләмле бер әсәр язасым килә. Соңгы елларда миңа кордаш булган язучылар арасында мондый әсәрләр язу күбәеп бара. Ләкин бу мине куркытмый. Чөнки һәркемнең тормыш юлы, язучы

кузлегеннән карый һәм күрә белгәндә, кабатланмас үзенчәлекләр белән тулы. Миңа бала чагымнан ук бик катлаулы, авыр тормыш юлы үтәргә туры килде. Беренче бөтендөнья сугышы, революция еллары, гражданнар сугышы, ятимлек, ачлык нужалары, балалар йорты тормышы, кеше булу, иҗат куанычлары, шәхес культы чоры китергән газаплы кичерешләр, төрмә стеналары, ниһаять, Бөек Ватан сугышы еллары, зур җиңү шатлыклары... Алар мине язарга кыстыйлар. Һәм Октябрьның 50 еллыгы якынаю уңае белән мин бу җитди эшкә чынлап керешергә җыенам.

Язасы килгән әйберләр күп. Каләмем инде сәхнә әсәре язуны да бик сагынды. Һәвәскәр балыкчылар турында бер юмористик повесть тел очымда гына тора кебек. «Мәхәббәт хаты» дигән бер хикәям шактый өлеше язылган хәлдә, тәмамланганны көтеп, елап ята.

Барын да күрәм, барын да тоеп йөрим. Барысы өчен дә борчылам. Алар миңа картаймый торырга кушалар. Ләкин вакыт көче белән көрәшү җиңел түгел. Шулай да өметне өзмим, иптәшләр ярдәме белән мин аны авызлыклау чараларын табармын дип ышанам.

## *Мөхәммәт Садри*



Мин «Җыр дәвам итә» дигән шигъри повесть өстендә башны күтәрмичә утырып, аның беренче бүлеген тәгәлләдем. Аннары командировкада йөрдем: Арча һәм Октябрь Норлаты үзәкләрендә, колхозларында булган әдәби атналыкларда, Мәскәүдә үткәрелгән Сабан туенда, Әлмәттә яшь нефтьчеләр слетында, Чиләбе трактор заводында, Троицкида, Ленинградта һәм андагы атаклы Киров (Путилов) заводында, Кронштадтта,

Һәм бу җәзаны алла барча хатынкызларга карата төгәл үтәп килә. Ә менә алла, синең беренче ике хөкемең (әллә инде фәрештәләр җиргә алып төшкән чакта бутап бетергәннәр, әллә хөкемең тора-бара көчен җуйган) беркайчан да төгәл рәвештә гамәлгә ашмый. Тир түгеп ашаучылар булган кебек, бөтенләй бернәрсә эшләмичә, ашап ятучы паразитлар күп, яман күп. Элек тә, хәзер дә. Һәм алар тир түкәннәрдән күбрәк тыгыналар, тәмлерәген тыгыналар.

Бәлкем, син үзең күреп бетерми торгансың (әлгаязе билләһи, әйттем исә кайттым), хатын-кызга карата да хөкемең төгәл үтәлми бит. Аларның кайсыберсе тулгак газабын күрми. Ә фән якын киләчәктә хатын-кызның бөтенесен синең бу җәзаңнан йолып алырга вәгъдә итә.

Ышанмыйсың? Ә син ышан. Кешене син яраткан бик күп зарарлы микроблардан арындырган, син яраткан трахома, бизгәк, чахотка кебек чирләрдән йолып алган фән эшләячәк моны! Кешенең иң нечкә әгъзаларына иң нечкә операцияләрне ясаганда авыртуын ала торган дару уйлап тапкан фән эшләячәк!..

Алланың еланга карата чыгарган хөкемен дә гадел хөкем димәс идем мин. Эш шунда ки, елан җәннәт капка төбендә сакта торган чагында дүрт аяклы, болан сымак бик күркәм сыйфатлы, әйтеп бетергесез сөйкемле, үтә гайрәтле һәм чая бер хайвани зат була. Шайтанны җәннәткә керткән өчен алла аңар:

Шуышып йөри торган мәхлук бул, гомерең балчык ашап үтсен, дип нәгърә ора. Әйтте — бетте. Бичара елан — әнә шунда гына без белә торган елан рәвешенә керә... Минем бурыч — еланның да гаебен йолу. Һәм миңа моның өчен бер сүз дә җитә: Адәм хәтле Адәмне утырткан Шайтан бер мәхлукне ничек утыртмасын ди инде? Аннан Шайтанга андый көчне алла үзе бирде ич!.. Тагын шунысы: алланың еланга карата чыгарылган хөкеме, читләтеп кенә булса да, безнең мәнфәгатькә дә суга, һәм бик каты суга. Сөйкемле, күркәм сыйфатлы хайван булып калса, ул берәр эшкә ярар иде, ә хәзер әнә гомер-гомергә безнең котны алып тора.

Бирерә тагын шунысы игътибарга лаеклы. Елан алла хөкеменең икенче пунктын үтәми. Балчыкны ашау түгел, гомерендә бер кабып та карамый.

Бу бабта, янә бер мәртәбә Иблис мәсьәләсенә әйләнеп килеп, аллага шуны әйтик: син ул Иблис фәрештәгә шундый көч, шундый ирек биреп бик каты ялгышкансың, алла бабай. Син бит әле аңа ирек биреп кенә дә калмагансың, кеше балаларын station аздырырга аңар үзең фәтвә биргәнсең, киңәшләр биргәнсең. Хәтта шундый явызлыкка өйрәткәнсең син аны.

Кешеләрнең «Балаларын уртаклаш, җиһазларын уртаклаш», дигәнсең син аңар.

*(Коръән, «Исраил балалары» сурәсе, 66 аять.)*

**Җиһазлар** турындагысын әйтә алмыйм. Бәлкем, шулай эшләнеп килә торгандыр. Өеңә кайтып керәсең, йозак ватык, җиһазны төяп киткәннәр. Әллә кеше, әллә Шайтан мәзәге. Шайтан белсен!.. Трамвайда, билет алмакчы булып, кесәңә тыгыласың, портманеттан җилләр искән. Әллә кеше эше, әллә Шайтан мәзәге. Шайтан белсен!.. Әмма ләкин шунысы бәхәссез: Иблис синең «кеше балаларын уртаклаш» дигән боерыгыңны күңел өчен генә булса да, гомергә бер генә тапкыр булса да тотмады. Ачуы чигенә чыкканда кайбер кеше үзенең баласына: «Шайтан алгыры!» — дип әйтеп салучан, ләкин Иблис кешенең соңынтын үкенәсен белгәне хәлдә, аның баласына орынмый, алмый аның баласын.

Бу урында Иблискә рәхмәт әйтми киту — кешеләрчә булмас иде. Рәхмәт сиңа, Иблис дус! Ихлас күңелдән рәхмәт! Алладан рәхимлерәк икәнсең. Аның төсле үк кансыз түгел икәнсең.

Иблис турында алда сүз күп булыр әле. Хәзергә тик шуны гына әйтим: син, алла бабай, аны дәрьгаһыңнан сөреп, бик начар иткәнсең. Гөнаһсыз фәрештә килеш калдырырга иде сиңа аны: ул бит синең юлыңа гелән киртә булачак, арт тәгәрмәчеңә таяк тыгып торачак, гел син эшләгәннең киресен эшләп барачак. Үзең уйлап кара: хак дингә өндәп, күк белән җир арасында дөнья хәтле фәрештәләрең йөреп тора, бер-бер артлы пәйгамбәрләрең килеп тора. Ә кешенең бик азыннан гайриләре, алар әйткәнне, ягъни синең изге сүзләреңне колагына да элми. Ник? Чөнки син Шайтанга үзеңнең һәрбер әйткән сүзеңне онытгырырлык көч бирдең бит!!!

Ялгыштың? Безнеңчә дә шулай. Хәзер син аны җәһәннәмгә бик бөтереп тыгар идең дә, хөкемең андый түгел, акка кара

булдым. Татарстан районында һәм Уралдан алып Балтикка кадәр үтелгән юл мине яңа иҗади эшләргә рухландырды. Хәзер «Уралдан Балтикка кадәр» дигән шигырьләр циклы өстендә эшлим. 1966 елда, югарыда әйтелгән зур поэтик әсәремне тәгәлләү өчен бөтен көчемне куям. Чөнки ул әсәрне Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгына багышлыйм. 1966 ел минем өчен бигрәк тә киеренке иҗат елы булачак: сәхнә әсәре өчен материал туплыйм. Гражданнар сугышында күрсәткән батырлыклары өчен беренче булып орденнар алган татар хатын-кызлары турында очерк язар өчен дә материал җыйдым. Бер үк вакытта, үзем җыеп туплаган фольклор материалларын карап, «Себер халык әкиятләре һәм җырлары» дигән китап хәзерлим.

## *Зәки Нури*



1966 елда укучылар кулына җиткерeләчәк китабым инде типографиядә. Ул «Елмаябыз һәм көләбез» дип атала. Китап күркәм күңелле кешеләрнең кайбер мәзәк сыйфатларын күреп, ягымлы елмаю белән бергә, начар якларны, начар эшләрне рәхимсез фаш итеп, алардан чаянча көлә. Кыскасы, җыентык көлке капчыгына өстәләсе әсәрләрдән тора. Алдагы елларның берсендә чыгарыр өчен балалар турында язган барлык шигырьләремне туплап нәшриятка тапшырдым. Анысы «Бу безнең китап» дип атала һәм балалар аны шулай кабул итсеннәр иде. Бер үк вакытта, инде күптәннән башланган берничә эшемне дәвам итәм: азлап-азлап булса да партизан хикәяләре языла. Илебездәге барлык милләтләрнең борынгы һәм хәзерге заман поэзиясеннән иң яхшы үрнәкләрен тәрҗемә

**итәм. Барлык илләрдән, барлык телләрдән сайлап халык мәкальләре һәм әйтемнәре китабын татар телендә эшлим. Ул китап әдәбиятчылар, журналистлар, пропагандистлар һәм барлык укучылар өчен дә бик кирәкле кулланма булыр дип уйлыйм. Кыска гына мәкалә һәм әйтем юлларында, Горький әйткәнчә, калын-калын китап өчен җитәрлек фикер, акыл һәм хисләр бар.**

## *Мәхмүт Хәсәнов*



**Татар совет әдәбияты кебек зур әдәбиятка үзеңнән өлеш кертү, әлбәттә, чиксез мактаулы, шул ук вакытта гаять дәрәҗәдә җаваплы эш. Узган елларда минем «Саф җилләр» исемле романым дөнья күрде.**

**1965 ел минем өчен аеруча истәлекле булды. Ел башында ук татар совет язучыларының съезды булуын, шуның өстенә яңа әсәр тәмамлавымны һәм, ниһаять, съезд барган көннәрдә СССР Язучылар союзына мине член итеп кабул итүләрен дә исәпкә алсам, ул елның минем өчен гади ел гына булмавын исбат итеп торуның кирәге дә юк.**

**Яңа әсәрем «Юллар, юллар...» дип атала. Ул 1966 нчы елда аерым китап булып басылып чыгачак. «Юллар, юллар...»ны мин шулай ук «Казан утлары» журналына да тәкъдим итеп карарга уйлыйм.**

**Хәзерге вакытта бөтен прогрессив кешелек дөньясы В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуны, бөек Октябрьның 50 еллыгын тантаналы рәвештә үткәрү өчен зур әзерлек эше алып бара. Билгеле инде, безнең язучыларыбыз да бу зур даталарны үзләреннән лаеклы өлеш кертеп каршы алачаклар. Минем дә күп еллардан бирле яшәп килгән хыялым бар. Шул өермәле, ялкынлы дәверебезне чагылдырган зур күләмле әсәр язарга уйлыйм. Гадәттән тыш җаваплы, шул**

белән: «Кыяматкәчә теләсәң нишләп йөр», — дип язып куйгансың. Үзгәртер идең, фәрештәләр нинди алла син үз сүзендә тормагач дип, мыек астыннан көлеп йөриячәк. Нишләсәң дә вай...

Бу бүлекнең иң дә тузга язмаган җире, иң йөгәнсез экиятләргә дә сыймый торганы: Иблиснең алла хөкемен шулай тыныч кабул итүе. Әйтерсең, канатыннан бер каурыен гына йолкып алдылар, исе дә китмәде бит. Имештер, алайса, алла агай, миңа теләсәм нишләп йөрергә ирек бирәсең, һәм шуның белән безнең эш бетте.

Күлештерерсең алай ансат кына Шайтанны! Мәңгелек җәннәтне, шундый зур дәрәҗәне күз ачып йомганчы үтеп китә торган фани дөньяның ялган бизәкләренә алмаштырырга шыр тиле түгел, фәрештә ләбаса ул! Аның да гадие түгел, җеннәргә каршы сугышып дан казанган фәрештәләр гаскәре башлыгы!

Бәс шулай булгач, бу Шайтан экиятенә экият кенә итеп тә ышанасыбыз килми безнең. Әгәр Шайтан, чыннан да, бар икән, чыннан да, ялгышкан икән, атабыз Адәм белән анабыз Хава кебек гафу үтенер иде. Нәрсәгә гафу! Бөтенләй ялгышмас иде ул! Фәрештә буларак, алланың шундый хөкем чыгарачагын болай да белеп торган ич ул!

Шайтан экияте фәкать бер мәзәк экият булып калу белән бергә, Коръәннең «Фәрештәләрдә женес аерымлыгы юк, ирлек, хатынлык юк» дигән тәүге бер раславының ялган идекен өстәмә рәвештә фаш итә: фәрештәләрдә женес аерымлыгы булмагач, ул иблис токымы ничек ишәеп китте икән соң дибез без. Андый сүзне кайдан алдың, дисең? Ә бу хакта Коръәннең берничә урынында аерымачык ярылып ята. «Киртәләр» сүрәсенең 26 аяте, мәсәлән, менә нәрсә ди:

«Дөреслектә Иблис һәм аның төркеме кешеләрне күреп тора, сез генә аларны күрмисез...»

Икенче бер аятьтән, төркемә генә түгел, аның гаскәре дә бар икәнен беләбез: пехотасы һәм кавалериясе. Иблис үзенең бу гаскәрен безне аздыру өчен куллана.

**«Кешеләрне аздыра алган кадәр аздыра бир, —** ди аңар алла, **— аларга каршы үзенең җәяүле һәм атлы гаскәреңне җибәр».**

*(Коръән, «Исраил балалары» сүрәсе, 66 аять).*

Хатыны булмагач, үрчү хасияте булмагач, ул гаскәр Иблискә каян килде икән соң? Бәлкем, ул җеннәргә каршы сугышкан гаскәрдер? Яки, җеннәргә баш булып алгач, шулардан туплагандыр? Кайсы булса да, моны алланың чиктән тыш буталчык хикмәте дияр идем мин. Гаскәр фәрештәләрдән торса, фәрештәләр Иблискә әле дә элеккечә, ул полководец чактагыча, буйсыналар дигән сүз. Димәк, фәрештәләрнең Адәмгә сәҗдә кылулары алла алдында күз буяу гына булган. Гаскәр җеннәрдән торса, димәк, җеннәрнең кяфере дә, мөселманы да шулай ук Иблискә буйсына булып чыга! Гаскәр Иблиснең үз токымы булса, димәк, аларда үрчү хасияте бар, ире бар, хатыны бар! Ягъни алар да безнеңчәләтеп үрчиләр? Ә фәрештәләр? Димәк, үзеннән-үзе аңлашыла — фәрештәләр дә!

10

### АЛЛА ҖЕННӘР БЕЛӘН БЕЗНЕ НИ ДИП ЯРАТКАН? Ә САЗ КӨЗӘНЕН? «ТӨТЕН» СҮРӘСЕ ТӨТЕН ҖИБӘРӘ

Әгәр дә мәгәр алланың үзе биргән акыл белән фикер йөртеп караудан курыкмасак, безнең башта үзеннән-үзе шундый бер тирән фәлсәфи сорау туарга тиеш: бу аллага җирләр, күкләр нигә кирәк булды икән? Тагын кеше нигә кирәк? Ә ул «җен алгыры» җеннәр? Гомумән, алланың дөньяны яратудан максаты нәрсә? Аннан башка да мәңге-мәңге рәхәтләнеп яшәгән бит. Һичбер төрле борчуы булмаган. Әллә, бала үзенә комнан шәһәрләр ясап уйнаган кебек, үзе өчен берәр кызык эзләп яратты микән, үзенә күңел ачу өчен яратты микән?

Юк, соңгысын алла катгый рәвештә инкарь итә. Менә нәрсә ди ул:

«Без җир белән күкне һәм алар арасындагыларның җәмгысен үзебезгә күңел ачу теләге белән ясатмадык, мәзәк эзләү теләге белән яратмадык. Әгәр үзебезгә берәр мәзәк теләсәк, күңел ачу эзләсәк, без аны үзебезнең эчтән дә чыгарган булыр идек».

*(Коръән, «Пәйгамбәрләр» сүрәсе, 16—17 аятьләр.)*

**«Мәзәк теләсәк, мәзәкләрне үзебезнең эчтән генә чыгарган булыр идек».** — Бу үзе генә дә путаны чишеп сөйләшә торган хикмәтле хикмәт. Ләкин алланың без-

ук вакытта чиксез авыр эш икәнлеген дә беләм, хәтта, башкарып чыга алырмынмы икән? — дип икеләнеп калган чакларым да була. Әмма, язмыйча булдыра алмыйм. Җитмәсә тагын ул әсәрем моңарчы иҗат иткән китапларымнан күп өстен, эчтәлеге белән дә, формасы белән дә иң яхшы әсәрем булыр төсле. Хәер, Г. Флобер әйтмешли, беркем дә начар китап язам дип кулына каләм алмый.

## *Равил Фәйзуллин*

●



Быел «Аҗаган» исемле китабым чыгачак. Аңа студентлык елларында язылган шигырьләрнең бер өлеше керде. Язга табан ул китап укучыларга барып җитәр дип өметләнәм.

Хәзер шигырь формасы турында күп сөйлиләр. Сөйләнүләр, тулы каны булмаган бәхәсләр, алдан пәйгамбәрлек итүләр әдәбият өчен күпме файдалыдыр, белмим, ләкин шунысына шигем юк: алар чын мәгънәсендә вакыйга булырлык әдәби әсәрләр мөнәсәбәтендә үткәрелмәгәндә кирәксезләр. Башта бүтән милләт укучылары да сокланырлык әсәрләр язасы иде, аннан...

1966 елда балалар өчен язу белән беррәттән, олыларга адресланган яңа шигырь китабы өстендә эшләячәкмен. Инде язылганнары арасында традицион калыплы шигырьләр дә, ирекле формадагылары да бар. Минемчә, әдәбиятта жанрлар диктатурасы шартлы нәрсә. Әгәр хәзерге заман шигыре тукымасында проза яки драма элементлары очрый икән, мәгълүмате һәм хәзерлеге булган укучы моңа аптырап калмаска тиеш. Мондый синтез әдәбиятны баетачак кына. Тик язылганнар талантлы, кешелекле генә була күрсеннәр...

нең фәлсәфи сорауга биргән җавабы тагын да хикмәтлерәк. Әйдәгез, башта шул турыда әңгәмә кылышып алыйк. Алла гүя безнең башта шундый сорау туасын белгән, ул безгә менә нәрсә ди:

«Әллә алар үзләре турында уйланмыйлармы, — ди ул. — Без бит **җир белән күкне, алар арасындагы нәрсәләрне хакыйкатьне күрсәтү өчен билгеле бер мөддәткә яраттык».**

*(Коръән, «Рим кешеләре» сүрәсе, 7 аять.)*

«Төтен» сүрәсенең 38—39 аятьләрендә алда әйткәнен тагын да ныгытып, аныклый төшеп:

«Без җирләрне, күкләрне фәкать **хакыйкатьне күрсәтү өчен генә** яраттык», — ди.

Уйлап карыйк әле: кемгә күрсәтә соң ул үзенең бу хакыйкатен? Җир белән Күкне яраткан көннәрдә дөньяда әчмуха җан иясе дә булмый бит әле. Инде кешегә күрсәтергә уйлаган икән, аңар башта кешене әвәләп куярга иде. Алла өчен моның бернинди дә кыенлыгы юк лабаса. Әнә Кояштан алда яктыны яратты ич.

Җеннәр белән кешеләрне ярату максаты тагын да сәеррәк. Монысы белән алла үзен тагын бер тапкыр көлкегә калдыра:

«Мин — ди алла «Таркатучылар» сүрәсенең 56—57 аятьләрендә, — **кешеләрдән дә, җеннәрдән дә тормышым өчен кирәк-ярак таләп итмим. Мине ашатып-эчертеп торуларын таләп итмим. Мин аларның фәкать үземә табынып торуларын гына телим. Аларны шуның өчен генә яраттым».**

Менә нәрсә өчен генә яшәргә тиеш икән без — кешеләр һәм җеннәр— җирдә!.. Фәкать аллага табыну өчен!.. Ә фәрештәләрне?

«Фәрештәләр... тәкәбберләнеп, табынудан баш тартып тормыйлар, көн-төн, бертуктаусыз аллага мәдхия укый торалар».

*(Коръән, «Пәйгамбәр» сүрәсе, 19—20 аятьләр.)*

Алар гынамы соң!..

«Әллә син күрмәденме, — ди алла «Хаҗ» сүрәсенең 18 аятендә, — җирдәгеләр дә, күктәгеләр дә миңа табына: Кояш та, Ай да, йолдызлар да, таулар да, агачлар да, хайваннар да...»

Хайваннар да, димәк, һәрбер хайван: сыер, кәҗә, сарык кебекләр белән рәттән, бака белән елан да, күсе белән кырыгаяк та, һ. б. һ. б. һ. б. хәшәрәтләр дә?! Әлбәттә, бет белән борча да...

Алар гына да түгел.

«Әллә аларның күргәннәре юкмы, — ди алла, — без яраткан һәрнәрсәнең **күләгәләренә хәтле, уңга-сулга баш иеп, безгә табыналар».**

*(Коръән, «Балкортлары» сүрәсе, 50 аять.)*

Ә соң бу табынулар, мәдхияләр аллага нигә кирәк? Патшаларның, ханнарның кешеләрдән үзләрен мактатып, аларны үзләренә буйсындырып, мәдхия укытып торулары аңлашыла. Кеше буйсынмаса, патшаның эше чуала бит. Тотып асмасалар да, тәхетеннән бәреп төшерүләре бик мөмкин һәм күз алдыбызда мондый хәлләр булгалый тора. Безнең заманның кайбер түрәләренә дә мактатып тору бик кирәк. Бигрәк тә эшлексезләренә, булдыксызларына. Ул үзенең тәлинкә ялаучылары тудырган ялган дан ярдәмендә үзеннән зуррак түрәләр алдында шул рәвешчә дан казана. Нәтиҗәдә, аны төшермиләр генә түгел, тагын да югарырак күтәрәләр.

Кыскасы, патшалар өчен дә, түрәләр өчен дә үзләрен мактау, мәдхия укыту, табындырып тору зурур шәйдер. Ә менә безнең аллага ни пычагыма? Фәрештәнең, җеннең, кешенең, дөянең, баканың, күсенең, бетнең, борчаның һәрдәм табынып торуы нигә аңар? «Аллаһе әкбәр, аллаһе әкбәр, лә илаһа иллаллаһе валлаһе әкбәр, аллаһе әкбәр, вәлилләһил

хәмд» дип торулар, ягъни «алла бөек, алла бөек, бер алладан гайри алла юк, алла бөек, алла бөек, аллага дан» дип, бертуктаусыз такылдап торулар нигә? Радиодан ике-өч кенә көн бер үк артист бер үк жырны чыңлатса да, күңел болгана башлый. Ә ул әле ни әйтсән дә, жыр, артистлар... Ә җен, мәхлук хәшәрәт?.. Һәм шулар җыенысы бер юлы бер үк сүзне, бер үк колакка!.. Көн саен, сәгать саен, бертуктаусыз, мәңге!.. Әйтегез, мулла абзыйлар, аллага моның нигә кирәге бар? Аның тотып асылу яки тәхетеннән бәреп төшерелү куркынычы юк лабаса. Елан яки саз көзәненең табынмавы аның бер бөртек сакалына да зыян китерә алмый лабаса. Хәтта киресен эшләсәләр дә, бөтен галәм бертуктаусыз бәддога укып торсалар да, бер җире дә кителәчәк түгел ләбаса аның!..

Алла, ниләр буласын белеп торган алла, күрәсең, безнең заман кешеләренең шулай фикер йөртәчәкләрен, шул рәвешчә фикер йөртеп, үзен стенага китереп терәячәкләрен белгән, җен токымы белән кешеләрне яратуының югарыда китерелгән максатына тагын бер максат өстәгән янәсе:

**«Без кешеләрне һәм җеннәрне сынар өчен яраттык».**

Соң болай булгач, алла җеннәр башына ниләр киләсен белмәгән булып чыга түгелме? Кешенең җирдә нишләп йөриячәген белмәгән булып чыга түгелме? Гомумән, алдагы көндә, алдагы секундта ниләр буласын белми була түгелме? Һәм моның белән «минем кодрәтемнең чиге юк», дип шапырынуы сабын куыгы кебек шартлап юкка чыга түгелме?

**Ә «кешеләр белән җеннәрдән тормыш кирәк-яраклары таләп итмим, мине ашатып-эчертеп торуларын таләп итмим»** диюен ничек аңларга? — Игътибар итегез: кирәкми дими, мин андый вак нәрсәләргә мохтаҗ түгел дими, таләп итмим генә, ди. Моның белән алла янә бер кәррә безнең алга нәкъ безнең кебек кеше сыйфатында килеп баса.

Кыскасы, болары белән алла, йомшак кына итеп әйткәндә, үзен, янә бер тапкыр уңайсыз хәлгә куя.

Инде сез бу юлларны укыган өчен, мин бәхәскә кереп язган өчен тәүбәгә килик тә Коръәннең тагын да кызыклырак бер бабына күчик.

# Икенче бүлек

«Дин хәзер иске, аварга торгучы чергән дивар...»
*Габдулла Тукай.*

## 1

### САК БЕЛӘН СОК. МӘХӘББӘТ ТРАГЕДИЯСЕ. УСАЛЛЫККА КЕМ ӨЙРӘТӘ? ПӘЙГАМБӘР ҮЧ АЛА.

Җәннәттән сөргәч тә аллаһ тәгалә атабыз Адәм белән анабыз Хаваны җиргә куып төшерә. Бер очтан Шайтан ләгыйнне дә шунда олактыра.

Син инде, хөрмәтле укучым, Адәм белән Хаваны бирелә берәр кыш әмәлләп кереп, тереклек итә башлыйлар, дип уйлый торгансың... О-а, Алланы белеп бетермисең шул әле син! Аның ачуына бер тарма, тарсаң — арма... Алла атабыз Адәм белән анабыз Хаваны, бергә түгел, икесен дөньяның ике читенә төшерә. Берсен Һиндстан илендәге Серандип атавына, икенчесен Мәккә тирәсендәге Җөдә тавына. Риваятьләрнең раславына караганда, ике яшь йөрәк, Сак белән Сок кебек, икесе ике якта берсен-берсе күрергә зар-интизар булып, нәкъ ике йөз ел тилмерешеп йөриләр. Көне бар, шомлы караңгы төне бар. Җиле-яңгыры, эссесесуыгы... Һәр тарафта, арыслан да юлбарыс, аю да бүре. Ул елан-чаян-

ның исәбе-хисабы юк, ниндиләре генә юк... Сагыш, кан-яшь... Әйтергә онытып торам икән. — Җәннәткә керткәч, алла боларның өсләренә ефәк хелләләр киерткән иде, җиргә сөреп төшергәндә салдырып алып калды. Яфрактан тегелгән гаурәт өрткечләрен табып алып кигәннәрдерме, юктырмы, анысы Коръәндә әйтелмәгән. Хәер, кигән булсалар да, күптән тузып төшеп калгандыр инде...

Ниһаять! Ниһаять! 201 елга чыккач, алланың мәрхәмәт-шәфкать хисләре уяна. Атабыз Адәмгә Мәккә тарафына барырга ишарә итә. Хаван шунда, ашык, әй Адәм!..

Ә кайда соң ул Мәккә? Карта дигән нәрсә юк әле, компас турында уйларга да түгел. Шулай да Адәм үзенең Хавасын эзләп таба. Алар Гарәфәт дигән тау башында кавышалар. Сөбехан алла!.. Тирә-якка күз атсалар, бөтенесе әзер. Мал-туарны, кош-кортны әйткән дә юк. Җеннәрдән калганмы, ничекме, — шәһәр, авылларга хәтле салынып куелган. Мәккәсе, Җөдәсе, Ямәне, Һиндстаны... Тауларның исемнәренә хәтле бар: Серандип, Гарәфәт, корабларга, юлларга хәтле бар. Кая кушсаң, шунда атландырып алып китәргә әзер дөяләр тора тез чүгеп.

Ләкин ходай тәгалә әллә бу турыда онытa, әллә безнең акыл ирешмәстәй бүтән бер уе була, Адәм белән Хаваны бу шәһәргә кертми, авылларга якын да китерми. Алла әмере буенча күктән очып төшкән фәрештәләр боларга, җәннәттәге төсле итеп, ак болытлардан чатыр корып бирәләр. Адәм белән Хава монысына сөенергә өлгермиләр, алла Адәмне үзенең җирдәге тулы хокуклы һәм гадәттән тыш вәкиле итеп, борынгычалатып әйтсәк, пәйгамбәр итеп куя.

Пәйгамбәр? Кемгә? Шул бер бөртек хатынынамы? Аллаһ тәгалә хәзерге заман кешесенең шундый сорау бирәсен белгәне хәлдә, атабыз Адәм белән анабыз Хавага бала үрчетү сәләтен гаять көчле итеп бирә. Дөрес, әдәпле вә тыйнаклы атабыз Адәм, оят саклап, янәдән 300 ел буена анабыз Хавага якын килми әле. Аның каравы, яше алтынчы йөзгә чыккач, үкенечкә калырлык итми... Ходаның рәхмәте, балалары да, балаларының балалары да бу мәсьәләдә әби-бабаларыннан калышмыйлар. Чагыштырмача кыска гына гомер эчендә атабыз Адәм белән анабыз Хава нәселе, — ишетмәсәң ишет, — 100 мең кешегә житә!.. Менә кемнәргә пәйгамбәр була атабыз Адәм.

Ләкин нәсел үрчетүдә шундый уңышларга ирешсә дә, атабыз Адәм, пәйгамбәр буларак, дин юлында зур эшләр күрсәтә алмый. Хәтта беренче балаларына баш була алмый дисәк тә дөрес булыр.

Эш шунда ки, боларның беренче корсактан Кабил белән Әкълимә исемле игезәкләре була. Күп тә үтми, Һабил исемле тагын бер ир балалары дөньяга килә. Үсеп буйга житкәч, ике туган бер кыз тuганга гашыйк булмасынмы!

Ул заманда шәригать шундый: бер корсактан туганга өйләнергә ярамаса да, бер ата-анадан туганга ярый. Адәм Әкълиманә Һабилгә бирмәкче, ә Кабилнең үз шәригате. Ул әтисенә: мин олы, башта син мине өйләндерергә тиеш, ди.

Ах, нигә инде шунда пар-пар итеп яратмадың ходаем?!. Адәм шулай дип зарлангандырмы, юктырмы, безгә мәгълүм түгел. Ләкин Коръәндә вә һәм риваятьнамәләрдә шунысы бик ачык: Адәм шәригатьне боза. «Әнә аллага корбан чалыгыз, алла кайсыгызның корбанын кабул итсә, кыз шуныкы», — ди. Чалалар. Алла Һабилнекен кабул итә. Ләкин Кабилдәге мәхәббәт ялкынын шәригать тә, эти белән алланың риза булу-булмавы да сүндерә алмый... Нәтиҗәдә Кабил Һабилне таш белән бәреп үтерә дә, Әкълимәне урлап, Ямән иле тарафына элдертә.

Хәзер без дин әһелләре алдына шундый сорау куйыйк: Кабилне таш белән бәреп үтерергә кем өйрәтте икән? Ул чак дөньяда атабыз Адәм белән анабыз Хавадан гайри бер адәм заты юк бит әле. Гаепне тагын

Шайтан өстенә ташлыйкмыни инде? Ярый. Ә соң алайса ул Шайтан дигәнебез мондый усаллыкка үзе каян өйрәнгән?

— Үзлегеннәнме?

Авызыңнан җил алсын, мулла абзый, тәүбә диген, моның белән син Коръәнгә каршы киләсең бит. Хәтерендәме, фәрештәләр аллага нәрсә диде: «Син өйрәткәннәрдән гайри без бернәрсә дә белмибез», — диде түгелме? Ә Иблис кем? Ул да фәрештә генә түгелме соң? Имеш, җәмгы фәрештә, шул җөмләдән Җабраил, Исрафил, Мөнкир белән Нәкир кебекләр белмәсен, алланың дәрьгаһыннан сөрелгән Иблис фәрештә белсен!.. Юк, моны икърар итү — үзе зур гөнаһ эштер дип беләм мин.

Кыскасы, Кабил таш белән бәреп үтерү һөнәрен үзлегеннән белгән дияргә бертөрле дә нигез юк. Кабил әле алла өйрәтеп торганны да үзләштерә алмый интегә. Алла, бар инде, шул юньсезне мәет күмәргә өйрәтеп кайт, дип моның янына козгын җибәрә. Козгын, тәҗрибә уртаклашу тәртибендә, күрсәтеп бирә. Әнә шунда да әле энекәшен күмә алмыйча интегеп бетә Кабил.

«...Кайгы миңа! — ди ул.— Шушы козгын кебек итеп, туганымның ялангач тәнен дә томалый белмим бит...»

*(Коръән, «Ризык» сүрәсе, 34 аять.)*

Бәс шулай булгач, Кабилгә үзенең энекәшен бәреп үтерергә кем өйрәткән булып чыга? Кыйссадан хисса, җирдә кешеләр ишәйгәч, аларны эчәргә, урларга, зина кылырга һ. б. һ. б. бозыкларга кем өйрәткән булып чыга? Ничек кенә боргалама, алла үзе, шулай түгелме? Без үзебез бер дә, бер дә икеләнмичә шулай дибез.

Читкә кителде. Әйтәсем килгәне: атабыз Адәм, пәйгамбәр башы белән әнә шул бер улына да баш була алмады. Ниһаять, алла каршында бернинди хезмәт күрсәтә алмыйча, Коръән теле белән әйтсәк, мең елдан илле ел ким гомер итеп, дөнья куйды.

Атабыз Адәм белән анабыз Хавага йөз меңле нәсел үрчетерлек җегәр вә сәлэт бирүе өчен аллага ихлас күңелдән хәмед әйтик. Атабыз Адәм белән анабыз Хаваның бу мәсьәләдә күрсәткән тырышлыкларына хәйран калганыбыз хәлдә, йөзләребезне кыйбла тарафына юнәлдереп, кулларыбызны күтәреп, дога кылыйк: авыр туфраклары җиңел булсын. Амин!..

Коръәннең онытканда бер ычкындырып ташлаганнары буенча, алланың кешене үзенә охшашлы итеп ясаганын белгән идек. Ә ул аны тышкы кыяфәте белән генә түгел, эчке табигате белән дә үзенә охшатып ясаган икән: Адәм пәйгамбәр дә бер баласын үги күрә, берсен үз итә. «Үзенең Шист исемле улын, башкалардан аерып, аерата бер сөю белән сөяр иде. (Нәкъ безнең замандагыча: кешенең кешелек сыйфатына карап түгел, кулыннан эш килгәнгә-килмәгәнгә карап түгел, — аерата бер сөю белән сөйгәнгә — Г. Г.) Үлгән чакта Шистны үз урынына патша итеп калдырды».

*(«Тарихел әнбия», 4 бит, «Әнба-эл-әнбия», 16 бит.)*

Бер биргәнгә бирүчән алла Шистны атабыз Адәм урынына пәйгамбәр дә итеп куя. Шистның табигатендә исә, алла сыйфатларының тагын да «изгерәге» ачыла. Бер Адәм белән Хава гөнаһысы өчен алла кыямәткәчә бөтен кешеләрне җәзага хөкем иткән кебек, бу да бер Кабил өчен аның бөтен нәселеннән үч ала: аларга каршы сугыш ача, бөтенесен кырып бетерми торып, кылычын кынына тыкмый, бер очтан патшалыгындагы йөз мең кешенең бөтенесен, ягъни үзенең бөтен кан кардәшләрен, бала-чагаларын үтереп бетерә.

Бу пәйгамбәрнең алла каршында башка хезмәтләре мәгълүм түгел. Хәер, безгә гыйбрәт өчен шунысы да җитеп беткән!.. Алла аны Кабил

мөртәт пычраткан җирдә калдырмый, үз янына ала. Җиргә пәйгамбәр итеп Идрис дигән бер бәндәне билгели.

Инде монысының хезмәтләренә килсәк, бер алла каршында гына түгел, бөтен кешелек дөньясы алдында гаять зур. Ул кешеләрне сыйныфларга, патшаларга, әмирләргә һәм дә кара халыкка аерып чыга... Мәсәлнең морале шулдыр ки: бәс, шулай булгач, патшаларга, байларга кырын карарга безнең хакыбыз юк. Алла кушкан, пәйгамбәр аерып куйган! Шулай килгән, шулай барачак. Кара, орына күрмә, гөнаһлы булырсың!

Әлбәттә, Идрискә алла моның әҗерен бирепме бирә. Әҗәле җиткәч, үтерми, мәңге гомерле итеп, үз янына күккә күтәрә.

## 2

## КИРЕ БЕТКӘН КЯФЕРЛӘР. ТУФАН ӘКИЯТЕ. ЯНӘ ДУҢГЫЗ КЫЙССАСЫ.

Шуннан алла тагын берәүне пәйгамбәр итеп билгели. Тагын, тагын...

«Алла кешеләргә пәйгамбәр итеп кешеләр дә, фәрештәләр дә җибәрә».

*(Коръән, «Хаҗ» сурәсе, 74 аять.)*

Пәйгамбәр дә пәйгамбәр... Сыйныфларга бүлендек, үтерешергә өйрәндек, тагын нигә кирәк булды соң әле алар?

— Халыкны дин юлына өндәү өчен, аллага ышансыннар өчен, — ди Коръән.

Ләкин бу җавап безне канәгатьләндерми. Менә ни өчен: Адәм белән Хава алланы күреп беләләр ич. Уллары, оныклары ата-бабадан ишетеп белә... Белә, ә ышанмый! Фәрештә арты фәрештә, пәйгамбәр арты пәйгамбәр килеп кенә тора, ниһаять, хәтерегездәдер, бер мәлне алла үзе дә җиргә төште, кеше күзенә күренеп йөри. Җирнең чит-читен кисеп чыга, судларга кереп утыра. Ә кеше — ходаның хикмәте — барыбер ышанмый. Ышанмый — бетте-китте. Алла бу уңай белән яман зарланып:

«Колларымның эшләре харап! Ничә пәйгамбәр җибәрдек, берсенә дә ышанмыйлар, барсын да мыскыл итәләр», ди.

*(Коръән, «Ясин» сурәсе, 29 аять.)*

Алай гынамы соң!.. Әз генә дә тартынып тормый кешеләр, күзләрен күккә чекрәйтеп, алланың үзен мыскыл итәләр әле. Таштан, я агачтан сын ясап куялар да, безнең алла менә шушы, диләр.

Монысы да, Шайтан ләгыйн кулыдыр дисез? Ләкин — әлеге дә баягы — алла аңар, бөтен кешене дә юлдан яздырырга юл куймам, диде бит... Хәзер безнең башка ихтыярсыз шундый сорау килә: ул Шайтан ләгыйн алланың бөтен аллалык серләренә төшенеп житеп, властьны үз кулына алдымы икән әллә? Югыйсә, дөнья һич кенә алла дигәнчә бармый бит... Кыскасы, Адәм үлеп, нибары 692 ел үтүгә (Коръән әйткәнчә, кешенең ул заманда меңәр ел яшәгәнен искә алсак, бу бик кыска гомер) алла дөньяга Нух дигән адәмне пәйгамбәр итеп билгели. Монысы да «дөньяда меңнән 50 генә ел ким яши» һәм шуның 500 елын пәйгамбәрлек хезмәтенә багышлый.

*(Коръән, «Үрмәкүч» сурәсе, 13 аять.)*

500 ел! Бу вакыт эчендә әзме чапкандыр ул, әзме тырышкандыр, әзме изге сүзләр сөйләп, вәгазь-нәсихәт кылып, халыкны алла юлына

өндәмәгәндер!.. Карап карасаң, нибары 80 кеше, шул җөмләдән өч улы белән өч килене иман китерә. 10 елга бер ярым кеше!.. Халык көлә генә. Башкага ни сан, хатыны белән бер улы да моны шулай ук тилегә санап, иман китерми.

— Түгел, мине бу эшкә алла үзе җибәрде.

— Син безнең кебек үк кеше. Аерма тик шунда: син шыр тиле, синә ышанса да үзең кебек тиле кабахәт җаннар гына ышаныр... Яхшы чакта тай моннан!.. «Югыйсә, таш белән тукмап ташларбыз үзеңне».

*(Коръән, «Шагыйрьләр» сүрәсе, 116 аять, «Һуд» сүрәсе, 29—30 аятьләр.)*

**Кабахәт җаннар гына ышаныр...** Һәм бу, күрәсең, чын мәгънәсендә шулай була да. Икенче бер заман кяферләр Нух пәйгамбәргә:

«Синә шундый түбән җаннар ияргәнне күрә торып, без синә ияребезме соң!» диләр.

Бәлкем, бу 80 кеше кяферләр күзлегеннән караганда гына шундый түбән җаннардыр? Юк. Кяферләрнең 80 мөселманга биргән бәяләре белән Нух үзе дә килешә. Ул, тик алар өчен мине генә гаеп итмәгез, дигән кебек итеп:

«Ә мин аларның элек нишләп йөргәннәрен белмәдем», ди. «Үзләре иман китерәбез дип торганда мин аларны куып җибәрмәм ич инде».

*(«Коръән, «Шагыйрьләр» сүрәсе, 112—114 аятьләр.)*

Көн бәхәс, төн бәхәс... Күрәсең, теңкәләренә тиеп беткәндер, ниһаять, Нухны тотып алып, кыйнагандыр. Инде Нух киңәш сорап, аллага мөрәҗәгать итә:

«...Мин халкымны көн-төн дингә өндәдем. Берьюлы да, берәмлекләп тә аңгәмә кылып карадым, ләкин аларның кяферлекләре генә артты, колакларына бармак тыктылар, башларын киемнәр белән төрделәр...»

*(Коръән, «Нух» сүрәсе, 5—8 аятьләр.)*

Укучы хәзер, әлбәттә, алланың Нухка халыкны дингә өндәү юлында нинди дә кыенлыклар биргәнен көтә. Ә алла, беләсезме, нишли? — таңга кадәр уйлап ятсагыз да белә алмыйсыз. Алла үзенең пәйгамбәренә менә нәрсә ди:

«Ә син алар кылган эшкә бер дә уфтанма. Аларның шулардан гайриләре барыбер иман китерәчәк түгел».

*(Коръән, «Һуд» сүрәсе, 38 аять.)*

— Ә соң китерәчәк булмагач, мине 500 ел буена ни дип чиләндердең?.. — Нух аллага шулай дип шикаять иткәндерме юктырмы, — ул кадәресе безгә тагын мәгълүм түгел. Алла исә шул ук сүрәнең 39 аятендә Нухка менә нинди боерык бирә:

«Минем күз алдымда, мин күңеленә салган рәвештә итеп, бер көймә ясә. Ә халыкны иман китертү хакында минем белән сөйләшеп тә торма; алар батырып үтереләчәк», ди.

Дөньяны яратканда алла һәрнәрсәне үзе ясады бит. Нух та, анардан күрмәкче, эшкә бер үзе керешә. Ә көймәнең нинди максат белән ясалганын белмәгән кешеләр көлә:

«Нихәл, әүвәлдә пәйгамбәрлек дәгъва кылыр идең, инде балта остасы булдыңмыни?»

*(«Әнба-әл-әнбия», 20 бит.)*

Көймә эшләнеп беткәч, Нух, алла боерыгы буенча, бер елга житәрлек азык төйи һәм иман китергән 80 мөселманны, тагын һәртөрле җан иясеннән берәр парны шунда тутыра.

«Көймә тауга тиң дулкыннар эчендә йөзеп китте. Һәм Нух (алланың, кяферләрне утыртма, диюенә карамастан, хәзергечә итеп әйтсәк, үзенең хезмәттәге халәтеннән файдаланып — Г. Г.) аерылып калган кяфер улын көймәгә чакырды: «Әй, улым, кил безнең янга, кяферләр белән калма».

*(Коръән, «Һуд» сүрәсе, 44 аять.)*

Үҗәтлеге beләнме, алла боерыгына буйсыныпмы, малай кул гына селти.

Көймә күздән югалды. Кырык көн яңгыр явып, бөтен дөньяны су басты. Иң биек тау ташлары 40 аршын су астында калды. Җәмгы кяферләр; шул исәптән Нухның кяфирә хатыны, имансыз улы, бер очтан дөньядагы барлык җан ияләре батып үлде.

Көймә алла планы буенча, алла күз алдында ясалган булса да, юлга чыгу белән бер җитешсезлегє беленә. Бәдрәфе юк!.. Әгәр теләсә, алла бу хакта шундук Нухның күңеленә салган булыр иде. Нух, алла рәхмәте белән әдигәнче әмәлләп тә куяр иде. Юк, алланың бу мәсьәләдә үз уй-фикерләре бар. Ул, әллә барча мәхлукларны яраткан чакта ясаганын оныткан, әллә Нух көймәгә алырга онытып җибәргән, — тиз генә өр-яңа дуңгыз ясап, җан өрә. Һәм аңар юл буенча бөтен хайваннарның, шулай ук 80 мөселманның һәм Нухның үзенең фәлән нәмәрсәсен ашап барырга әмер бирә.

Алланың зирәклегенә таң калмаска мөмкинме! Тагын бер атуда ике куян. Бердән, көймәне чистартучы булды. (Хайваннарның вә кешеләрнең кысталганнарын күреп, каты борын хәзер килеп житә...) Икенчедән авырга килә дип, алла Нухка мамонт дигән хайванны көймәгә алдыртмаган иде, нәтиҗәдә бер төр хайванның кимү куркынычы көн кебек ачык иде, — алланың яңа иҗады — аяк урынына тояк бирде!.. Илһам бер килә башласа, килә дә тора икән ул: әллә очынып китеп, сычкан дигән бер зат ясап ташлый. Мәзәк кенә, кечтик кенә, йомшак кына... Ул колаклары, ул күзләре, ул койрыгы...

Илһамын — илһам... ләкин бу — алланың нәүбәттәге хатасы булып чыкты. Сычкан шундук көймә төбен кимерә башлады. Ләкин, алла бер дә аптырап тормады, арыслан төчкерегеннән мәче дигән бер мәхлук ясап, сычкан өстенә җибәрде. Сычкан ярыкка кереп посарга мәҗбүр булды.

Көймәнең туфан эчендәге сәяхәте турында безгә бүтән нәрсә мәгълүм түгел. Унычы айның беренче көнендә (бу срокны хәтерегездән чыгармагыз) алла җиргә суны эчәргә кушты, көймә төбе Җөдә тавы башына килеп терәлде. Ниһаять, мөселманнар җиргә аяк басты. Гомуми тантана.

*(Коръән, «Нух» сүрәсе; «Киртәләр» сүрәсе, 57—62 аятьләр; «һуд» сүрәсе, 25—51 аятьләр, «Шагыйрьләр» сүрәсе, 105—122 аятьләр.)*

Хикәясе кыска гына булса да, үтә гыйбрәтле, шулай түгелме! Әй бәндә, кара аны, аллага буйсынмасаң, сиңа да шул көн киләчәк! дигән кисәтү ята аның төбендә.

Тик хикәясенең очы очка килеп бетми шул, шунлыктан ул бездә бер-аз шик тудыра. Беренчедән, туфан вакыйгасы белән кызыксынган галимнәр исәпләп чыгарган: бөтен җирне, шул исәптән иң биек тау башларын кырык аршын су астында калдыру өчен су җирдәгедән унике өлеш күбрәк булырга тиеш. Ә куктә бер сукыр мәче баласын батырып үтерерлек тә су юк. Су мәсьәләсе бездә тагын бер сорау тудыра. Ярый, туфаннан соң җир бөтен суны эчеп бетерде ди. Ә соңыннан хәзер без белә торган диңгезләр, елгалар, күлләр, чишмәләр каян һәм нидән хасил булды? Җир суны яңадан чыгаргандыр, дисезме? Соң бит җир

эчендә ул сулар җәмгысе бергә кушылып бетәргә тиеш, ә безнең җир йөзендәге суларның тәме бер-берсенә охшамаган. Хәтта диңгез суларының тәме һәм составы бер түгел. Аларның тозы 8 процентлылары бар, 40 ка житә торганнары бар. Икенчедән, туфан кайтканда, имештер, көймә тәбәнәк кенә Җүдә тавы башына килеп терәлә, ә биеклеге 8 километрлы Һималай таулары һаман су астында әле!..

Инде көймә турында. Көймә һәртөрле җан иясеннән берәр парны сыйдырырга тиеш. Үз тирә-юнендәге җан ияләрен генә күздә тотканда бу мөмкин дә кебек. Ат, сыер, кәҗә, сарык, тавык-чебеш, каз-үрдәк... Ә бит хайваннар дөньясы синең ишек алдындагы мал-туар белән генә чикләнми. Аның бер исемдәгеләре дә бер генә төрле түгел бит әле. Мәсәлән, эт. Сукыр тавыкка бар да бодай дигәндәй, бөтенесе эт. Ә аның 200 гә якын төре бар. Көймәгә кайсын алырга? Барысын да. Чөнки йорт куяныннан урман куяны тумаган кебек, такса токымыннан беркайчан да ау эте тумый. Кырмысканың бөтенесе кырмыска. Ә җир йөзендә аның унбиш меңләп төре бар! Яки менә күбәләк. Карап торырга бөтенесе күбәләк. Ә фәнгә аның туксан мең төрле төре билгеле! Токымнарын саклап калыйм дисәң, һәр төрен алырга тиешсең. Син берсен генә алмассың. Ә ул җиләк-җимеш бакчалары өчен иң кирәклесе булып чыгар, ягъни серкәсеннән алма корты ясала торганы!.. Алла сакласын, андыйны калдырырга ярыймы соң? Әйдә, бөтенегез дә кунаклагыз көймәгә!.. Җир йөзендә 3.500 төрле имезәк хайван яши. Шуышып йөри торганнар 5.500 төрле. Үрмәкүч сыманнар 30.000. Бөҗәкләрнең төре 75.000 гә җитә. Буынтыкларны җыйсаң, үзләре генә дә 80.000. Ә кошлар? Алар да ун ай буена һавада очып йөри алмый бит. Ә аларның төре артык та түгел, ким дә түгел 146 мең.

Җыя торгач, җәмгы төр мәхлук бер миллион 200 меңгә тула. Һәр төрдән бер ата, бер ананы алырга кирәк. 2 миллион 400 мең дигән сүз! Шулар өстенә 80 мөселман һәм Нух үзе! Тагын бөтенесенә бер елга житмәле азык! Имештер, шуларның бөтенесе бер көймәгә сыеп бетә!!! Аныcы бер хәл әле, ул 2 миллион да 400 мең җан иясен ничек, кайчан җыеп бетермәк кирәк! Хәтта иң көчле микроскоп аша күренми торган микропларны да калдырырга ярамый бит. Бигрәк тә бизгәк, чахотка, дизентерия микробларын; свинка, рожа, трахома, сифилис, бруцеллез, сары авыруы, тимрәү, рак микробларын. Тагын тифнекен. Тимгеллесе бар, кайта торган дигәне... Берсен алып икенчесен калдырып кара син!.. Мәсәлән, эч тифенекен. Тимгелле тиф микробы белән эч тифен әллә нинди догалар укып та йоктыра алмыйсың. Чума белән дә шул ук хәл. Ваба белән дә. Ваба белән безне борча тәэмин итеп тора. Тагын шуны онытмагыз; һәрбер борча түгел (аларның төрләре меңгә якын). Биредә, нәкъ кызыл күсенеке кирәк. Күсесе булгач, борчасыз булмас, дип, һич тә тынычланырга ярамый. Нәкъ син алган күсе борчасыз булып чыгуы мөмкин. Ә бу инде кешеләрне ваба чиреннән мәңгегә мәхрүм итү дигән сүз булыр иде. Ярамый... Алла Нух пәйгамбәрнең зиһенен җуймасын да, Нух онытып куймасын диген инде... Тагын бума ютәл, скарлатина, дифтерия кебекләрне онытырга ярамый. Алар аллага яшь балаларны, бигрәк тә имчәк балаларын газаплап үтерергә кирәк булачак.

Иң кыены шунда: 510 миллион квадрат километр җир йөзенә сибелгән бит ул мәхлуклар! Тагын шунысы: диңгез артларындагы илләрдә, мәсәлән, Америкада яши торган кыргый хайваннарны ничек барып алып килмәк кирәк? 500 ел буена өндәп-өндәп, бер хатынын дингә кертә алмаган пәйгамбәрнең шул тикле хайванны тыңлата алуына ышану айһай кыен. «Бала-чагаларың ник чәнчелеп китми, хатыныңны ал да әйдә минем көймәгә», дип әйтеп кара әле син берәр хайванга, мәсәлән, арысланга!.. Аннан, моның өчен, арыслан телен белү кирәктер бит әле. Җәмгысе миллион 200 мең төрле мәхлукның миллион 200 мең төрле

телен белү кирәктер... Ә андый хасиятне алланың Сөләйман пәйгамбәрдән гайри берәүгә дә бирмәве Коръәннең үзендә үк ярылып ята!

Инде бичара мамонт турында. Имеш, алма син аны, — авыр. Аңа урын да күп кирәк... Ә авыр булу, зур булу — аның гаебемени? Аны кем шундый авыр итеп, зур итеп ясаган? Алла үзе түгелме соң? Аннан әнә фил белән мөгезборынны аласың бит, алар кечкенәмени, җиңелмени алар? Юк, бер миллион да бер йөз меңдә 99.999 төр хайванның нәселен саклап калып, фәкать берсен батырып үтерү — үзе егетлек түгел. Аю, бүре, шакал, төлке — җиһан корткыч, елан, бет, кандала, кырыгаяк кебек әллә ничә мең төрле хәшәрәтнең нәселләрен саклап калып, бер юаш мамонтның нәселен корытуны зирәк хөкем дип әйтмәс идем мин. Инде, алар кешегә зыян-зәүрәт кылып, теңкәләрен корытып тору өчен кирәк дисең икән, мин шуннан тәм табам дисең икән, — ул чакта азыктөлекне җитәрлек кенә итеп төятергә иде сиңа. Аның урынына бер пар мамонтны түгел, бөтен нәселен сыйдырырга булыр иде.

Безне тагын шунысы кызыксындыра: нигә шул тикле озак була ул туфан? Җан ияләрен тончыктырып үтерү өчен берничә минут та җитеп беткән ләбаса... Ах, шулаймыни, урманнар да, үләннәр дә, чәчкән игеннәр дә һәлак ителергә тиеш дисеңмени? Ул чакта әйттем исә кайттым... Шулай кирәк, әлбәттә. Пакьләргә икән, пакьләргә дөньяны!.. Кяферләрнең шул урманнарда ауга йөргән булулары, гөмбә җыйган булулары, агачларына орынып киткән булулары мөмкин. Ә иген кырлары? Аларны шул кяферләр чәчеп үстергән бит... Черетергә, җир йөзендә нәселен калдырмаска! Тик болай булгач, бездә шундый бер дөньяви сорау туа: туфан бетеп, җир йөзенә аяк баскан 80 мөселман нәрсә ашап яшәр икән соң? Нух үзе? Бер миллион бер йөз мең 99 мең 999 пар мәхлук — аю, бүре һ. б. һ. б. лар? Арысланга, мәсәлән, көн саен ярты болан яки бер кәҗә давай, төлкегә — куян. Ә алар һәркайсы берәр генә пар. Төлке берәрсен тотып ашады — нәселе бетте дигән сүз. Тагын шунысы: төлке ул «китек колак»ны ашарга ярамаганны ничек белергә тиеш тә, ничек ашамый түзәргә тиеш? Ачтан үлә башласа, ерткыч түгел, кеше берсен-берсе тотып ашый бит.

Мин үзем туфанны алланың бик үк акыллы хөкеме димәс идем. Ә Нух кавеме иман китермәгәнгә ачу итеп, бөтен җир йөзендәге хайваннарның берәр пардан гайриләрен батырып үтерүе — беткә ачу итеп тунны яндыру кебегрәк була шикелле. Ә кешеләр? Төптән уйлап карасаң, алар да гаепле түгел. Алла үзе хөкем чыгарып куйды бит, аларның шул сиксәннән гайриләре иман китерергә тиеш түгел, диде!.. Тагын сабыйның ни гонаһысы бар? Коръәндә бәян кылынмаган, ә күз алдына китерергә була. Бөтен җир йөзе тоташ диңгез. Коеп яңгыр ява. Җилдавыл, дулкын, дулкын кочагында миллион төрле мәхлук, миллионнарча кешеләр: аналар, балалар. Имчәк балалары әниләренә чытырдап ябышкан... Йөрәк өзгеч тавышлар, аһ-зар... йөзә белмәгәне шундук су төбенә китә, белгәне коры җир табуны өмет итеп, йөзеп маташа. Ниһаять, алар да суга гарык була.

Бу фаҗигане, нормаль кеше димим, берәр кеше ашаучы читтән күзәтеп торса, һушыннан язар иде, иң явыз ерткычның йөрәге ярылып үләр иде. Ә алла, шәфкатьле, мәрхәмәтле алла, «Без динсезләрне генә җәзалыйбыз» дигән алла аларның төркем-төркем су төбенә киткәннәрен, кулларын уып, үзенең кодрәтенә исе китеп, күктән карап тора. Моннан соң да алланы шәфкатьле, мәрхәмәтле димәсәң...

Инде җиһанда иң кабахәт эшкә дучар ителгән дуңгыз турында. Ике миллион да 400 мең дә 81 җан иясенең фәлән нәмәстәсен ашап торырга ул дуңгыз ничек өлгерде икән? — диясе килә. Ничек өлгерде икән дә кай җиренә сыйдырды икән? Икенчедән, адәмне яраткан кебек ял-

гыз итеп яратты бит алла ул дуңгызны. Хаваны ясаган кебек кабырга шәрифеннән бер иркәк тә ясап бирмәде. Шулай булгач, җир йөзендә нәселе ничек үрчеде соң ул каты борынның?

Үсемлекләр дә бездә зур шик тудыра. Аларның су астында өч тәүлек тә яшь алмый торганнары бар бит; аларның нәселе ничек исән калды икән соң, ходаем?..

Әйтергә кирәк, туфан әкиятенең табигыйгә бердәнбер якынрак җире — көймәне ясау. Ләкин аның да бер чатак җире бар. Нигә аны Нух ялгызы ясарга тиеш тә, калган сиксән мөселман ни дип 100 ел буена аның ясалганын көтеп, түшәмгә төкереп ятарга тиеш? Тагын ничек йөз ел эчендә берсе генә дә үлми аларның, үлми һәм үрчеми? Тагын ул көймәнең өске катын ясаганчы төбе ничек череп бетми? Янә килеп алланың Адәм белән Хаваны ятратканчы ясап куйган кораблары кая китте? Ясаганда кешеләр өчен диде бит аларны алла. Нигә Нух үзенең кавемен шул корабларга гына төямәде?

Бу әкиятнең табигыйгә якынрак тагын бер урыны бар: Нух үзе дә өч улы, өч килене генә исән кала, барлык мөселманнар, көймәдәге авыр шартлар нәтиҗәсе буларак, җиргә аяк басу белән үлеп бетәләр. Әйе, монысы табигый. Ләкин бу үзе бик четерекле бер сорау тудыра: нәселләрен дә калдырмыйча үтереп бетерерлек булгач, аларны 9 ай да бер көн көймәдә интектерү нигә кирәк булды соң? Шуның белән бергә Нухның аларны 500 ел буена дингә өндәп йөрүе нигә кирәк булды икән?

## 3

## КЕШЕЛӘР ЯНӘДӘН НИЧЕК ТАРАЛА? ТУФАН ӘКИЯТЕ КАЯН КИЛГӘН?

Шәфкатьле-мәрхәмәтле алла кешеләрне шул рәвешчә һәлак кылганнан соң аларның кабат үрчеп китүләре кызык кына. Алла бу эшне Нухның өч улы белән киленнәренә йөкли.

Бу турыда сүзне Коръәннең үтә гыйбрәтле бер җиреннән башлап җибәрү урынлы булыр. Туфанга кадәр кешеләр бар да ак тәнле булалар әле. Эшне Нухның Хам исемле угылы харап итә. Дөнья күтәрә алмаслык гөнаһ эшли ул. Гөнаһ шуннан гыйбарәт: көннәрдән бер көн үзләренең чатырына килеп керсә, этиләре йоклап ята. Җил чыгып итәген ачкан, тәнбаны (штаны) юк... Бу хәлгә (кем генә елмаймый үтәр иде икән) Хам, әлбәттә, шаркылдап көлә. Җитмәсә туганнарын алып кереп күрсәтә. Туганнары Хамны орышалар. Йөгереп килеп этиләренең зекерен томалыйлар. Шул чак Нух, уянып китеп, Хамга, у-у, йөзең кара булгыры, ди. Һәм, ходаның рәхмәте, шул ук минутта Хамның тәне каралып чыга. Билгеле инде, аның балалары да кара тәнле булып туалар. Җир йөзендәге кара тәнле кешеләр шул Хамнан тарала.

*(«Әнба-эл-әнбия», 19—24 б., Рабгузи, «Кассас-эл-әнбия», 47 бит.)*

Ышандык та ди. Ә соң алайса, Американың кызыл тәнлеләре, Азиядә яшәүче сары тәнлеләр кемнән тарала? Дин китаплары бу турыда әйтми. Әйтерләр иде, бу әкиятне язган кешеләр җир йөзендә Америка белән Азиянең барын да белми әле... Тик соңыннан, дин әһелләренә Америка, Австралия, Азия, Европа материклары мәгълүм булып, анда төрле төстәге кешеләр яшәгәне беленгәч, Коръәнне һ. б. дин китапларын аклау теләге белән мондый әкият уйлап чыгаралар:

«Атабыз Адәмне ясаган туфрак үзе бер генә уч булса да, аның эчендә ак, кара, сары, яшел, зәңгәр төсләр бар иде. Вә һәм дә пакь һәм арусыз бөртекләр бар иде. Адәм балалары шунлыктан төрле-төрле булып туды-

лар...» Ләкин дини язучыларның бу аклаулары әз генә орынуга сабын куыгы кебек шартлап юкка чыга. Хикмәт Адәмне ясаган туфракта булгач, Адәм балалары төрле сыйфатта булудан бигрәк Адәм белән Хава үзләре төрле төстә булырга тиеш иде түгелме икән соң?! Мәсәлән, бер як битләре кара, бер-бер ягы ак, борын — кызыл, маңгай сары, колак шәмәхә... Бер сүз белән әйткәндә, төштә күрсәң, котың очып уянмалы. Ә бит алар һәр икесе әйтеп бетергесез матур булалар. Аннан өч ата белән өч анадан тарала булгач, бер телдә сөйләүче өч ата — өч анадан тарала булгач, бездә тагын шундый бер сорау туа: нигә кешеләрнең телләре бер түгел? Әллә шул 6 кеше туфанга кадәр дөньядагы бөтен телләрне белгәннәрме? Дөнья йөзендәге 7 мең тел һәм шивәләрне белерлек галим булганнармы алар? Ул чакта бу фәукылгадә галимнәр турында нигә Коръәндә юк? Алланың Идрис пәйгамбәрне кием тегәргә өйрәтүе, икенче бер пәйгамбәрне калкан ясарга өйрәтүе кебек юк кына эшләр турында бар, ә инде мең төрле тел өйрәнү кебек ун мең елда да ирешергә мөмкин булмаган гыйлемлек турында бер сүз юк!

Тагын бер сорау. Монысы мулла абзыйлар сезгә. Кешеләрнең тәннәре төрле төстә булу — Адәмне ясаган балчыкның төрле-төрле булуыннан килә булгач, «Әнба-эл-әнбия» һ. б. дини китапларның әкиятләрен, кара тән — Нухның Хамга бәддога укуыннан башлана, дигәнен кая куябыз?

19 гасырда дин әһелләрен тетрәткән, диннең тамырына тагын бер кәррә балта чапкан үтә гыйбрәтле бер вакыйга була. Кырын эш кырык елдан соң беленә дигәндәй, туфан әкиятенең Тәуратка, аның аша Коръәнгә кайдан, ничек килеп кергәне фаш ителә. Рич исемле немец галиме эшли бу эшне. Ул Тигр елгасы буенда җир һәм ком катлавы астында күмелеп яткан бик борынгы бер шәһәрне эзләп таба. Тарихи шәһәр. Бу борынгы Ассирия мәмләкәтенең башкаласы, моннан 2.600 еллар элек мидиан дигән халыклар һәм вавилоннар тарафыннан тар-мар ителгән шәһәр булып чыга. Кайбер таш йортларга, гыйбадәтханәләргә кадәр бөтен килеш сакланган. Арада иң кадерлесе — Ассирия патшасының зур китапханәсе. Әлбәттә, китаплары кәгазьгә түгел, кирпеч ташларны уеп язылган. Хәрефләре дә безнең заман халыкларыныкы түгел. Шулай да, күп еллар өйрәнә торгач, галимнәр Ассирия әлифбасының серенә төшенәләр һәм күмелеп яткан бөтен китапларны укып чыгалар. Күп кенә әкиятләр арасында Коръән белән Тәуратта бәян кылынган Туфан әкияте дә бар. Нәкъ Коръән белән Тәураттагыча!..

Алла сакласын, бу диннең тагын бер нигез ташын җимерү ич!.. Дин әһелләре күтәрелеп бәрелә: ялган! Ләкин менә әлифбасы, үзегез укып карагыз.

— Ялган! Ассирия кешеләре үзләре Тәурат белән Коръәннән алып язганнар!..

Ә ул чакта бу хакыйкатьне кая куясыз, дин әһелләре? Тәурат дөньяга килгәнгә нибары 1.800 ел, шулай түгелме? Коръән «иңгәнгә» нибары 1300 ел. Туфан әкияте, аңарчы ничә гасыр яшәгәндер, Ассирия патшалыгының җимерелгәненә дә инде, алда әйтелгәнчә, 2600 ел!

Нух туфанының, алла гамәле булмыйча, бик борынгы бер халык әкияте икәнлеге әнә шулай фаш ителә.

Ә Коръәнгә ничек кергән соң бу әкият? Вавилоннар тарафыннан җимерелүдән 150 еллар элек Ассирия патшалыгы, яһүдләр иленә басып кереп, озак еллар аны үз кул астында тота. Табигый ки, яһүдләр шул чак Ассирия халкының күп кенә гореф-гадәтләрен үзләштерәләр, хәтта диннәрен кабул итәләр. Яһүдләрдә Туфан әкиятенең үз шартларына яраклаштырылган берничә варианты барлыкка килә, ә тора-бара бу әкият илаһи сүз, алла сүзе булып йөри башлый. Күп гасырлардан соң яһүдләрнең үз диннәре формалашканда ала сүзе булып Тәуратка кереп утыра. Аннан әз генә үзгәртелеп, Коръәнгә керә.

Без исэ хәзер бу турыда онытып торып, юри-мари гына, тарихка түгел, фәнгә түгел, Коръәнгә ышанган булып кыланыйк. Туфан дөнья йөзен төрле әшәкелекләрдән арындырды. Җәмгы динсез, җәмгы кяфер суга батып үлде, алар заманында яшәгән хайванга, кош-кортка хәтле суга гарык булды, алар белән бер суны эчкән, бер һаваны сулаган, бер кояш астында яшәгән мөселманнарга хәтле туфан нәтиҗәсендә үлеп бетте, бөтен нәселе корыды. Дөнья — дезинфекциядән соң бөтен хәшәрәтләрдән чистарынган алма бакчасы кебек чистарып калды. Бөтен дөньясында Нух үзе, Нухның өч изге килене, изгеләрдән изге өч улы. Болардан начар бала туу мөмкинме? Безнеңчә, юк, мөмкин түгел. Хәзер бакча бер кортсыз алма бирә башлаячак. Туфанның максаты да шул ич. Ләкин без уйлаганча булып чыкмый. Бу изгеләрдән моңарчы дөньяда булмаган әшәкелекләрне эшләүче әшәке нәсел тарала.

Анысы алдагы бүлектә.

4

### ИБРАҺИМ ПӘЙГАМБӘР ҺӘМ АНЫҢ МӘҢГЕ ЧИБӘР АБЫСТАЕ. ПӘЙГАМБӘРГӘ АСРАУ КЫЗ БАЛА ТАБЫП БИРӘ. МӨСЕЛМАНЛЫК МӨҺЕРЕ.

Нухтан соң аллаһ тәгалә безнең ерак бабаларыбызга пәйгамбәр итеп Ибраһим атлы кешене билгели. Монысы да тырышып-тырышып алла юлына өнди, монысына да беркем иман китерми. Башкага ни сан, хәтта үз этисе дә кулын гына селти. Тәре сатучы була аның этисе. Бик аптырата башлагач, юк белән баш катырып йөрмә әле! — дип, улын өеннән куып чыгара.

Коръән моның белән Ибраһимның этисен яман атлы итеп күрсәтмәкче. Ә безнеңчә, бу бик бәхәсле. Чөнки, йомшак кына итеп әйткәндә, Ибраһим үзе тиле-милерәк бер бәйләнчек бәндә була. Коръән моны үзе дә яшерми. Мәсәлән, ул бер заман халыкны дингә өндәп торган чагында кинәт йолдызларга күтәрелеп карый да: мин авырыйм икән, ди. Янәсе үзенең авырганын йолдызларга карап белә. Тегеләр (зәхмәте кагылмасын дигән кебек) моның яныннан чыгып сызалар. Шуннан Ибраһим пәйгамбәр мәҗүсиләрнең үзләре ясап куйган аллалары янына шыпырт кына килә дә, «ник ашамыйсыз, ник сөйләшмисез?» дип, бөтенесен кыйнарга керешә.

*(Коръән, «Сафтагылар» сурәсе, 86—91 аятьләр.)*

Дөрес, алда бәян кылыначак бер вакыйгага нигезләп, Коръән, Тәурат һәм башка дини китаплар Ибраһим пәйгамбәрне үтә кунакчыл, үтә юмарт кеше итеп, яманлыкка яхшылык үрнәге итеп күрсәтмәкчеләр. Ләкин без монысын да акыллылык үрнәге дип кабул итә алмыйбыз. Менә ул вакыйга:

Этисе куып чыгарганнан соң, берәр куыш корып, халыкны дингә өндәп яту урынына, пәйгамбәребез үзенең Сара абыстаен ияртә дә ил гизәргә чыгып китә. Йөри торгач, Мысыр фиргавене (безнеңчә әйтсәк: патшасы) җиренә килеп чыгалар. Фиргавеннең Сара абыстайга күзе төшә. Ибраһим сүз әйтми. Менә фиргавен Сара абыстайга кул сала башлый, Ибраһим тагын сүз әйтми. Алла булып алла, бу хәлгә ачигысы килеп, азгын патшаның кулын корыта, ә Ибраһим аллага дога кылып, аның кулын төзәтүен сорый. Дога кабул була, кул төзәлә. Фиргавен Ибраһим белән Сарага бик күп мал-туар, бихисап күп алтын-көмеш бүләк итеп озатып кала. Пәйгамбәр тәшәккердән гаҗиз...

Безгә калса, бу кыйссаны әкият итеп кенә дә кабул итә алмыйбыз. Берәр тәгәрмәче төшеп калган арба кебек, аның нәрсәседер житми. Кулын сузган өчен генә алла фиргавеннең кулын корыткангa, кул суз-

ган өчен генә фиргавеннең Ибраһим пәйгамбәргә шулхәтле мал-туар биреп, кадерле кунагыдай күреп озатып калганга ышанасыбыз килми. Тукта әле, Тәуратта ничек икән... Без Тәуратның Ибраһим пәйгамбәргә багышланган сәхифәләрен актарырга керешәбез... Әйттем бит, шигебез урынсыз булмаган!.. Без аннан үзебез эзләгәнне табабыз...

«Мысырга килеп житәрәк, Ибраһим үзенең хатынына әйтте: Мин беләм, син матур хатын, Мысыр кешеләре сине күреп кызыгырлар. Мине үтерерләр, ә сине исән калдырырлар. Син әйт аларга, мин аның сеңелесе диген. Синең аркаңда миңа да яхшы булыр, җаным исән калыр...»

Чыннан да шулай була:

«Фиргавеннең түрәләре Сараның искиткеч матур икәнен күрделәр, фиргавенгә кереп мактадылар, **фиргавен Сараны үзенең сараена алдыртты...»**

Күренә ки, монда роман бер кул сузу белән генә чикләнми, шактый тирәнгә кергән була. Менә инде хәзер без алланың фиргавен кулын корытканына гаҗәпләнмибез. Фиргавеннең дә Ибраһимга шулхәтле байлык бүләк иткәненә гаҗәпләнмибез...

Шуннан соң фиргавен Сара абыстайны тизрәк Ибраһим пәйгамбәрнең үзенә кайтарып бирә. Ә Ибраһим, юмартын юмарт та, хатыны өчен алган байлыкны патшага кире кайтармый...

«...Хатыны аркасында Ибраһимга да яхшы булды. Эре һәм вак терлекләре булды. Ишәкләре, коллары, кол хатын-кызлары, дөяләре булды».

*(Тәурат, «Яшәеш», 12 сурә, 11—16 аятьләр.)*

Әкияте күңелле генә, әйе бит. Балаларыгыз өчен тәрбияви әһәмияте дә зур. Менә үсеп буйга житәрсез, өйләнерсез. Ибраһим пәйгамбәр хәленә дучар булсагыз, хатыныгызны — хатыным димәгез, сеңелем диегез, хулиганнар теләсә нишләтсеннәр үзен, яклап маташмагыз. Бәлкем, үзегезгә дә яхшы булыр, Ибраһим пәйгамбәргә түләгән кебек сезгә дә түләп куярлар...

Хәзер укучыда, нигә соң монысы Коръәндә юк, дигән шик тууы мөмкин. Тарих фәне, күп кенә бәхәссез дәлилләргә нигезләнеп, моңар бик ачык җавап бирә: Коръәннең бик күп өлеше Тәураттан күчерелгән. Бәгъзе бер җирләре, хосусән Сара белән Мысыр патшасы кебек артык әдәпсез җирләре, йомшартыла төшкән. Бу очракта да шул хәл. Һәм Тәурат Ибраһим пәйгамбәр белән Сара абыстай маҗарасын бу килеш кенә дә туктатмый. Ибраһим пәйгамбәр, Сара абыстайны ияртеп урыннан-урынга йөри торгач, Герар дигән шәһәргә кереп чыга. Дөресен әйтсәм, үземне үтерерләр дип куркып, биредә дә ул Сара абыстайны сеңелем ди.

Юкка шүрләмәгән икән!.. Бу ил патшасы да Сара абыстайны күреп гашыйк була һәм, төннәрдән бер төн үзенең егетләре белән барып, урлап ук кайта.

Бичара Ибраһим... Ләкин алла ташламаса, бүре ашамас... «Алла төнлә белән Герар патшасының төшенә керә һәм әйтә аңар: син бу хатынны урлаган өчен үләчәксең, чөнки аның ире бар», — ди.

Герар патшасы Сарага әле тиеп өлгермәгән иде. Аллага әйтте:

«Бөек кодрәт иясе! Шулай ук син, ничек-ничек булганын белми торып, бер гөнаһсызга мине үтерерсеңмени? Ибраһим миңа Сараны, сеңелем, диде түгелме соң? Сара үзе дә «ул минем абыем» диде. Мин моны һич тә бозыклык эшлим дип эшләмәдем».

Һәм әйтте аңар алла:

«Бозыклык эшлим дип эшләмәгәнеңне беләм, шуңар күрә дә сине гөнаһ эштән тотып калдым, бу хатынга кул салырга юл куймадым. Инде хатынны иренә кайтарып бир, чөнки ул пәйгамбәр. Ул синең өчен дога кылыр, һәм син исән калырсың, халкың да исән калыр...»

«Һәм иртә торгач, патша үзенең колларын чакырып кертеп, бу сүзләрнең бөтенесен колакларына пышылдады. Коллар бөтенесе дә бик курыктылар».

«Патша Ибраһимны чакырып китерде һәм әйтте: син безне нишләттең? Синең миндә ни ачуың бар иде? Нигә син мине һәм минем мәмләкәтемне зур гөнаһка дучар итмәк булдың?»

«Ибраһим әйтте: **мин бу җирдә алла хөкеме йөрми торгандыр дип белдем,** хатыным өчен үземне үтерерләр дип курыктым».

«Һәм Герар патшасы Ибраһимга мең көшел көмеш, эре һәм вак терлек, коллар вә кол хатын-кызлар бирде. Сарасын да үзенә кире кайтарып бирде һәм әйтте Ибраһимга: менә синең алдыңда минем җирем. Кайда теләсәң, шунда яши бир».

«Ибраһим аллага гыйбадәт кылды. Алла Ибраһим хатынына ябышкан өчен патшаның аталык орлыгын корыткан иде һәм кол хатыннарның бөтенесенең дә карыннарын балага узмаслык итеп томалап куйган иде — ачты. Патшага да сихәт бирде. Патша өендәге хатын-кызлар бөтенесе бала таба башладылар».

*(Тәурат, «Яшәеш», 20 сүрә, 1—18 аятьләр.)*

Ләкин бу әкияткә бик тә ышану кыен. Менә ни өчен. Һәр ике патшаның сарайлары тулы хатыннар, кәнизәкләр, мәмләкәтләре тулы җиләк кебек кызлар. Ә патшаларның күзләренә, имеш, берсе дә күренми. Аларга давай Сара абыстайны!.. Инде килеп, Сара абыстайның яшен дә әйтсәк, әкият һәркемнең күз алдында тузга язмаган әкият булып калса кирәк. Сара абыстай Мысыр фиргавененең башын-күзен әйләндергән көннәрдә 70 яшендә була, Герар патшасы урлап киткәндә, артык та түгел, ким дә түгел, 80 нче яше бара!

Ибраһим пәйгамбәр тормышында, дөресрәге, Ибраһим пәйгамбәр белән Сара абыстай тормышында Коръәндә кайта-кайта бәян кылынган янә бер гыйбрәтле вакыйга бар. Аллаһ тәгалә Ибраһим пәйгамбәр белән Сара абыстайга бала бирми. Бу хәлгә алар икесе, бигрәк тә, пәйгамбәр үзе бик борчыла. Моның өчен ул Сара абыстайны әз битәрләми, күрәсең. Бик теңкәсенә тигәч, әйтә Сара абыстай:

— Асравыбыз табып бирсен соң, бар йокла үзе белән, — ди...

Шул кадәресе дә мәгълүм булсын, хәзер инде Ибраһим пәйгамбәр элеккеге кебек ни акыллы, ни җүләр түгел, хатынының тәнен сатып көн күрүче дә түгел. Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә дигәндәй, үзе дә нәмәхрәм нәрсәләрдән йөз чөерми.

Ул Сара абыстайның тәкъдимен күтәреп кенә ала:

— Ә?.. Күптән шулай диләр аны!..

...Асрау боларга менә дигән ир бала табып бирә. Исемен Исмәгыйль куялар... Хәзер Ибраһимның бөтен күңеле бала белән асрауда.

Ах, кызуы белән генә әйтеп ташлавы булган икән; бу хәлне күреп, Сара абыстайның көнчелек шәмнәре дөрләп кабына. Ә көнчелек, үзегез беләсез, ниләр генә эшләтми!.. Сара әби асрауның, Коръәндәге исеме белән әйтсәк, Һаҗәрнең, өч әгъзасын: борыны белән ике колагын кисәргә ант итә.

Һаҗәр, шундый изге пәйгамбәр сөяркәсе булса да, һәмишә кол бит әле, — үтерсәләр дә сүз әйтергә хакы юк. «Һаҗәр ризалык кылды». Ләкин шул чак арага Җабраил фәрештә килеп керә. Ул шаһит. Һаҗәр гаепсез, Һаҗәрне Ибраһим пәйгамбәр куенына кертеп җибәрүче үзең ич, Сара абыстай!.. Фәрештә бу кадәресен үк әйтми, әмма Ибраһимга әйтте:

«Сара Һаҗәргә золымлык кылмасын, алла риза булмас, диде. Ибраһим Сарага Җабраил фәрештә сүзен ирештерде». Ләкин Сара: «Антым-

ны бозмыйм»... — диде. Шуннан Җабраил фәрештә (компромиска керәп — Г. Г.), алайса Һаҗәрнең ике колагын тиш, ят әгъзасыннан бераз кисеп ал, диде. (Никадәр матур, изге, әдәпле вә әдәби сүзләр... Мондыйны шул изге Коръәннән дә дини китаплардан гайри һичбер каян табалмыйсың. Кулга төшкәндә укып кал...) Сара Һаҗәрнең ике колагын тиштә, ят әгъзасының кикриген кисеп алды. Ә үзен баласы белән бергә тауташ араларына илтереп ташлатты. Сара абыстай бераз тынычланды. Ләкин бераз гына... Төннәрдән бер төндә, җиде төн уртасында, абыстаебыз пәйгамбәрне тотып селки:

— Бала кирәк!..

— Булды бит инде...

Сара абыстай аның саен:

— Бала кирәк!

Пәйгамбәр төшенеп бетми, ә күктә төшенәләр һәм күннәрдән берkөн, ходаның рәхмәте, боларга ике егет килеп керә:

— Сәлам, — ди Ибраһим пәйгамбәр боларга һәм алларына кыздырылган бәти ите китереп куя. Болар ризыкка орынмыйлар. Ә абыстайга бер авыздан болай диләр:

— Уфтанма, абыстай, балаң була...

Бу вакытта, күрәсең, абыстай инде тәмам өметен өзгән була: «Сара абыстай тәмам шашынды, битен йодрыклый-йодрыклый: «Мин кысыр карчык», — дип кычкырды.

— Ходаның рәхмәте киң, абыстай!..

Егетләрнең сүзе раска килә. Чыннан да инде 90 яше белән барган Сара әби Ибраһим пәйгамбәргә менә дигән ир бала табып бирә.

*(Коръән, «Таркатучылар» сүрәсе, 24—30 аятьләр, «Һуд» сүрәсе, 72—76 аятьләр, «Әлхиҗр» сүрәсе, 51—55 аятьләр, Кассас-эл-әнбия, 1 җөзьә, 91 бит, Рабгузи, «Кассас-әнбия», Кыйссаи Исмәгыйль галәйһиссәләм, 84—93 битләр.)*

«Әнба-эл-әнбия» 90 яшьлек әбинең бала табу вакыйгасына игътибарга лаек бер ачыклык кертә. Сара әбигә: «Бала табарсың» дип хәбәр салган егетләр фәрештә булып чыгалар. Аларны Сара абыстай янына алла үзе җибәргән булып чыга.

Ә алла бу фәукылгадә эшне ни өчен эшли? — Тикмәгә түгел. Һәм аның бәләкәй генә булса да үтә гыйбрәтле тарихы бар. Ибраһим алладан бала сорап дога кылганда:

«Әгәр балам була калса, шуны синең ризалыгың өчен корбан кылыр идем», — ди.

*(«Әнба-эл-әнбия», 42 бит.)*

Суяр өчен бала? Тагын ничек тиле димисең инде бу Ибраһимны? Ләкин бу адарыну аллага бик ошый. Ул шундук Ибраһим янына төшеп, үзенең бик мәмнүн булганын әйтеп, менә нәрсә вәгъдә итә:

«Күккә кара, әгәр саный алсаң, шул йолдызларны сана. Синең токымың шул йолдызлар санынча булыр», ди.

«Сиңа һәм синең токымыңа үзең гизә торган Ханан илен мәңгегә бүләк итәрмен, ә үзем ул кавемнең алласы булырмын. Синең кавемең көчле һәм бөек булыр, җир йөзендәге бөтен халыклар синең кавемеңә буйсынып торыр».

*(Тәүрат, «Яшәеш», 16 сүрә, 1—2 аятьләр һәм 18 сүрә.)*

Ләкин — мин сиңа, син миңа... Алла Ибраһим пәйгамбәргә шундый бер шарт куя: ә син моның бәрабәренә минем боерыгымны тотасың, үзең исән чакта һәм үзең үлгәч дөньяга киләчәк токымнарың да тотсын:

гаурәтләрегезнең очларын кисегез. Бу синең белән минем арадагы килешүнең билгесе булсын».

*(Тәурат, «Яшәеш», 17 сүрә, 1—9 аятьләр, Рабгузи, «Кассас-эл-әнбия», кассас-эл-Исмәгыйль галәйһиссәләм.)*

Хәзерге заманда, мәсәлән, бер бик зур мәмләкәт башлыгы кечкенә мәмләкәт башлыгы белән бергә мәсьәлә буенча договор төзегәндә, кул куеп торма, аның урынына гаурәтеңнең башын гына кисеп бир, дисә, тегесе моны акылдан язган исәпләп, тизрәк аның яныннан таю ягын карар иде. Пәйгамбәр исә алланың бу шартын бик шатланып кабул итә. Инде, 99 яшенә житеп, тәмам сәлперәйгән карт булуына карамастан, шундук таш пычак белән гаурәтенең башын кисеп ала. Аннан инде 13 белән барган Исмәгыйльнекен кисә.

*(«Әнба-эл-әнбия», Ибраһим галәйһиссәләм кыйссасы.)*

Дин китаплары сөннәт йоласының башланып китүен шул рәвешчә итеп, һәм аны мөселманлык мөһере итеп бәян кылалар. Асылда исә сөннәт мөселманлык мөһере булудан ерак тора. Бу кыргый йола бик борынгы халыкларда ук була. Һәм алар бу йоланы яки алла ризалыгы өчен корбан йоласы итеп, яки бәлигъләк билгесе итеп үтиләр. Йола Америка белән Австралия жирләрендә яшәүче кайбер мәжүси диндәге халыкларда хәзергә кадәр сакланып калган, хәтта хатын-кызларда да булган бу йола. Сара абыстайның Һажәр туташның оят жиренең кикриген кисеп алу әкияте — шул кыргый йоланың чагылышы.

Хәзерге христианнар бу турыда белмиләр, поплар исә, исләренә төшергәнне яратмыйлар. Ләкин бу тарихи факт. Бу йола христианнарда да чукыну белән алмаштырылганга кадәр бик күп гасырлар яшәп килгән. Хәзерге көнгә кадәр хәтта «Гайсәнең» сөннәте (гаурәтенең башыннан кисеп алынган тире) 20 чиркәүдә саклана. Бердә түгел, 20 чиркәүдә! һәм һәр чиркәү беркатлы христианнарга үзендәгене асыл нөсхә итеп тәкъдим итә. Бу мәсьәләдә без башкача уйлый алмыйбыз: яки кимендә 19 чиркәү ялганлый, яки «Гайсә» 20 гаурәтле булган. Шунысы кызганыч, бу хакта дини язучылар үзләренең изге китапларына ачык итеп язып калдырмаганнар.

Алла белән Ибраһим пәйгамбәр арасындагы договорга кайтып шуны әйтик: алла сүзендә тора. Сара әбигә менә дигән бала бирә. Ләкин менә бәла!.. Ибраһим маңгаенда пәйгамбәрдән пәйгамбәргә күчеп йөри торган нур була. Ибраһим кияүләп ятканда бу нурны Сарага, балаң булгач, аңар күчертермен дип вәгъдә иткән була. Бала туа, нур юк. Ибраһим маңгаенда да юк. Сара абыстай эшнең нәрсәдә икәнен сизеп ала. Һажәр малаена бирдеңме? Шулаймы?! — ди ул һәм очып килеп Ибраһим пәйгамбәрнең якасына ябыша... Хәер, якага ябышу һәрбер ир башына килүе мөмкин булган гади бер семья жәнжалы, яхшы түгел, карап тормыйк... Кыскасы, 90 яшьлек әбинең баласы булды, алла вәгъдәсендә торды. Ә башка мәсьәләдә, турысын әйткәндә, пәйгамбәрне алла кәкре каенга тери. Ибраһим кавеменең элек түгел, соңыннан да күктәге йолдызлар санынча булганы юк. Бу кавемнең, ягъни яһүдләрнең, бөтен дөньяны беркайчан да үзләренә буйсындырып, үзләренә каратып торганнары юк. Хәзер исә, Израил дип аталган еврей мәмләкәте жир шарының бер почмагында кысылып калган зәгыйфь кенә, кечкенә генә бер мәмләкәттер.

Израил — анысы «вак» мәсьәлә, төп мәсьәләне онытмыйк. Аллага без мөселманнарны сөннәтле иткән өчен тәгәри-тәгәри гыйбадәт кылыйк. Әлбәттә, без Ибраһим алдында да бурычлы. Бу мөбарәк гамәл үрнәген безгә ул күрсәтә бит. Тик шунысы бераз аяныч: «Әлгыйсел әввәл» исем-

ле бер изге китап раславына караганда, теге дөньяга баргач, без әле янәдән, бер кәррә сөннәткә утырырга тиеш булабыз. Чөнки:

«Кешеләр каберләреннән купканда бөтенесе ялан аяк, ялан баш һәм сөннәтсез булачак».

5

### ИБЛИС ЛӘГЫЙН МӘЗӘГЕ. «КЫЗЛАРЫМНЫ ТЕЛӘСӘГЕЗ НИШЛӘТЕГЕЗ». ПӘЙГАМБӘР КЫЗЛАРЫ КЫЗЫК ИТӘЛӘР.

Без хәзер сезнең белән Коръәннең иң изге, иң гыйбрәтле сәхифәләрен ачарбыз. Мәчеттәге кебек тезләнеп утырыгыз, кулларыгызны тезләрегезгә салыгыз, мин башлыйм.

Ибраһим пәйгамбәр дин юлында хатынының тәнен сатып баю, асравы белән йоклау, сөннәт йоласын кертүдән гайри эш чыгара алмыйча фәни дөнья белән бәхилләшә. Шуннан соң алла пәйгамбәр итеп Ибраһимнның уйнаштан туган угылы Исмәгыйльне билгеләи. Үкчәсе белән җиргә тибеп чишмә чыгаруын исәпкә алмаганда, Исмәгыйль турында Коръәндә телгә алып сөйләрдәй нәрсә юк. Аның каравы Исмәгыйль белән бер үк чорда пәйгамбәрлек иткән Лут әфәнде дин ислам юлында кыяматкәчә онытылмаслык эшләр эшләп калдыра. Башта әле ул үзеннән алда килгән пәйгамбәрләр кебек гади генә эшләр эшли. Үзенең кавемен хак дингә өнди, аңар да шулай ук иман китерүче булмый, хәтта үзенең хатыны, хатынының ата-аналары да кул гына селти. Ә менә дөясе белән эте, ходаның хикмәте, иман китерә. Хәтта телгә килеп, халык арасында хуҗаларының хак пәйгамбәр икәнен сөйләп йөриләр. Халык исә барыбер иман китерми. Бу хәлгә тагын да катырак кычкырып көләләр:

«Ә-ә, син Лут агай, әле сихерче дә икәнсең! Бу эшләрне безләргә сихер белән күрсәтәсең икән, диделәр».

*(Әнба-әл-әнбия», 49 бит.)*

Шуннан артык нишләмәк кирәк? Нух пәйгамбәр кебек ул да кавеменә алланың берәр афәт җибәрүен үтенеп дога кыла. Һәм... Лутның да кыяматкәчә онытылмас эшләре менә шуннан башланып китә.

«Бер заман Шайтан бер бик гүзәл углан сурәтендә Лут кавеме арасына килеп керде. Арада бозыграк кешеләрне сайлап алып, аларга хатынлык итте. Бу бозык кешеләрдән күрмәкче, һәркем гүзәл углан сурәтендәге Шайтан мәлгунь белән кабахәт эшне кыла башлады. Аннан соңра кешеләр башка угланнарга да һәвәс кыла башладылар».

Лут ачыйгъланып:

«...Сез чиктән тыш бозык кешеләр, алла биргән хатыннарыгызны ташлап ирләр белән торасыз», — дип тә бакты.

*(Коръән, «Киртәләр» сүрәсе, 78—79 аятьләр.)*

Ләкин халыкның карты-яше аның саен котыра гына барды. Шайтан исә моның белән генә дә туктап калмады. Им-томчы хатын сурәтенә кереп, хатын-кызга да катнашып йөри башлады, аларны да бер-берсе белән якынлык кылырга өйрәтте».

«Менә бер кичне хәзрәте Лут өенә бик гүзәл ике егет килеп керде. Лут үзенең кызларына аш-су әзерләргә кушты. Егетләрне тиз генә сыйлап, озатмакчы булды. Чөнки ул, шәһәр кешеләре күреп алып, бу егетләрне дә мәсхәрә кылырлар дип хафалана иде».

Һәм шулай була да.

«Лутның хатыны Лутка дошманлыгы сәбәпле, төнлә шәһәр халкына хәбәр салды: «Лутка бик гүзәл ике егет килде, барып карагыз», диде.

Ярты төн авышкач, берничә йөз кеше җыелышып Лутның йорты янына килделәр. Менә ат менгән патша үзе дә ун вәзирен ияртеп килеп җитте. Җәмгы халык егетләрне күреп бик кызыктылар».

Лут боларны кертми. Вәгазь-нәсихәт кылырга керешә:

«Зинһар кабахәт эшкә һәвәс кылмагыз, кунакларымны мәсхәрә итмәгез, — ди. — Хатыннарыгыз урынына ирләр белән якынлык кылырсызмени?» — ди.

Һәм аларга, Ибраһим пәйгамбәр кебек үзенең инде сәлперәеп беткән Сарасын түгел, менә дигән гыйффәтле кызларын тәкъдим итә, мактыймактый тәкъдим итә:

«Я, минем халкым! — ди ул. — Менә сезгә кызларым. Алар сезнең өчен бу егетләргә караганда әйбәтрәк. Кунакларыма тигәнче, шушы кызларымны алыгыз да теләсәгез нишләтегез...»

Игътибар итегез, моны хак пәйгамбәр әйтә. Ләкин халыкка пәйгамбәр кызлары түгел, ирләр кирәк:

«Морадыбыз ни икәнне беләсең, тиз бул, безгә кунак егетләреңне чыгар!»

Анысы булмас!

Халык капканы ватып керә башлый.

Кунак егетләр дигәнебез, ходайның рәхмәте, кеше кыяфәтенә кереп йөрүче фәрештәләр икән. Фәрештәләр халыкның күзенә бер уч туфрак алып сибәләр, (башка вакытта күзгә күренми йөри ала торган фәрештәләр бу очракта бозык кешеләрдән качу өчен башка юл таба алмыйлар — Г. Г.) тегеләр (берничә йөз кеше бер уч туфрактан! — Г. Г.) — сукыраеп кала. Лут әлеге гыйффәтле ике кызын ияртеп шәһәрдән чыгып шыла.

Ә халык? Шәһәр?

«Таң вакыты житте. Җир тетри башлады. Бер бик каты тавыш ишетелде. Күктән таш ява башлады. Ахырда бөтен шәһәрнең асты өскә килде. Ниһаять, шәһәрне җир йотты». Нәкъ Нух туфанындагыча гөнаһсыз карт-коры да, бала-чага да, бишектәге сабыйлар да алланың каһәре төшкән шәһәр хәрабәсе астында тилмерешеп җан бирде. Мал-туар да, кош-кортлар да, **шул исәптән Лутның алла юлына өндәп йөргән дөясе белән эте дә (!!!)** афәттән качып котыла алмады. Ә Лутның кяфирә хатынын алла аерата бер җәзага дучар итте: аны тоз баганасына әверелдерде».

*(Коръән, «Шагыйрьләр» сурәсе, 165—175 аятьләр; «Кырмыскалар» сурәсе, 55—59 аятьләр; «Һуд» сурәсе, 79—84 аятьләр; «Әлхиҗр» сурәсе, 61—77 аятьләр; «Әнба-эл-әнбия», 48—51 битләр.)*

Дин әһелләре, атлаган саен, Коръәннең һәр сүзе, һәр хәрефе изге, гыйбрәт алу өчен иңгән, дияргә ярата. Ә соң Лутның бу маҗарасыннан без нинди гыйбрәт алырга тиеш булабыз? Шундый бозык кешеләр өеңә кереп кунагыңа ябышсалар, кызларыңны чыгарып бир, теләсәләр нишләтсеннәр, дипме? Ничек кенә боргаланма, моңардан бүтәнчә мәгънә чыгарып булмый. Ләкин Коръән юкка көчәнә, юкка безне андый «кунакчыллыкка, киң күңеллелеккә» өнди! Җир йөзендә мондый кабахәтлеккә барырдай һичбер адәм заты димим, алланың үзе белән шул Луттан гайри берәр ерткыч та табылачак түгел. Әйтергә кирәк, мәчеттә муллалар әле һаман бу аятьләрне бик тәмләп укыйлар, абзыйлар мәгънәләрен белмәгәннәре хәлдә, иреннәрен лепелдәткәләп, амин, амин дип утыралар.

Бу аятьләр уңае белән бездә мулла абзыйларга шундый сорау туа. Нигә ул фәрештәләр, бөтен шәһәрнең шундый бозык икәнен белә торып (аларның җирәнеч гадәтләрен ташларга өндисе урында), «матур углан нар кыяфәтенә кереп», болай да азган кешеләрнең күңелләрен аздырып

йөриләр икән? — Әлбәттә, мулла абзыйлар моңа да, алла рәхмәте, диюдән бүтәнчә җавап бирә алмыйлар.

Коръәндә Лут пәйгамбәр маҗарасы шул рәвешчә тәмам була. Дөресрәге, Ибраһим пәйгамбәр маҗарасы кебек киселә генә. Тәүратта исә бу кыргый әкиятнең дәвамы хәзерге көнгә кадәр сакланып калган. Әлбәттә, хәзер бик чыгарып ташларлар иде дә, акка кара белән язылган, бернишләтә алмыйсың. Һәм без ул юлларны укучыларыбызга рәхәтләнеп торып тәкъдим итәбез.

«Сигор шәһәре асты-өскә килеп җимерелгәч, халкы кырылып беткәч, Лут пәйгамбәр бер мәгарәгә кереп яши башлый. Әлеге кызлары да үзе белән. Чөнки Лут аларны Сигорда калдырырга курыкты».

«Олы кызы кечесенә әйтте: безнең әти карт инде... әйдә әтине аракы эчереп исертәбез дә **үзе белән йоклыйбыз.** Шулай итеп, җирдә әтиебезнең токымын калдырабыз».

«Һәм шул төндә үзләренең әтиләрен аракы эчертеп исерттеләр; Лутның өлкән кызы әтисе белән йоклап чыкты, ә Лут үзе кызының кайчан кереп ятканын да кайчан торып чыкканын да белми калды».

«Икенче көнне өлкән кызы кечесенә әйтте: менә мин кичә әти белән йокладым, бу төнне дә без аны аракы эчертеп исертик, һәм син әти белән йокла. Шулай итеп җирдә әтинең токымын калдырыйк».

«Һәм бу төнне дә әтиләрен аракы эчертеп исерттеләр. Кече кызы әтисе белән йоклады, ә Лут пәйгамбәр кызының кайчан кереп ятканын да кайчан торып чыкканын да белми калды».

«Лутның ике кызы да корсакка узды. Һәм өлкән кызы ир бала тапты, ул аңа, бу минем әтиемнән булды дип, Моав исеме кушты... Кече кызы да ир бала тапты. Һәм ул аңа Бен Амин исеме кушты.

*(Тәүрат, «Яшәеш», 19 сүрә, 30—38 аятьләр.)*

Күрәсең, ул заманда да матур кызда хәйлә күп булган икән. Әтиләре белән йоклау өчен нинди хәйлә корганнар бит... Ә безнеңчә, бу тәти кызлар бер дә юкка пәйгамбәрне исертеп мәшәкатьләнгәннәр. Кызларын үз кулы белән берничә йөз азгын ир хөкеменә чыгарып ташлауны гади эш санаган, алай гына да түгел, саваплы эш санаган пәйгамбәр аек килеш тә бу эштән тайчанмас иде!.. Мәсьәлә менә кайда. Бу изге пәйгамбәрнең изге кызлары ул аракыны каян алдылар икән, — шунысы гына бездә бераз шик тудыра. (Шәһәрнең асты-өскә килде. Тирә-якта җан иясенең дә, авылларның да әсәре калмады бит.) Сәлперәеп беткән, үзен-үзе белмәслек хәлгә килеп мәлҗерәгән карт бүген бер кызы белән, иртәгә икенчесе белән йоклавы, ә үзенең бу изге эшне хәтта сизми дә калуы шулай ук шикле.

Хәер, анысы янә «вак» мәсьәлә. Вак түгеле менә кайда: шушы кыргый җирәнгеч әкиятне Тәүрат буенча гамәл кылучы дин әһелләре күзләрен дә йоммыйча, аяк терәп аклап маташалар. Янәсе, пәйгамбәр кызлары моны бозык уй белән түгел, изге теләктән чыгып, җир йөзендә пәйгамбәрнең нәселен калдыру максаты белән эшлиләр.

Максаты әйбәт. Ләкин нәсел урчету өчен шуннан бүтән юл беткәнмени? Аллаһ тәгалә үзенең сөекле пәйгамбәренең нәселен саклап калу өчен кыргый хайван башына да килми торган, нәсел өчен зарарлы юлдан бүтән юл белмимени? Моның өчен башка илләрдә, шул ук Ибраһим угылы Исмәгыйль пәйгамбәрлек итә торган илдә, хатын-кыз беткәнмени? Әй, алла, алла! Сәер дә соң синең хөкемең, билләһи әгәр... Бер әйткәндә әйтеп калыйк әле. Ибраһим пәйгамбәргә байлык бирү ысулың да үтә сәер булды бит синең. Бу изге пәйгамбәрне баету өчен хатынының тәнен саттырып йөрүдән гайри юл тапмадыңмыни ?Аңар байлыкны үзеңнең бетмәс-төкәнмәс хәзинәңнән алып бирсәң дә була иде ләбаса!..

XVII гасырда яшәгән бөек француз язучысы Вольтер Лут пәйгамбәр маҗарасының асылын фаш итеп, тарих өчен зур хезмәт күрсәтте. Ул бу

экиятнең үз этисе белән йоклап бала табучы Адонис исемле кыз турындагы экияттән алынганын исбат итә. Һәм шундый зирәк нәтиҗә ясый:

«Адонис. — ди Вольтер көлеп, — үзенең җинаяте өчен җәзасын ала. (Аны халык кыйнап үтерә — Г. Г.). Ә Лут кызлары, дин әһелләре күзлегеннән караганда, алладан иң югары бүләк алалар. Изге пәйгамбәр балаларына ана булып, тарихка керәләр. Шунысы кызганыч: пәйгамбәрнең зинаның да зинасыннан туган бу изге балалары кем булып үсәләр, алардан кемнәр тарала, — анысы изге китапларда әйтелмәгән».

6

## ТАГЫН БЕР ПӘЙГАМБӘР ҮЗ ХАТЫНЫНЫҢ ТӘНЕН САТЫП БАЕМАКЧЫ. ЯКУП ӘФӘНДЕНЕҢ АЛЛАНЫ ҺӘМ ӘТИСЕН АЛДАП ПӘЙГАМБӘР БУЛУЫ.

Тегендә Ибраһим... монда Исмәгыйль... Әнә анда, мәгарәдә, үзенең кызлары белән Лут пәйгамбәр нинди изге эшләр кылып ята, ә халык барыбер иман китерми... Шуннан аллаһы тәгалә тагын бер шәһәргә Исхак исемле затны пәйгамбәр итеп куя.

Исхакны сез бераз белергә тиеш. Ибраһим пәйгамбәрнең Сара абыстайдан туган улы. Әти-әнисенең Герар илендә булган маҗарасын да хәтерли торгансыз. Бу маҗара Исхак пәйгамбәрне дә васвасәләндерә. Күчмә халыклардан буларак, 80 елдан соң Исхак та әти-әниләре эзеннән шул Герар иленә килеп чыга. Ходаның рәхмәте, Герар патшасы әле һаман исән икән, әле һаман шул Авимелах икән!..

Исхак пәйгамбәр дә, әти-әнисеннән ишетеп беләме, аллаһы тәгалә үзе моның күңеленә саламы, — шул юл белән баемакчы. Ул да үзенең хатынын «Бу минем сеңелем» дип йөри.

Ләкин авызы пешкән — өреп эчкән Авимелах Исхак хатынына Сара абыстайга гашыйк булган кебек бер күрүдә гашыйк булмый. Исхакны, хатыны белән шаярып ятканын тәрәзәдән күреп, үзенең чатырына чакырып кертеп, арт сабагын укыта.

«Хатының икән бит ул синең, нигә син аны сеңелем дидең?»

«Исхак әйтте:

Чөнки мин аның өчен үлмәгәем дип курыктым».

«Авимелах әйтте:

— Бу нишләвең синең, ә? Минем кешеләремнең берсе чак кына синең хатының белән якынлык кылмый калды. Безне гөнаһка батырасың икән ләбаса!..»

Кыскасы, Исхакның юлы уңмый, Герар патша, Исхак пәйгамбәрне, сукыр бер тиен бирмичә, куып чыгара.

*(Тәурат. «Яшәеш», 26 сүрә, 8—11 аятьләр. «Кассас-эл-әнбия», Исхак галәйһиссәләм кыйссасы.)*

Исхакның дин юлында шуннан гайри искә алырдай хезмәтләре безгә мәгълүм түгел. Аның каравы ике угылының берсе — Якуп пәйгамбәр турында без байтак беләбез.

Май чүлмәге тышыннан билгеле... Бу изге затның да буш кеше түгел икәнлеге туганда ук мәгълүм була. Дөнья йөзенә бер карында яткан игезәк туганының үкчәсенә ябышып чыга ул! Якты дөньяны беренче булып күргән Гаесне өлкән бала дип игълан итәләр, ә Өлкән булуның өстенлекләре бар. Мәсәлән, әтиләре үлә-нитә калса, мирас малы аңар ике өлеш тия. Ул заманда закон шундый. Якуп, моны белер яшенә җиткәч, өлкәнлекне ничек тә үзенә алырга әмәл эзли һәм таба да. Ничектер, көннәрдән бер көн Гаес үләр чиккә җитеп ачыгып кайта. Якуп абыйсының шул хәленнән файдаланып, аның өлкәнлеген бер җамаяк ясмык өйрәсе белән бер сынык арпа ипие бәрабәренә сатып ала. Гаиләдә Гаеснең үзенең теләге буенча өлкәнлектән баш тартуын, өлкәнлекнең Якупка күчүен игълан итәләр.

Якуп — Иаков — еврей сүзе. Аяк чалу дигән сүз. Исеменең җисеменә туры килеп торуын кара син!.. Ә икенче тапкыр Якуп Гаескә, күзләреннән ут күренерлек итеп, аяк чала. Дөрес, монысында Якупка әнисе Рәфка абыстай ярдәм итә. Һәм Якуп, Гаес кулына керергә торган пәйгамбәрлек мөһерен тартып алып, үзе пәйгамбәр була.

Ышанмыйсызмы? Алайса, әйдәгез, бергәләп укып карыйк.

Исхак пәйгамбәр, 133 яшенә житеп, күзләре тәмам сукырайгач, ике угылының берсен пәйгамбәр итүен сорап, аллага дога кылды. Алла карт пәйгамбәрнең теләген кабул итәргә булды.

Ләкин кайсын пәйгамбәр итәргә? Алла, күрәсең, ыгы-зыгы чагына туры килеп, сорарга оныта. Ах, бу картлык!.. Исхак та әйтергә онытып җибәрә. Ә күңелендә үзенең сөйгән улы Гаес була... Хәзер Исхак пәйгамбәр үзенең догасын төзәтмәкче. Шул уй белән Гаесне чакырып кертә дә, бар, улым, урманнан киек аулап кайт та миңа кәбап кыздырып бир, мин сиңа бер изге теләк теләрмен, ди.

Бу сүзне Рәфка абыстай ишетеп кала. Ә ул Гаесне түгел, 73 яшенә җитеп өйләнмәгән, гел үзе янында сырпаланып йөргән эшлексез Якупны аерата бер сөю белән сөя, шунлыктан нәкъ аның пәйгамбәр булуын тели һәм бик әйбәтләп хәйләгә керешә. Гаес ауга китү белән серне Якупка чишә.

— ...Ах, нишлибез соң, әни?

— Минем әйткәннәремне тыңла. Көтүгә барып, әйбәт кенә ике кәҗә бәтие алып кайт. Мин шулардан әтиеңнең яраткан ризыгын пешерермен, син шуны әтиеңә кертеп ашатырсың, әтиең сине Гаес дип белеп, изге теләкне сиңа теләр.

Якуп шөбһәләнә:

— Ә тәнемне капшап караса? Гаес җөнтәс тәнле бит, ә минем тәнем шоп-шома... Изге теләк урынына бәддога гына алырмын...

— Бәддогасы әнә минем өскә төшсен... Бар, әйткәнне тыңла.

Якуп тыңлый.

«Әнисе кәҗә бәтиләрен кыздырды. Якупка Гаеснең киемнәрен киертте, аның шома муенына, кулларына бәти тиреләре япты».

— Бар, кер.

«Якуп әтисе янына керде, әйтте:

— Әтием!

— Син кем, минем кайсы улым?

Якуп әйтте:

— Мин — Гаес. Мин син әйткәнне эшләдем. Торып утыр, мин атып кайткан киек кәбабен аша, минем җаныма изге теләк теләә».

Ата, күрәсең, шикләнә:

«Исхак Якупка әйтте: кил яныма, мин сине капшап карыйм:

— Син Гаесме, түгелме?»

«Якуп Исхак янына килде, Исхак аны капшап карады һәм әйтте, тавышы Якупныкы, куллары Гаеснеке... Тагын әйтте: син минем Гаесемме? Тегесе җавап бирде: әйе».

Исхак Якуп өстендәге киемне иснәп карады:

— Гаеснеке. Кәбабы да тәмле...

Исхак бу юлы да, аллә исемен әйтергә онытып, аллә анысын артык санап, **«шушы угылына»** изге теләк теләи:

«Җаным сине изге эшкә юлласын, — ди ул. — Алла сиңа күктәге чыклардан күп итеп, җир майларыннан күп итеп икмәк бирсен. Халыклар сиңа хезмәт итсен, кабиләләр сиңа буйсынсын, туганнарыңа баш бул, әниеңнең уллары сиңа баш исеннәр, сине каһәрләүчеләргә каһәр төшсен, сиңа изге теләк теләүчеләргә рәхмәт иңсен».

*(Тәурат, «Яшәеш», 27 сүрә, 1—29 аятьләр; Рабгузи, «Кассас-эл-әнбия», кыйссасы вәләдәтә Исхак пәйгамбәр, 95—97 битләр)*

Менә шулай утырта Якуп үзенең әтисен, менә шулай утырта Якуп үзенең туганын.

Ләкин, менә бәла!.. Якуп чыгып китүгә, урманнан Гаес кайтып җитә, ул да әтисенә кәбаб кыздырып кертә һәм шунда мошенник Якупның хәйләсе ачыла.

Тели белсәң — теләк, тели белмәсәң — имгәк дип, шундый чакта әйтәләрдер инде аны!.. Хәзер Исхак пәйгамбәр үзенә дулый, Гаес үзенә. Ләкин берни эшләр хәл юк, теләк теләнгән, алла кабул иткән, эш узган: хәзер Якуп бер кайда да хур булачак түгел, Гаес тотып алып каезлап ташлаганчы Якуп шәһәрдән чыгып шыла.

Тагын юри генә аллага ышанган булыйк. Һәм алланың үзе биргән акыл белән аның бу эшен хөкем итеп карыйк. Башкача була алмый: яки бу алланың чеп-чи ялганы, надан кешегә бар да үтәр дип язылган бер чиле-пешле әкият. Инде булган вакыйга икән, ул чакта алла бер ачык авыз, җебегәннең дә җебегәне. Югыйсә сукыр картның ялгышыннан файдаланып, энесенең бәхетен талап качкан аферист Якупны пәйгамбәр итәргә түгел, явыз энисе белән бергә җәһәннәмнең төбенә дөмектерергә тиеш иде ул.

Ә Исхак? Имеш, малаеның киеме икәнен исеннән белә, ә яңа суйган кәҗә тиресен җөнтәс кеше тәненнән аермый. Бу хәл шулай ук әкиятнең тузга язмаган әкият булуы турында сөйли.

Ары китик.

Исхак пәйгамбәр догасы аллага бик тиз барып җитә. Якуп туган-үскән иле Кәнганнан Ханан җиренә качып китеп барышлый Иерусалим шәһәреннән 30 чакрым җирдәге Луз шәһәре тирәсендә туктап, йокларга ятты. Йокысында Җәбраил фәрештәне күрде. Җәбраил хәзрәт әйтте: «Әй, Ягкуб, ушбу мөбарәк илләрне аллаһы тәгалә синең нәселеңә вәгъдә кылды. Синең бер заман балаларың булыр, нәселең үрчер, нәселең синнән соң ушбу җирләрдә тереклек кылыр», — диде. «Хәзрәте Якуп уянды, төшенең алла тарафыннан булуын фикерләп, бик сөенде. Баш астына салып яткан ташны манара кебек итеп бастырып куеп: «Я раббым, бу җир, аллаһы тәгаләгә гыйбадәт кыла торган изге җир булса иде», — дип дога кылды».

*(Тәурат, «Яшәеш», 28 сурә, 7—14 аятьләр, «Әнба-эл-әнбия», 73—74 битләр.)*

Башта ук әйтеп куйыйк. Алла бу теләкне кабул итә алмас, чөнки Луз дигән шәһәр иске китапларда булса да, дөньяда юк... Монысына тукталып тормастан, алдакчы Якуп артыннан сәяхәт кылыйк, алда аны хәйран тамаша хәлләр көтә.

Алдакчы гына түгел, бик мут та була Якуп мәрхүм. Ул әтисе белән Ибраһим бабасы кебек бердән-бер хатынын патшаларга тәкъдим итеп йөрми, бер атна эчендә туталы-сенелле ике кыз куенына керә. Ничек?— Шулай. Пәйгамбәрен — пәйгамбәр, ә өйләнергә акча кирәк, дөнья чаклы бирнә кирәк. Ә өйләнми булмас, 74 нче яше белән бара бит инде.

Якуп бирнә бәрабәренә җиде ел дәвамында кайнатасы булачак кешенең көтүен көтәргә килешә. Мөддәт тулуга — дөбердәтеп туй ясыйлар. Зофаф кичәсе... Иртәнчәк уянып китеп бикәченең йөзенә бакса, ни күзе белән күрсен, кызларның бүтәне, өлкәне, ямьсезе, кылые, Лия исемлесе! Ә ул кечесен килешкән иде. Ай кук нурлы йөзлесен, Рәхиль исемлесен! Ах, кайнатай, караңгыдан файдаланып, куеныма шушы кылыйны кертеп салган бит!.. Кияү йөгереп чыгып кайнатасына шикаять кыла. «Кайнатасы әйтте: безнең илдә, олысын калдырып, кечесен бирү юк. Бер атна тор да, кечесен дә бирербез, анысы өчен янә җиде ел көтү көтәрсең» диде.

Якуп риза була. Һәм атна дигәндә Рәхиль куенына керә, монысы өчен янә җиде ел ләмкә тарта.

Шулай итеп, кайнатай аферист Якупның үзен төп башына утырта... Ләкин ничек ул, шундый таш астыннан чыккан нәрсә, төннең-төн буена гыйшык-гашәрәт шәрабе эчкәндә җиде ел күз атып йөргән мәгъшукасыннан кылый кызны аермаган? Тагын: менә-менә пәйгамбәр булырга торган бу изге җанны алла ни дип ундүрт ел көтү көттереп газаплаган? Ниһаять, нигә шундук пәйгамбәр итмәгән?..

Ләкин шикләнергә ярамас, бу бит изге китап сүзләре. Күзләребезне йомып, анысы турында онытып ары китсәк хәерлерәк булыр.

Бөтен әмәлләр үз кулында булгач, ничек рәхәт!.. Әкиятне тагын да экәмәтлерәк итү өчен алла менә нәрсә эшли. «Аллаһы тәгалә (әй шук та инде үзе...) Якупның Лияне сөймәгәнен күреп, аның аналыгын томалый, Рәхильне дә бала тапмый торган итә».

*(Тәурат, «Яшәеш», 29 сүрә, 31 аять.)*

Ләкин биредә тагын хода рәхмәте: беренче **җиде көн** эчендә (ягъни аналыгы томаланганчы) **Лия абыстай дүрт бала анасы булып өлгерә.** Бигрәк уңган килен икәнсең, Лия абыстай!

Кызык бит. Әкиятне дәвам итсәк, укучы ачуланмас дип беләм.

«Рәхиль үзенең бала таба алмаганын белгәч, апасыннан көнләште һәм Якупка әйтте: бала бир миңа, югыйсә мин үләм». «Якупның Рәхильгә ачуы чыкты, һәм аңар әйтте: әллә мин алламы? Кайсыдырки синә аналык орлыгы бирмәгән.

Рәхиль әйтте: (бу урында Ибраһим пәйгамбәр җәмәгате Сара әбине хәтерлик — Г. Г.) менә минем асравым, йокла үзе белән... Миңа бала табып бирсен».

Баш өсте! Якуп ялт асрау кыз янына! И бер-бер артлы ике угыл! Аннан күрмәкче Лия дә үзенең асравы янына Якупны кертеп чыгара. Анысыннан янә ике ир бала. (Тагын Сара әбине хәтерлик—Г. Г.). Шуннан Лия дә, Рәхиль дә үзләре бала таба башлый. Җабраил фәрештә ышандырганча, диңгез читендәге ком бөртекләре санынча ук булмаса да, ходай тәгалә Якупка җәмгысе унике ир, бер кыз бала бирә.

Якуп кайнатасына ундүрт ел туры хезмәт итсә дә, ташы култык астында булган икән, явызның... Ул бу ташны мәһәр мөддәтен тутырып, этисе йортына кайтып китәр вакыт җиткәч бик әйбәтләп китереп чыгара. Кайнатасыннан аның быел яз чуар булып, тагын тимгел-тимгел булып туачак кәҗә һәм сарык бәтиләрен сорый.

Һи-и, андый могҗизаны көт әле син!.. Кайнатай: «Ярый, кияү, бирермен», — ди. Ә кияү менә нәрсә эшли: тирәк, миндаль һәм чинарботаклары җыеп кайта да, кайрыларын сыдырып ташлап, мал тагарагына сала: бары шул. Ходаның рәхмәте, тагарактан су эчкән терлекләрнең бәтиләре чуар яки тимгел-тимгел булып тумасынмы! Кыскасы, Якуп кайнатасына әйтеп тә тормый, аның уннан тугыз өлеш терлеген куып, хатын, бала-чагаларын ияртеп, этисе йортына кайтып китә.

Бу урында мин янә бер кат хәзрәтебезнең, чебен пычраткан күзгә бозып, яхшыны яман итеп күрсәтә, адәм балалары да шулай: алланы озаграк ядъ итми торса, калебе пычрана, яхшыны яман итеп күрә башлый, дигәнен хәтерләп, калебе пычранмаганнарга мөрәҗәгать итәм: әллә чыннан да шулаймы? Тумыштан алдакчы Якупның афералары безнең күзгә генә шулай яман булып күренәме? Шулай ук алланың Ибраһимны хатынының тәнен саттыру юлы белән баетуы, Лутның кызлары белән йоклау юлы белән аның нәселен үрчетүе асылда изге эш булып, безнең күзгә генә яман булып күренәме?.. Сез җавап әзерли торыгыз, без, Якуп пәйгамбәргә ияреп, алга китәбез.

Кайнатасын алдап кайтып килешли теге вакыт баш астына салып йоклаган таш янына җиткәч, Җабраил (ниһаять!) Якупка алладан вәхи китерә.

«Аллаһы тәгалә Якупны Кәнган халкын хак дингә өндәмәк өчен пәйгамбәр кылды. Һәм аңа «Исраил» дигән бер кавем бирде, шуның өчен аның нәселенә бәни Исраил диелер (Исраил угыллары димәктер).

*(«Әнба-эл-әнбия», 1 җөзьә, 78 аять.)*

«Кассас-эл-әнбия» исә үзенең 2 җөзьә, 122 битендә, үзенә-үзе каршы килеп, «Исраил» сүзе турында бөтенләй бүтән әкият сөйли. Имештер: «Якуп пәйгамбәр намаз укып торганда Шайтан ләгыйн моның лампасын өреп сүндерә, Якуп аны тотып алып әсир итә. Шуннан соң бу пәйгамбәрне **Исраил** дип йөри башлыйлар».

Чынлыкта Исраил — Израил — яһүд сүзе. Рус Москва ди, без Мәскәү дибез, без Казан дибез, рус Казань ди. Бередә аерма шундый гына. Ә Исраилнең мәгънәсе — әсир дигән сүз түгел, **алла белән көрәште** дигән мәгънәгә туры килә һәм бу исемне алла Якуп пәйгамбәргә үзе бирә. Монысы үзенә бер чиктән тыш кызык вакыйга. Монысы Коръәнгә кермәгән. Ләкин күп кенә дини китаплар, шул җөмләдән, «Кассас-эл-әнбия», бу әкиятне бераз шомартып, заман шартларына яраклаштыра төшеп, үзенең битләренә урнаштырган:

«Якуп бик баһадир көчле пәйгамбәр иде. Иблисне әсир кылгач, күңеленә: «миннән көчле адәм бар микән» дию гаҗәп (уй)төште. Хак собханә вә тәгалә (безнеңчә, просто алла — Г. Г.) бер фәрештәне адәм сурәтенә кертеп, угрый кыяфәтле кылып, Якуп янына җибәрде. Якуп сахрада куйларын, дөяләрен сакларга барып йоклаган иде. Уянып китсә, фәрештәне угрый дип белеп тотып алды. Таң атканча низаглаштылар. Ахырда фәрештә Якупны җиргә күтәреп бәрде. Якупның бот төбе авыртулы булып калды».

Әмма ләкин әкиятнең асылы алай түгел. Хәзер без аны борынгы Тәураттан гына эзләп таба алабыз. Әлеге дә баягы, Якуп кайнатасыннан качып китеп барышлый була бу хәл:

«Якуп ялгыз калды. Кемдер аның белән таң атканчы көрәшеп чыкты. **Җиңә алмагач, Якупның ботын бәреп имгәтте.** Һәм әйтте Якупка:

— Җибәр мине, чөнки таң атты, — диде.

Якуп әйтте:

— Мине пәйгамбәр итми торып, җибәрмим.

Тегесе әйтте:

— Синең исемең ничек?

Бу әйтте:

— Якуп.

— Бүгеннән башлап синен исемең Якуп түгел, Исраил булыр, чөнки мин — алла, син алла белән көрәштең, кешеләрне дә җиңәрсең».

*(Тәурат, «Яшәеш, 32 сүрә, 24—31 аятьләр.)*

Билгеле, бер боты имгәнгән булуга карамастан, алланы җинеп чыккан Якупның уллары да яман гайрәтле булалар һәм без моны түбәндәге вакыйгадан беләбез.

Пәйгамбәр кызына кем генә кызыкмас!.. Кәнганнан ун көнлек җирдәге Туркум иленең патшасы Якуп пәйгамбәрнең кызына яучы җибәрде. Якуп, үзе дүрт кяфиргә өйләнгән булса да, бу патша кяфер булганлыктан, аңа кызын бирмәде. Патша гаскәр җибәрде. Якупның ун улы гаскәрнең бөтенесен кырып салды. Тагын бер патша Якупның кызына гашыйк булды. Якуп аңа да бирмәде. Патша 100.000 гаскәр белән килде. Якупның ун егете боларны да кырып салды.

*(«Кассас-эл-әнбия», 1 җөзьә, 118 бит.)*

Янә бер патшадан яучы килде. Якуп пәйгамбәр патша алдына изге дигәндә дә изге шарт куйды: кызыма өйләнәсең икән, башта үзең сөннәткә утырасың, аннан бөтен халкыңны утыртып чыгасың...

Гыйшык ниләр эшләтми!.. Патша шундук җиргә утырып, ят җиренең башын кисеп ала. Вәзирләре, илендәге бөтен халкы сөннәткә утыртыла. Ләкин сөннәткә утыру — мөселман булу түгел бит әле... Хәер, күрәсең, пәйгамбәргә ул кадәресе кирәк тә булмаган... Тегеләр сөннәттән соң сырхап ятудан файдаланып, пәйгамбәрнең ун пәһлеваны, кылычларын үткенләп барып, бөтенесен кырып чыгалар.

*(Тәурат, «Кассас-эл-әнбия», «Әнба-эл-әнбия», «Тарихеләнбия».)*

Ун пәһлеван шулхәтле кешене, аннан алда йөз мең гаскәрне, аннан алда тагын патша гаскәрен!.. Безнеңчә, бу алланың Мюнхаузен башына да килми торган борчагы. Инде дин әһелләре моны булган хәл диләр икән, алла егетләргә илаһи көч биргән, диләр икән, димәк, алла аларны бу эшкә үзе юллаган булып чыга. шулай түгелме?! Ул чакта әйтегез, бу юлбасарлыкның кай җире илаһи, нәрсәсе изге һәм без аның кай җиреннән гыйбрәт алырга тиешбез?

## ҮЗЕ ПӘЙГАМБӘР, Ә ҮЗЕ КЯФЕР ПАТША МИНИСТРЫ. ГЫЙШЫК КҮЗНЕ ТОМАЛЫЙ. КАЙДА КОЙМАК — ШУНДА КУНАК.

Менә инде без сезнең белән, әкренләп килә торгач, алланың иң сөекле пәйгамбәрләреннән берсе булган Йосыф галәйһиссәләм җәнапләренә дә килеп җиттек.

Йосыф — Якуп пәйгамбәрнең төпчек улы. Ул әлеге ун пәһлеван арасында булмады, кечкенә иде. Инде буйга җитте, укучыга күрсәтергә бик вакыт.

Әйткәнемчә, ул алланың сөекле пәйгамбәре. Тәурат аңар егерме бит урын биргән, 300 битле «Кассас-эл--әнбия»нең 60 бите, «Әнба-эл-әнбия»нең өчтән бере Йосыфның бер үзе турында. Якуп хәтле Якуп турында нибары берничә сүз белән чикләнгән Коръәннең 11 бите Йосыфка багышланган. Һәм ул битләр шундый аять белән башланып китә.

«Без хәзер сиңа Коръәндәге иң яхшы хикәяне сөйләп бирәбез».

*(Коръән, «Йосыф» сүрәсе, 3 аять.)*

Без дә аның тормыш юлын бизәп торган изге вакыйгаларның кыскача әчтәлеген сезнең игътибарга әйбәтрәк итеп җиткерүне үзебезгә изге бурыч итеп куйдык. Йөзләрегезне кыйбла тарафына юнәлтегез, әгузе-бисмиллагызны әйтегез, мин башлыйм.

Якупның ун пәһлеваны, алда бәян кылынганча, дин юлында үзләрен аямыйча, чирләп яткан кяферләрне суеп чыгу кебек изге эшләр эшләп йөрсәләр дә, Йосыфны дошман күрәләр. Төп сәбәп — көнчелек: Йосыф һәм аның абыйсы Бәниәмин яшь анадан. Әниләре үлеп, ятим калганлыктан, әтиләре боларны аерата бер ярату белән ярата. Их, менә Йосыфны үтерсәләр яки берәр башка илгә олактырсалар, әтиләренең бөтен мәхәббәте ун пәһлеванга күчәр иде дә бит... Ничек котылырга соң үзеннән?.. Пәһлеваннар шул турыда баш ватып йөргәндә Йосыф унбер йолдызның вә һәм Кояш белән Айның үзенә сәҗдә кылганнарын күреп уяна. Әтисе бу төшне, пәйгамбәр булырсың, агаларың да сиңа буйсыныр, дип юрый. Чүп өстенә чүмәлә, төш турында агаларына килеп ишетелә.

— Башына җитәргә, әнчекнең!..

— Ничек?

Пәһлеваннар, Яһүдә исемлесенең тәкъдиме буенча, Йосыфны, әтиләреннән сорап, сахрага алып чыгалар һәм бер коега илтеп ташлыйлар. Ә әтиләренә: «Без куыш уйнап йөргән арада Йосыфны киемнәребез янында калдырып торган идек, килсәк, бүре ашаган», — дип кайтып әй-

тәләр. **Һәм сукыр картка (!) Йосыфның ялган канга буялган күлмәген күрсәтәләр.**

Әтиләре ышанмый.

Шуннан ун пәһлеван, сахрага чыгып, бер бүре аулыйлар да, авызына кан сөртеп, этиләренә алып кайтып күрсәтәләр:

— Йосыфны менә шушы бүре ашады...

«Якуп (**сукыр Якуп — Г. Г.**) **бүренең авызындагы канны күрде ирсә,** я рабби, бу җанварга тел бир, дип мөнаҗәт кылды. Хак тәгалә аның догасын кабул итте. Якуп: «Әй бүре, Йосыфны ни өчен ашадың, нигә мине газиз баламнан мәхрүм кылдың?» — диде. Бүре телгә килеп: «Я рәсүлулла, пәйгамбәрләр ите барча җанварга хәрам, Йосыфны минем күргәнем дә юк, бу залимнар, мине куып тотып, авызыма кан сөрттеләр, мин үзем Мысырдан килдем, өч көн бер тәгам ашаганым юк, бер улым бар иде, югалды, шуны эзләп йөрүем... Син, ичмасам, миңа шул баламны табарга ярдәм ит», — диде.

— Ә анысын без хәзер...

«Якуп, бүрене ашатып, күңелен хуш итте, баласын эзләп тапсын дип, дога кыйлды, бүре үзенең баласын эзләп тапты».

*(«Кассас-эл-әнбия», хәзрәте Ягъкуп галәйһиссәләм кыйссасы.)*

Өч көн дигәндә әлеге кое янына кәрван килеп туктый. Дөяләрен эчерергә коедан су алганда Йосыф кәрванчыларның чиләгенә тотынып чыга. «Менә бәхет, өйгә алып кайткач, кол итеп сатарбыз үзен!..» диләр кәрванчылар.

Шул чак Якупның башкисәрләре килеп җитә. Башларына үзгә уй төшкән:

— Тай моннан, безнең кол бит ул!.. Теләсәгез, сатып алыгыз.

Кәрван хуҗасы Йосыфны юк кына бәягә сатып ала да, өенә алып кайтып, хатыны кулына тапшыра.

«Кадер-хөрмәт күрсәт үзенә, бәлкем, ул кайчан да бер безнең өчен файдалы кеше булыр яки үзебезгә угыл итәрбез».

— Син кем итсәң дә итәрсең, ә мин менә кем итим әле аны...

Бу сүздән укучының сизгерләге үзе үк сизгән булса кирәк, хәзер Йосыф белән хуҗа хатынының мәхәббәт хикәясе башланып китәргә тиеш. Әйе. Һәм бу хикәя шактый мавыктыргыч. Шунлыктан ул бер ислам дөньясына гына түгел, бөтен Африка, Азия халыклары арасына таралган, аны бөтен Европа диярлек белә. Борын заманның мәшһүр шагыйрьләре, Йосыфка атап шигырьләр иҗат иткән, драматик әсәрләр тудырган. Гасырыбызның беренче чирегендә татар сәхнәсендә мәйдан toткан «Йосыф—Зөләйха» драмасы шулай ук Йосыф белән аның мәгъшукасына багышланган. Бу ике яшь йөрәкнең мәхәббәт тарихлары җырларга кергән:

> «Кавышырсыз, иркәм, кавышырсыз, көннәрдән бер көннәрдә,
> Җиде елдан соң кавышкан Йосыф пәйгамбәрләр дә».

> «Казан каласын су алган, байның маллары калган,
> Сөеп алу — сөеп бару пәйгамбәрләрдән калган...» —

болар бар да Йосыф пәйгамбәр белән аның мәгъшукасы турында.

Коръәнгә кайтыйк.

Хуҗа хатыны (ул Зөләйха исемле була) дөньясында бер матур. Яшь, дәртле... Барыннан бигрәк шунысы куанычлы: никахланган булса да, кыз кыз әле. Чөнки иренең ирлеге бөтенләй юк. Печелгән ир... Ә Йосыфның матурлыгын безнең тел белән генә әйтеп бетерә торган түгел. Бу хакта «Кассас-эл-әнбия» менә нәрсә ди: «Алла матурлыкны йөз өлеш яратты. Шуның 99 өлешен анабыз Хавага бирде. Бер өлешен янә йөз өлеш кылып (?), 99 өлешен Йосыфка бирде. Калганын барча халыкка таратты».

Сүз уңаенда әйтеп китәргә кирәк, Йосыф кына түгел, пәйгамбәрләрнең күбесе әйтеп бетергесез матур булалар. Мәсәлән, Муса. Кояшның аең бер якта торсын!.. «...Нурыгызга күз чагыла, яшел пәрдә корыгыз», дип җырлыйлармы? — аның да нуры әнә шундый була. Һәм ул, кешеләрнең күзләре чагылмасын дип, йөзенә пәрдә корып йөри. Бер заман бер чибәр хатын (шушы Йосыф Зөләйхасы кебек мутрак нәмәрсә булган булса кирәк), йөзеңне бер күрсәм, үлсәм дә үкенмәс идем», дип моның артыннан ияреп килә. Муса, ниһаять, йөзен ачып җибәрә, хатынның ике күзе чагыла. Ах, чагылып кына калган булсачы!.. мәңгегә сукыраеп кала күзләре...

Бәлкем, бер очтан, алланың үз нуры турында да беләсегез килер? Анысын тел белән генә әйтеп аңлата торган түгел. Менә үзегез шуннан чамаларсыз. Бер заман алла әлеге Муса пәйгамбәрне бер тауга чакырып китерә. Анда алар кырык көн сөйләшеп яталар. Хикмәти хода, Муса алланың тавышын ишетә, үзен күрми. Муса күрәсе килгәнен әйтә. Ләкин:

— Бу мөмкин түгел, — ди алла.

— Ник?

— Түзәлмәссең дип куркам.

Муса, пәйгамбәр булса да, адәми зат бит, кызыксына:

— Түзәрмен, таңрем, күрсәт.

— Мә, күр инде алайса...

Ярый әле, алла үзенең мөбарәк нурын Мусаның йөзенә түгел, тауның бер читенә генә төшерә. Мусаның шунда борылып каравы була, ә биһуш булып егыла. Ә тау? Тау беләсезме нишли? Чәлпәрәмә килеп, типтигез җир булып кала...

Менә нинди нурлы алланың нуры!..

Йосыфка кайтыйк.

«...Хуҗа хатынында Йосыфка дәрт кузгалды. Ул ишекне бикләп алды да әйтте: «Кил яныма». Йосыф әйтте: «Алла сакласын! Хуҗам миңа шундый рәхәт тормыш бирде...»

Ләкин теге вакыт фәрештә хәтле фәрештәләрне аздырган хатын-кыздан нәрсә көтмәк кирәк: «Бу хатында Йосыфка дәрт кузгалган кебек, Йосыфта да хатынга дәрт кузгалды. Әгәр безнең кисәтүебезне күрмәгән булса... Без аны бу эшәке эштән, усал нияттән туктаттык, чөнки ул безнең гөнаһсыз хезмәтчебез иде».

Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, алла Йосыфны туктата, ә хатынны — юк. Хатын Йосыфны көчли башлый. Йосыф ычкынып китеп, ишеккә ташлана, хатын, куып житеп, шундый эләктереп ала, бичара пәйгамбәрнең киеме аерылып чыга. Ишектән куышып килеп чыксалар — хуҗа! Билгеле инде, матур кызда хәйлә күп. Кыз, күзен дә йоммыйча, хәйләгә керешеп, иренә: «Ул мине мәсхәрә итмәк булды, син аны төрмәгә ябарга яки коточкыч җәза бирергә тиешсең», — ди.

*(Коръән «Йосыф» сурәсе, 25 аять.)*

Ләкин, маташтырасың хатын, «киеменең арты ертылган түгелме соң?.. Беләбез без сезне!.. Йосыфтан гафу үтен, чөнки син гөнаһ эшләдең».

...Гайбәт бөтен шәһәргә тарала:

«Зөләйха үзләренең яшь хезмәтчеләренә кызыгып йөри икән, хезмәтчегә бер күрүдә гашыйк булган икән, бөтенләй юлдан язган нәмәрсә икән»... һ. б., һ. б...

Шулай дисезме!..

Зөләйха чаяның да чаясы була. «Шундук зур сый хәзерләп, гайбәтче хатыннарны кунакка чакырды. Һәрберсенең кулына пычак тоттырды. Шуннан Йосыфка керергә кушты. Хатыннар Йосыфны күреп, тәмам

шаштылар. Кулларын кистеләр һәм әйттеләр: «Валлаһи бу кеше түгел, бу искитмәле фәрештә».

«Ә-ә, хәзер шулаймыни!.. Ха-ха-ха!.. Нигә гаеп итмисез, итегез!.. Сез Йосыфны бер күргә кулларыгызны кистегез, ә мин аны иртә-кич күреп, нихәл сабыр кылыйм».

«Шулай икән шул. Без дә синең шәрик булыйк, безнең белән дә йокласын ул... Әй Йосыф, син Зөләйха белән дә, безнең белән дә йокла, безне морадыбызга ирештер...»

«Булмас!..»

Инде хуҗа хатыны тәмам ярсый:

«Булыр! Мин сине үземнең теләгемә мәҗбүр итәчәкмен. Әгәр мин кушканны эшләмәсәң, зинданга кереп, иң бәхетсезләрдән булачаксың...»

Башы төрмәгә китсә китә, изге Йосыф Зөләйха белән, шулай ук аның кунак хатыннары белән йоклаудан баш тарта.

Мәхәббәт корбаны Йосыф зинданда утыра торсын, мин сезгә пәйгамбәрләр заманында булган үзе кечкенә, үзе төш кенә бер вакыйга сөйләп алыйм.

Көннәрдән бер көнне аллаһ тәгалә Әюб исемле пәйгамбәргә һичбер төрле пәйгамбәр дингә кертә алмаган бер үҗәт патшаны дингә өндәп кайтырга куша.

Ул заманда, ни хикмәттер, пәйгамбәрләрнең генә түгел, патшаларның да хатыннары кысыр булалар һәм, тагын ни хикмәттер, тәмам кабер якасына баскач кына бала тели башлыйлар. Ибраһим пәйгамбәр һәм аның Сарасын гына хәтерләгез. Әюб пәйгамбәр дингә өндәргә тиеш патшаның хатыны белән дә шул ук хәл: ул да мәңге кысыр. Бу патша Әюб алдына шундый шарт куя:

— Аллаң бала бирсә, иман китерәм, югыйсә башымны катырып йөрмә, иман китермим.

Әюбнең тез чүгеп, чынлап торып бер дога кылуы була, патша, ходаның рәхмәте, төшендә күктән энҗе төшкәнне күреп уяна.

— Бала, — дип уйлап ала патша. — Ир микән, кыз микән?

Сарайдагы төш юраучыларның зирәклегенә ничек исең китмәсен!.. **«Энҗе тишекле идеме, тишексезме?»** дип сорыйлар.

— **Тишекле, тишекле!** — ди патша.

— Алайса, кыз... — диләр төш юраучылар.

Һәм нәкъ шулай булып чыга. Кысыр карчык патшага менә дигән кыз бала табып бирә.

*(«Кассас-эл-әнбия», икенче җөзьә, 179—181 битләр.)*

Бу риваятьне шуның өчен сөйләвем: Йосыф пәйгамбәргә дә алла шундый четерекле төшләрне юрау сәләтен бирә. Төрмәдә утырганда ул тоткыннарга төш юрый. Юравы гелән раска килеп тора. Ниһаять, моның бу даны патшага килеп ишетелә.

— «Йә, минем дә бер төшемне юрап кара әле. Бүген төшемдә җиде симез сыер күрдем, аннары җиде арык сыер. Юра шуны», — ди патша.

— Җиде ел иген уңар, җиде ел ачлык булыр.

Бөтен илдән җыелган төш юраучылар әйтеп бирә алмаган төшне юрады да бирде бит Йосыф пәйгамбәр!.. Патша моны шундук үзенең баш вәзире итеп куя. Һәм оттырмый... Йосыфның төше раска килеп, җиде ел иген уңа, ә Йосыф беләсезме нишли: дәшми-тынмый гына икмәк җыя, бөтен җирләргә иген чәчтерә, халыктан да сатып ала, ә ачлык еллар килеп җиткәч, җиде бәягә үзләренә сатып ята!..

Моннан соң да бу бәндәне изге зат димәсәң, пәйгамбәр димәсәң, алла орыр... Моңарчы шикләнеп йөргән булсаң, тизрәк тәүбәңә кил, укучым. Хәзер аның тагын да изгерәк бер маҗарасын сөйлим мин сезгә.

Шул рәвешчә, халыкның бөтен байлыгы, алтын-көмеше, мал-туары патша хәзинәсенә ага.

«Ике-өч ел эчендә халыкта акча тәмам бетте. Хайваннарын, йорт җиһазларын китереп, ашлык алып китә башладылар, балаларын кол итеп саттылар».

Көннәрдән бер көнне Иосыфның әлеге ун абыйсы да иген алырга килә. Иосыфны танымыйлар, ә Иосыф аларны таный. Унысына ун йөк ашлык төяп, кайтарып җибәрә.

— Икенче килгәндә этиегез янында калган энегезне дә (Бәниәминне дә — Г. Г.) алып килегез, югыйсә үзегезгә бүтән ашлык сатмам.

Алып киләләр. Ә Иосыф Бәниәминне үз янында алып калу өчен, аны караклыкта гаепләп, төрмәгә яптыра. Егетләр этиләренә кайтып әйтәләр. «Кайгы-хәсрәттән Якуп пәйгамбәрнең күзләре (сукыр күзләре! — Г. Г.) агарып чыга».

«Барыгыз Иосыфымны эзләп табыгыз, Бәниәминне дә табыгыз», — ди Якуп пәйгамбәр.

Ун пәһлеван, шундук дөяләргә атланып, Мысыр тарафына китә.

Бу юлы Иосыф аларга үзен таныта.

Агалары моның алдына килеп тез чүгәләр:

— Гафу ит, энекәш!..

Әһә, теге вакыт төшемдә унбер йолдыз, ай, кояшларның миңа сәҗдә кылганын күргәч, әти бу төшемне, «алланың сайланган кешеләреннән буласың, ата-бабаларыңа яуган бәхет сиңа да явар, абыйларың сиңа буйсыныр», — дигәч, көлгән идегезме!..

— Мин түгел, менә болар...

— Гафу ит, энекәш!..

— Әйдә, итәм... Икенче килгәндә этине алып килегез. Бөтен гаиләгез белән күчеп килегез.

Киләләр.

Ул арада, нур өстенә нур — Зөләйханың печелгән ире күптән дөнья куйган һәм ялкынлы ике яшь йөрәк кавышкан була...

Ләкин болай йөгереп кенә үтсәк, пәйгамбәрне үпкәләтүең, хәтта бәддогасына дучар булуың бик мөмкин. Шуннан куркып, мин «Кассас-эл-әнбия»нең икенче җөзьә, 178 битеннән берничә юл күчереп алырга булдым. Бик гыйбрәтле юллар. Уйлыйм ки, сез дә укып мәмнүн булырсыз.

«...Җабраил, күктән төшеп, никах хөтбәсе укыганнан соң, Иосыф пәйгамбәр Зөләйха янына аулакка керде. Ул, хәзрәте Зөләйханың бу замангача кызлыгы бозылмауга исе китеп, сорау бирде:

— Ничек саклadың, Зөләйха?

Зөләйха оялып кына җавап кайтарды:

— Ирем миңа күңел куяр иде, шундук кычкырып янымнан качар иде һәм әйтер иде: «Кайчан сиңа күңелем төшсә, янында ике арыслан пәйда була да, сиңа якынлык кылыр хәлем калмый» ди торган иде...»

Иосыф Зөләйха янына аулакка кергәч, бәхеткә каршы, арысланнар пәйда булмый, барысы да мәгълүм тәртип буенча бара... Этиләре килгәндә йортта инде ике балалары да йөгереп йөри. Иосыф хикәясе әнә шулай күңелле генә тәмам була.

*(Коръән, «Иосыф сурәсе».)*

Коръәннең һәр сүзеннән гыйбрәт эзләүче дин кешесе, әлбәттә, Иосыф кыйссасыннан да үзенчә мәгънә чыгарыр. Бакчы, дияр ул, шайтан вәсвәсәсенә бирелмәде, ягъни хатыннарның бозык теләкләрен үтәмәде, ачлык елларда халыкны ач үлемнән саклап калды.

Әйе, бозык теләкләрен үтәмәде. Ә шунда, икесе дә кызып җиткән минутта, арага алла үзе кереп туктатмаган булса?..

— Алла? Син бигрәк инде...

Ышанмыйсыңмы? Ул чакта менә Коръән. «Йосыф» сүрәсенең 24 аятен үзең укып кара:

**«Без аны бу явыз нияттән, әшәке гамәлдән туктатып калдык. Чөнки** ул безнең гөнаһсыз хезмәтчебез иде».

Инде ышандыңмы, укучым? Биредә бик урынлы бер сорау туа. Нигә ул, Йосыфны туктаткан алла бер очтан хатыннарны да туктатмый, өерләре белән шәһәр буенча Йосыф артыннан йөгертеп йөртә? Нигә?

Чынбарлыкта исә мондый хәл, әлбәттә, булмый. Бу да шул Лутка кунакка килгән ике фәрештәне бөтен бер шәһәр ирләренең көчләргә йөрүе кебек үк нәҗеси бер әкият, Коръәннең бөтен хатын-кызга уптым илаһи яла ябуы. Монысы да әкият. Чынбарлыкта печелгән иргә Зөләйха кебек дөньясында бер чибәр түгел, бөтен гариплекне үзенә җыйган кыз да бармый. Инде берәрсе расчет белән барырга тели икән, печелгән ир, (әгәр ул шыр тиле түгел икән) үзе алмый. Бу бит, ашату-эчертү, өстенбашын бөтен итү миннән, калган ягын, егетләр, үзегез карагыз, дигән сүз булыр иде.

Инде Йосыфның ачлык елда халык өчен ничек тырышып йөрүе турында уйлыйк әле. Ачлык буласын төшендә күреп белгәч, халыкка кисәтү ясау урынына шыпырт кына халыктан арзан бәя белән иген җыяҗыя да, аннары җиде ел буена үзләренә үк җиде бәягә сатып ята! Халыкны ыштансыз калдырып талый. Бер табак он бәрабәренә газиз балаларын үзенә кол итә. Хәтта әнә үзенең атасын да дәһшәтле ачлык булачагы турында кисәтми. Инде шул бәдбәхет җанны да изге дибез икән, пәйгамбәр дибез икән, 1921 елгы авыл кулакларын бүген үк каберләреннән кубарып, гамәл дәфтәрләренә карап та тормастан, җәннәтнең түренә кертеп утырту дөрес булыр.

Бер очтан этисенә дә сәлам биреп үтәргә кирәктер.

Фәрештәләр аша һәрдәм алланың сәламен ишетеп, турыдан-туры Җәбраил фәрештә белән эш итеп яткан пәйгамбәрнең, алланың җирдәге тулы хокуклы һәм чиктән тыш вәкаләтле илчесенең, илгә ачлык килгәч, алладан туклык сорап, көн-төн намазлык өстендә аунуйсы урында, үзенең мөселманнарын ташлап, шыпырт кына улы янына, тук илгә, кяферләр иленә, качуын ничек аңларга?! Әйтегез, мулла абзыйлар, бу сорау сезгә. Әйтә алмыйсыз? Алмассыз шул. Культурасы иң түбән дәрәҗәдәге кыргый кабилә башлыклары да мондый хаинлекне эшләми. Хәер, бу Якуп пәйгамбәр бит әле!.. Әнисенең карыныннан абыйсының үкчәләренә ябышып чыккан, абыйсын алдап, өлкәнлекне үзенә алган, этисен һәм алланы кәкре каенга терәп пәйгамбәр булган, ниһаять, кайнатасын кычкыртып талап качкан пәйгамбәр бит әле бу!.. Мондый бәндәдән бүтәнне көтеп тә булмый, әлбәттә...

Бүре турында да берничә сүз.

Бүтән пәйгамбәрләрнең этләре, дөяләре иман китереп, халыкны хак дингә өндәп йөргәнгә ышанабыз икән, Якуп бүресенең сөйләшә белгәненә ышанмый ярамас... Ләкин хәзергә эш анда түгел. Бүрене ашатып чыгару, аңар яхшы теләкләр теләү белән, янәсе, Якуп изгелек эшли... Безнеңчә — киресенчә. Алланың бүреләргә пәйгамбәрләрне ашамаска дигән боерыгы бар икән, билгеле, бу вакыйгадан соң әлеге бүре пәйгамбәрнең үзенә түгел, мал-туарына да тимәс, әмма ләкин, үзенең баласын табу шатлыгыннан бүтән берәүнең иң симез сарыгын ботарлап ташлар. Иртәгә дә, берсекөнгә дә, гомер-гомергә халыкка зыян-зәүрәт кылып яшәр! Я, әйтегез, мулла абзыйлар, шул да булдымы пәйгамбәрнең изге гамәле?!

Яшь пәйгамбәрнең Зөләйхага гыйшкы, ниһаять, аңа өйләнүе «Йосыф» сүрәсендә үзәк урынны тота. Сүрә халыкка шул ягы белән мәшһүр дә. Һәм беренче карашта, аның финалы күңелле дә кебек. Бәгъзе берәүләрнең, театрдагы кебек, аллага шөкер, ниһаять, кавыштылар, дип ир-

кен сулап куюлары мөмкин. Ләкин, күзне ачыбрак карасак, бу никахның, гыйшык ялкыны белән Йосыф пәйгамбәр үзе дә сизми калган ифрат күнелсез бер ягы ачылыр. Ул да булса, **Зөләйханың мәҗүси диндәге кыз булуы, һәм аның мәңге үзенең шул мәҗүси динендә калуы.**

Сүз унае килгәндә әйтеп үтү урынлы булыр. Кяфирәгә өйләнүдән Коръән «кара халык»ны гына тыйган, пәйгамбәрләр үзләре бу мәсьәләгә бармак аша караган. Нух белән Лутны хәтерләгез. Ә Якуп? Дүрткә өйләнә, дүртесе дә чыкылдаган кяфирә. Һәм дүртесе дә Нух, Лут һ. б. ларныкы кебек ничәшәр йөз ел бергә гомер итүгә карамастан, ирләре өндәгән дингә төкереп тә бирмиләр. Җитмәсә берсе (нәкъ Йосыф әнисе — Рәхиль абыстай), инде пәйгамбәр белән егерме ел гомер иткән абыстай булуына карамастан, аның белән әтисе йортыннан качкан чакта әтисенең тәреләрен чәлеп китә!.. Гомумән, Якуп пәйгамбәрнең шәригате (авыр туфрагы җиңел булсын) керәле дә чыгалы: бердәнбер кызын мәҗүси патшага бирергә әзер, әмма тик сөннәтле булсын!..

Йосыф сүрәсенең тагын шушы ягы кызыклы. Әйтерсең, алла аны юри тузга язмаган итәргә тырышкан: шундый озын сүрә эчендә чынбарлыкка туры килә торган ник бер вакыйга булсын! Энеләрен кол итеп сатуны бәрән сату урынына да күрмәгән, сөннәткә утырганнан соң түшәктә авырып яткан бөтен бер ил кешеләрен өйдән-өйгә кереп суеп йөрүне тавык сую урынына да күрмәгән башкисәрләрнең ата-ана мәхәббәтенә хаҗәтләре булуга кем ышансын ди! Ә әтисенең итәгеннән төшмәгән бер малайны бер төш юраганына карап (әле раска килерме— юкмы) патшаның баш вәзире итеп куюы? Ә Йосыфның баш вәзир булып алгач, егерме ел буена сөекле әтисен кайтып күрмәве? Шулай ук әтисенең дә сөекле улы ике ятып бер төшенә кермәве? Йосыфның агаларын танып, агаларының моны танымаулары? Йосыфны күреп гашыйк булган хатыннарның берсе калмый кул кисүләре?!

Ниһаять, фикер йөртүдән курыкмаган һәркемнең башында шундый сорау туарга тиештер: Йосыф пәйгамбәрне әтисеннән аерып, әллә кайларга олактыру, коега салып газаплау, кол итү, зинданда яткыру, хатыннардан мәсхәрә иттерү — аллага нигә кирәк булды икән?

Дөрес, Коръәндә моңа җавап бар. Ләкин, никадәр тыйнаклык сакларга тырышсаң да, аны елмаймыйча укырга мөмкин түгел.

«Шул рәвешчә, — ди алла, — без Йосыфны бу илгә илтеп урнаштырдык...»

Димәк, алла үзенең пәйгамбәрен **бу илгә илтеп урнаштыру өчен** бүтән чара тапмаган?..

Ә беләсезме (монысы тагын да экәмәтрәк) алла аны «бу илгә» ни өчен илтеп урнаштырган? — таңга хәтле уйлап ятсагыз да әйтә алмыйсыз, аны бер алла үзе генә белә. Менә нәрсә ди алла бу хакта:

«Һәм бу безгә аны төш юрарга өйрәтү өчен кирәк булды».

*(Коръән, «Йосыф» сүрәсе, 21 аять.)*

Моны да хикмәт димәсәң!.. Иң сөекле, иң атаклы пәйгамбәрнең төп эше — төш юрау! Җиде симез сыер белән җиде арык сыер төшен юрау! Һәм шуңар өстәмә төстә **мәҗүси патша вәзире** буларак (монысы үзе генә дә ни тора!..) тирә-якны, шул исәптән мөселманнарны кычкыртып талап яту!!!

Бәлкем, мин сүрәнең изге җирләрен: Йосыфның дин юлында җанфәрман тырышып йөргән урыннарын усал нияте белән төшереп калдырганмын? Бәлкем, мин сөйләгәннәр Йосыфның алла юлындагы изге эшләре янында кояштагы тап кебек кенәдер? Юк. Йосыф үз гомерендә төрмәдәге ике токтынны дингә өнди, аларны да дингә кертә алмый. Йосыф пәйгамбәрнең дин юлындагы бөтен эше әнә шуңардан гыйбарәт. Ә бит, әйтергә кирәк, «Кассас-эл-әнбия» бу сүрәне — «Йосыф» сүрәсен, безгә гыйбрәтле итеп кенә түгел, шифалы сүрә дип тәкъдим итә.

«Кем дә кем фәкыйрьлеккә төшсә, зинданга дучар булса, васвасәгә грифтар булса, нәфесе яман касед кылса (ягъни берәр әшәкелек эшләргә ниятләсә — Г. Г.), хатыннар мәкеренә тарса, тагын әллә нәрсәләргә дучар булса, шушы сүрәне укысын. Шифасы булачак».

Көләрсең дә, еларсың да.

8

## МУСА ПӘЙГАМБӘР МАҖАРАЛАРЫ. КЫРЫК ТӨРЛЕ МОГҖИЗА. МУСА ФИРГАВЕННЕ КӘКРЕ КАЕНГА ТЕРИ.

Хөрмәтле укучылар! Динле һәм динсез иптәшләр! Әгәр сезнең читтә яшәүче ихтирамга лаеклы берәр туганыгыз үзе үлгән чакта: «Үзебезнең илгә кайтып йөрмәгез, биредә генә калыгыз, берничә ел рәхәт яшәрсез, аннан соң сезне җәбер вә золым кыла башларлар, туган илебезгә кайтмакчы булырсыз, ләкин рөхсәт итмәсләр, авыр хезмәтләрдә йөртеп файдаланырлар, ә 512 елдан соң бер бәндә килеп чыгып, нәселебезне бәла вә җәфалардан коткарса кирәк», — дисә, сез бу туганыгыз турында нәрсә уйлар идегез икән? — Акылдан язган дияр идегез, шулай түгелме? Ә бит моны, әлеге дә баягы, алланың иң сөекле пәйгамбәрләреннән берсе Йосыф пәйгамбәр үзенең туганнарына әйтә.

*(«Әнба-эл-әнбия», 124 бит.)*

Хикмәти хода, Йосыфның туганнары бу киңәшне кире какмый гына түгел, бик кулай күреп, мөселман башлары белән шул мәҗүси Мысыр илендә яшәп калалар.

Күрәсең, биредә дин ислам әһеле шунысына сөенергә тиештер. Имеш, Йосыф пәйгамбәр сүзләре раска килә, Йосыфның туганнары (без аларны Коръәндә әйткәнчә бәни Исраил кавеме дип атыйк), нәкъ Йосыф әйткәнчә, Мысыр патшасының авыр газапларына дучар ителә... Ниһаять, Йосыф үлгә 512 ел дигәндә, алла, «аның кавемен ягъни бәни Исраилне коткару нияте белән, Муса атлы кешене Мысырга пәйгамбәр итеп җибәрә... 512 елдан, ягъни берничә буын җәбер-золым күреп тереклек иткәннән соң... Анда да әле коткарачакмы ул Муса Йосыф өммәтен? Бу Йосыфның үз туганнарына берәр этлек эшләве түгелме?.. Аның сына керешүдән әлек алланың Мусаны ничек-ничек пәйгамбәр иткәнен белеп китик. Әлбәттә, алла бу бөек эшне биредә без бәян кылган кебек, ансат кына башкарып чыкса да хәленнән килер иде. Ләкин алай хикмәте булмый ич, аллача булмый. Мысыр иленә пәйгамбәр киләсен, аның Исраил кавемен, ягъни Йосыфның туганнарын Фиргавен золымыннан коткарачагын алла Муса туганчы ук дин дошманы Фиргавеннең төшенә кертеп куйган була. Моның өчен Фиргавен аллага рәхмәт әйткәндерме, юктырмы, — мәгълүм түгел, тик шунысы билгеле: Фиргавен куркуга төшә. Нишләргә?.. Ул бәни Исраилнең ир балаларын үтертеп бетерә, һәрбер яңа туганын үтерә барырга әмер бирә.

*(Коръән, «Сыер», сүрәсе, 46 аять.)*

Һичбер котылыр әмәл юк. Фиргавен тарафыннан куелган кендек әбиләре Исраил кавеменнән булган йөкле хатыннарны исәпкә алып куйган, тулгак тота башлауларына хәзер килеп җитәләр, ир бала булса, йолкып алалар да шундук буып ташлыйлар.

Менә Муса туа. Аны да шул ук язмыш көтә. Ләкин алла бу хакта Мусаның әнисенә белдереп куйган икән. Әни кеше Мусаны бер сандыкка салып диңгезгә агыза. Алла ташламаса, бүре ашамас. — Мусаны коткаралар. Беләсезме кем коткара? — Көчәнмәгез, бөтенегез бергә җыелып уйласагыз да белә алмыйсыз. Фиргавен хатыны, — менә кем

коткара Мусаны! Һәм ул да кайчандыр Йосыфны коедан табып алып кайткан кәрванчы евнух сүзләрен кабатлый:

«...Бәлкем, ул безнең өчен файдалы кеше булып чыгар, яки үзебезгә угыл итәрбез», — ди.

*(Коръән, «Хикәя» сурәсе, 8 аять.)*

Фиргавен үзе дә, тилерденме әллә син, чүпрәк баш, диясе урында, ходайның рәхмәте, ярый, шулай итәрбез, ди. Һәм үзенең башына житәчәк Мусаны аның үз әнисенә имезергә илтеп бирә. Бирә, ә күкрәк сөтеннән аерылгач, имеш, кире алырга оныта...

Мусаның пәйгамбәр булганчы башыннан үткәннәре әнә шуңардан гыйбарәт... Ә пәйгамбәрлек эшчәнлеген Муса изге дигәндә дә изге эш белән башлап җибәрә. Бер мөселман белән сугышып торган кяферне күрә дә, йөгереп килеп, бәреп үтерә. Икенче көн тагын бер кяферне якасыннан алып селекмәкче. Ләкин монысы җебеп төшми: «Син безгә кеше үтерер өчен килдеңмени, изге пәйгамбәрлегең шушымени синең?!» — ди.

Муса шәһәрдән чыгып шыла. Аны үзе юкта хөкем итәләр. Шунысы кызык: гүя ул үзе түгел, үтергән өчен хөкем итүчеләр гаепле, шәһәрдән чыккач, аллага хитап итеп, болай ди:

— «И ходаем, мине бу миһербан-шәфкатьсез халыктан коткара күр».

*(Коръән, «Хикәя» сурәсе, 20 аять.)*

Кавемең калды бит, бәни Исраил калды. Шуларны Фиргавен золымыннан коткару өчен пәйгамбәр итте түгелме соң сине алла? — Әйе. Ләкин Муса шәһәргә кире борылып кайтырга ашыкмый. Ул башта бүтән бер илгә барып, бер мәҗүси шаехнең кызына өйләнә. Шартлар һәм сәбәпләр нәкъ Якуп пәйгамбәр әкиятендәгечә. Көтүләрен су буена алып килгән ике кызга малларын сугарышырга ярдәм итә. Кызлар, моны, әйдә, эти үзеңә бүләк бирер дип, өйләренә алып кайталар. Әтиләре ике кызының берсен шундук моңар хәләл җефетлеккә тәкъдим итә. Мәһәре шундый:

«Сигез ел көтү көтәрсең (Якупның җиде ел иде — Г. Г.) ун ел көтсәң дә сүз әйтмәм».

*(Коръән, «Хикәя» сурәсе, 27 аять.)*

Хәзер мин сезгә Коръәннән озын гына бер өзек китерәм, сез аның мәгънәсенә генә түгел, әдәби камиллегенә дә игътибар итсәгез икән.

«Мөддәт тулгач, (көтү көтү срогы тулгач — Г. Г.) Муса хатын вә бала-чагаларын ияртеп, юлга чыкты. (Нинди юлга, кая барырга? — Г. Г.). Тау ягында ул ниндидер ут күреп, үзенең гаиләсенә әйтте: «Шушында торып торыгыз, мин тау ягында ут күрдем; бәлкем, мин сезгә бу ут турында хәбәр алып килермен яки сезгә **җылыну өчен утлы кисәү башы алып килермен»**. Кайчан ул аның янына килде (кем, нәрсә янына? — Г. Г.) шул чак бәхетле үзәннең уң ягыннан, куаклык эченнән:

«Әй, Муса, чынлыкта бу — мин, алла, шушы дөньяның алласы», — дигән тавыш ишетте.

*(Коръән, «Хикәя» сурәсе, 29—30 аятьләр.)*

Тагын шундый сәер хәл: бер үк вакыйга турында ике җирдә ике төрле итеп әйтү. Әлеге вакыйга турында «Таһә» сурәсенең 9—12 аятьләрендә без менә нәрсә укыйбыз.

«Менә Муса ут күрде. Һәм ул гаиләсенә әйтте: «Шушында торып торыгыз. Мин ут күрдем, бәлкем, мин аннан кисәү башы алып килермен яки **шул ут ярдәмендә туры юл табармын»**. Ут янына килеп житкәч, «Муса!» дигән тавыш ишетте. «Мин синең аллаң. **Сандалыңны сал, чөнки син изге җирдә»**.

Хәер, укучы мондый бутауларга күнекте кебек инде. Хәзер без Мусага: «Мин алла» дип дәшүче белән кызыксыныйк.

Нәрсә, берәрсе, мәзәк итеп, Мусадан көләр өчен куаклыкта кулына утлы кисәү тотып утырамы әллә? Юк, бу, Коръән ышандыруынча, чын алла булып чыга. Исәнлек-саулык сорашып тормастан, алла сүзгә керешә. Муса да, гүя үзенең балачак дустын гына очраткан, — бер дә исе китми:

«Исәнме, алла!»

«Исән... кулыңдагы таягыңны җиргә ташла!»

Муса ташлый.

«Ә кайчан таягының елан кебек бөтерелгәнен күрде, артына да борылып карамыйча йөгерә башлады».

Алла аны кычкырып туктата:

«Муса! Кил монда, курыкма. Син куркынычсыз җирдә».

*(Коръән, «Хикәя» сүрәсе, 31 аять.)*

Шуннан алла Мусаны тагын бер могҗиза ясарга өйрәтә. Һәм әнә шунда гына Фиргавеннең дин дошманы икәнен әйтеп, бәни Исраилне аның золымыннан йолып алырга әмер бирә. Муса, үзенең сакаулыгын сылтау итеп, ярдәмгә энесе Һарунны да алып барасы килгәнен әйтә. Югыйсә Фиргавен халкына рәтләп аңлата алмам да, пәйгамбәр икәнемә ышанмаслар, ди. Чикләнмәгән кодрәт иясенә артык кеше өстерәтеп йөрткәнче, Мусаның сакаулыгын төзәтеп, ораторлык сәләте бирсә дә хәленнән килер иде кана. Юк, алла Һарунны кече пәйгамбәр итеп, һәр икесенә вәгазь-нәсихәт кылып, җиңеп чыгачакларын вәгъдә итеп, озатып кала.

Әлбәттә, бу урында укучының динсезе, бу Мусага андый энекәш кайдан килде әле, әнисе бер Мусаны гына тапты, бер Мусаны гына сандыкка салып агызды түгелме соң? дип төпчеңә башлар. Динле кеше: ул кадәресе — алла хөкеме дияр. Без исә хәзергә андый «вак-төякләр»гә тукталып тормастан, Муса белән Фиргавен очрашкач булган искитмәле хәлләрне сөйләп бирергә ашыгабыз.

Муса Фиргавенгә үзенең пәйгамбәр икәнен, алланың чиктән тыш тулы хокуклы илчесе икәнен, бәни Исраилне азат итәргә килгәнен әйтә. Ләкин, менә ходаның хикмәте, Фиргавен үзен алла дип йөри икән, үзе генә түгел, мәмләкәтендәге барлык кешеләр аны шулай ук алла дип белеп, аңар табынып яшиләр икән. Мусаның сүзләреннән бөтенесе шаркылдап көләләр. Фиргавен дә көлә һәм үзенең халкына мөрәҗәгать итеп болай ди:

«Бөтен Мысыр, бөтен елгалар минем хөкемемдә түгелме соң? Сүзен дә рәтләп әйтә белмәүче бу җирәнеч адәмгә караганда мин әйбәтрәк түгелме соң? Ичмасам, кулларында алтын беләзек булса икән яки үзе белән фәрештәләр ияртеп алып килгән булса икән...»

*(Коръән, «Бизәкләр» сүрәсе, 50—53 аятьләр.)*

Ах, шулаймы? Менә хәзер Муса үзенең кем икәнен күрсәтсен әле!..

«— Яхшылык белән бәни Исраилне азат ит! Дөресен әйтәм, мин алланың илчесе! — ди Муса.

— Исбат итеп кара соң...

Шул чак Муса үзенең пәйгамбәрлек таягын җиргә ташлады. Таяк чын еланга әверелде».

Ләкин Фиргавен түрәләренең моңа әллә ни исләре китми. Без андыйны гына күргән, дигән кебек:

«— Оста сихерче икәнсең, — диделәр. — Инде менә син безнекен карап тор!..»

Фиргавен, бөтен илгә чаптарлар җибәреп, җитмеш мең сихерче җыя.

Арадан кырыгын сайлап алып, үзләренең һөнәрләрен күрсәтергә куша. Чү! Аларның да таяклары еланга әверелде ич!

«...Болар да «бөек сихерләр» күрсәттеләр. Карап торган кешеләрнең котлары очты...»

«Шул чак алла Мусага тагын: «Таягыңны тагын җиргә ташла», — ди. Ташлаган гына иде, «Мусаның таягы еланга әверелеп, тегеләрнең еланнарын берәм-берәм кабып йотты...» Бу хәлне күреп, Фиргавен сихерчеләре җиргә йөз түбән капландылар... Инде без Муса белән Һарун алласына ышанабыз, — диделәр».

*(Коръән, «Киртәләр» сүрәсе, 113—119 аятьләр.)*

Әлбәттә, үзен алла дип йөрүче Фиргавен бу хәлгә күтәрелеп бәрелә. Мөселманга чыккан сихерчеләрне, шундук тотып алып, аяк-кулларын өзгәләп ташлый. Шундый сихер иясе Муса, теләсә, әлбәттә, патшаны бу явыз эштән туктатып калган булыр иде, ләкин безнең Муса бу хәлгә бер сүз әйтми. Янәсе, анысы аның эше түгел, алла аңар бәни Исраилне генә коткарырга кушты бит!..

«— Азат ит бәни Исраилне, — ди ул Фиргавенгә. — Югыйсә алла үзеңә әллә нинди бәла-казалар җибәрер...»

«— Алла да алла ди бу Муса, күреп төшим әле шуның алласын... Миңа биек манара ясап бирегез...»

Ясыйлар. Шундый биек итеп ясыйлар, — Фиргавен анда ике тәүлек менә.

«— Муса ялганлаган, анда миннән гайри алла юк», — ди ул манарадан төшкәч.

— Ах, әле син һаман ышанмаска итәсең! — Ачуыгысы хәттин ашкан Муса, алладан бик каты яңгыр сорап, дога кыла. Дога кабул була. Яңгыр Фиргавен кяферләрен һәлак итә башлый.

Хәзер Фиргавенгә: бар, үзеңнең бәни Исраилең белән олага бир, диясе генә иде кана. Юк, кире беткән Фиргавен Исраил халкын азат итми. Янәсе, ул пәйгамбәрне алдамакчы:

— Үзеңнең аллаңа әйтеп, яңгырны туктатттырсаң, иман китерәбез, бәни Исраилне дә азат итәбез.

Муса, аллага әйтеп, яңгырны туктаттыра. Ә кяферләр иман китерми.

Муса, янә дога кылып, алланың Фиргавен өстенә чикерткә яудыруын сорый. Күктән чикерткә явып, игеннәрне кыра башлый.

Тагын:

«— Чикерткәләрне туктаттырсаң, ышанабыз, бәни Исраилне дә азат итәбез...»

Туктаттыра. Тагын ышанмыйлар.

Муса, бу юлы аллага да ялынып тормый, әлеге таягы белән күлгә бер китереп сугуы була, гөберле бакалар, дәррәү сикерешеп чыгып, кяферләргә ябырылалар, өйләренә сикерешеп кереп, казандагы ашларына төшәләр, авызларына кереп бетәләр.

Янә:

«— Туктаттыр, иман китерәбез, бәни Исраилне дә азат итәбез...»

Муса туктаттыра. Тегеләр бу юлы да иман китермиләр.

Шул рәвешчә, Муса кырыкмаса-кырык могҗиза күрсәтә. Күктән кандала яудырып газаплый, әчәр суларын канга әверелдерә.

*(Коръән, «Киртәләр» сүрәсе, 130—131 аятьләр.)*

Әлбәттә, бу афәтләрнең шаукымы бәни Исраилгә дә тия. Бәни Исраил дә гаҗиз:

«— Элек начар иде, син килгәч, тагын да күбрәк газап чигә башладык, пәйгамбәр».

«— Тагын бераз түзегез».

Бу «бераз» егерме ел дәвам итә. Ниһаять, Муса хәйләгә керешә. «Иртәгә гает, — ди ул Фиргавенгә, — бәни Исраилне сахрага алып чыгып гыйбадәт кылырга рөхсәт ит әле миңа».

Ахмак Фиргавен, янәсе, шуның хәйлә икәненә төшенми:

— Алып чык соң, — ди ул.

Бәни Исраил хатыннары да хәйлә кора. Алар, гыйбадәт вакытында бизәнергә диган булып, кяферләрнең алтын-көмешләрен сорап торалар.

Кяферләр дә Фиргавен кебек үк ахмакның да ахмагы булып чыга, арада ник берсе шикләнсен:

— Мәгез соң...

Һәм бәни Исраилне ай күрде — кояш алды! Фиргавен шиккә төшеп, үзенең гаскәре белән артларыннан куа чыкканда бәни Исраил инде тамталлар арасында була!.. Гомуми тантана!..

9

## ЯНӘ ИБЛИС МӘЗӘГЕ. ҖӘННӘТ БИЯСЕ. АЛДАН КЫЧКЫРГАН КҮКЕНЕҢ БАШЫ ЯРЫЛА

Ә бераз баргач, диңгез. Инде бәни Исраил хафага төшә. Ә Муса тыныч.

— Менә ничек итәбез аны...

Таягы белән диңгезгә китереп сугуы була, су көрәлгән кар кебек як-якка өелеп, уртадан киң юл ачыла. Бәни Исраил шул юлга өерелеп килеп керә.

Ләкин Фиргавен ләгыйндә дә хәйлә бар икән. Бу могҗизаның алла кодрәте белән эшләнгәнен белсә дә, гаскәренә хитап итеп:

«Минем бөек икәнемне күрдегезме инде, әнә дәрья миңа юл бирде» дигән була. Үзе тизрәк тәртәсен кире борырга чамалый.

Алланың бу хәлгә бик тә ачуы килә:

— Ах, мәлгуньнең дә мәлгуне икән!.. Бар әле, Җабраил, арт сабагын укытып кайт әле шул мөртәтнең!

— Ләббәйке, кадир алла!

Җабраил фәрештә Фиргавеннең арт сабагын җиңел кына да укыта алган булыр иде. Ләкин аның бу йомышны аеруча мәзәк итеп, хәйләле итеп үтисе килә. Ә хәйлә анарда бер капчык, алланың үзеннән өйрәнгән.

— Әллә инде алланы хәйләкәр дә димәкче буласыңмы, язучы?

Мин түгел, бу турыда алла үзе әйтә. Ул үзенең бу сыйфаты белән очраган бер җирдә мактанмый калмый. Менә берничә мисал:

«...Кешеләр хәйлә корып маташты. Ләкин берсе дә безнең хәтле булдыра алмады».

«Кяферләр безнең гыйбрәтләргә каршы хәйлә корып маташа, әйт: алла хәйлә мәсьәләсендә алардан остарак диген».

«Алар хәйлә корды. Алла да хәйлә корды. Ә алла хәйләкәрләр арасында иң әйбәт хәйләкәр, иң оста хәйләкәр».

*(Коръән, «Юныс» сүрәсе, 22 аять, «Гыймран» сүрәсе, 47 аять һ. б. сүрә, һ. б. аятьләр.)*

Җабраилгә килик.

Шулай итеп, Җабраил фәрештә хәйләгә керешә.

Ул «бер байтал атка атланып, Фиргавен алдыннан үтте». (Бу җирен фани дөнья уйларын башыгыздан чыгарып торып, ихлас күңелдән бөтен нечкәлекләрен күз алдына китереп укырга киңәш бирер идем.)

«Ә Фиргавен атланган ат айгыр иде». (Оһо, бия! Җәннәт биясе! Нинди сылу!.. Мондый һәркөн очрап тормый!..) «Фиргавен айгыры, Фиргавен тыеп бакса да, тыңламады, дәрте тәмам ташып, дәртле кешнәп,

җәннәт биясе артыннан җан-фәрман диңгезгә атылып килеп керде. Билгеле инде, аның артыннан Фиргавеннең бөтен гаскәре ыргылды. Ләкин гашыйк айгыр җәннәт биясе белән кавышырга да өлгермәде,— юлны су басты. Аллага мең шөкерләр булсын, шулай итеп, бәни Исраил азат, үл сәламәт котылды, Фиргавен гаскәре һәлак булды».

*(Коръән, «Киртәләр», 126—132 аять; «Кассас-әл-әнбия», хәзрәте Муса галәйһиссәләм кыйссасы.)*

Бәхәсне шул Фиргавеннән башлыйк әле. Дини китаплар исәбе буенча Муса туганга хәзер 4004 ел. Фиргавен үзенең гаскәре белән диңгезгә батып үлгәндә Муса 60 яшьләрдә булган булып чыга. Димәк, бу вакыйгага хәзер 3944 ел, ә бу елларда инде Мысыр — гаять көчле, бөтен дөньяга мәшһүр мәмләкәт. Чал тарихка Фиргавеннәр династиясен башлап җибәргән гаскәр башлыгына хәтле мәгълүм, бу мәмләкәтнең беренче патшаларына хәтле мәгълүм: Мина, Тутмос III, Әмин Хатип һ. б. лар[1].

Мысырның бу патшалары Хәбәшстан, Гарәбстан, Ханан, Месопотамия, Вавилон, Әрмән илләрен, җәмгысе 115 эре һәм вак мәмләкәтләрне дер селкетеп торганнар. Янәсе, әнә шундый мәшһүр патшаларның берсе бөтен гаскәре белән диңгезгә батып һәлак була, ә шуны күрше илләр, хәтта үз халкы белми дә кала, шул гадәттән тыш вакыйга тарихка язылмый кала!.. Муса вакыйгасының әкият икәнен исбат итү өчен шушы мәгълүмат үзе генә дә җитеп беткән түгелме!

Инде Муса таягы турында берничә сүз. Коръән, Тәурат һ. б. дини китаплар моны, әлбәттә, мәзәк өчен түгел, кяферләрне иман китерү өчен, алланың кодрәтен күрсәтү, пәйгамбәрләргә биргән зирәклекне исбат итү өчен сөйли. Ләкин, каш ясыйм дип, күз чыгара. Ярый, пәйгамбәр таягы еланга әверелсен дә. Ә кырык сихерченеке?! Әгәр пәйгамбәр белән алланыкын могҗиза дибез икән, Фиргавен сихерчеләренеке ни өчен могҗиза түгел? Ә Фиргавен эшләткән манара? — Очына ике тәүлек менә торган манара? Сәгатенә өч километр гына менгән сүрәттә дә 114 километр биеклектәге манара? Ни өчен анысы могҗиза түгел?! Алла һәм аның пәйгамбәрләре эшләгәнне гади кешеләр, хәтта «Фиргавен» кяферләре дә эшли ала дигән мәгънә килеп чыга түгелме соң монардан? Ничек кенә боргалама, шулай килеп чыга. Алланыкы дөрес, кяферләрнеке ялган дияр идең, һәр икесе бер үк Коръәндә, бер үк Тәуратта акка кара белән язылган, хисапсыз күп дини китапларда язылган. Димәк, яки һәр икесе (һәм алланыкы, һәм Фиргавен сихерчеләренеке) дөрес, һәр икесе могҗиза, яки һәр икесе ялган.

Коръәннең Муса турындагы сүрәләре могҗизаларга аеруча бай. Исраил кавеме диңгез аша чыккач, 40 ел буена сахрада адашып йөри. Моң-зар, эчәргә юк, ашарга юк... Зар аллага барып җитә. Алланың боерыгы белән Муса таягы янә эшкә керешә. Кырык ел буена 600 мең кешене шул таяк ашатып-эчертеп тора. Мусаның җиргә китереп оруы була, дәррәү үнике чишмә бәреп чыга. Тагын бер ора, күктән манна дигән ярма ява, шикәрле күмәч, хәлвә, тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр ява һавадан. Ул да түгел, бытбылдыклар очып килеп төшә. Үзләре оча, үзләре пешкән!.. Алла үз кешең булгач, ничек рәхәт!..

Ләкин әкиятнең зур әкәмәте ул түгел, зур әкәмәт менә кайда: бу сый-хөрмәт берничә елдан Мусаның үзенә, хәтта Җабраилга каршы баш күтәрәчәк бәни Исраилгә бит!!! * Ә менә шуннан соң, бөтен кешегә димим, саф мөселманнарга, мөселман булып туган, мөселман булып үл-

---

[1] Коръән һ. б. дин китаплары бу исемнәрне бөтенләй телгә алмыйлар, бөтенсезен Фиргавен диләр һәм шуның белән бу мәсьәләдә дә үзләренең наданлыкларын фаш итеп, көлкегә калалар: Фиргавен — исем түгел, мысыр патшаларының титулы. Без патшаны патша дигән кебек, рус царь дигән кебек, борынгы Мысыр халкы үзләренең патшаларын фиргавен дип йөргән.

* (Алдарак күрерсез, алар Муса динен ташлыйлар.)

гән, дин юлында мең тапкыр үләргә хәзер торган мөселманнарга бу сый-хөрмәт эләкми, аларга Муса таягы хезмәт итми. Саф мөселман иле булган гарәб илләрендә: Иранда, Иракта, Әфганстанда һ. б. бик күп илләрдә әледән-әле саранча афәте, корылык. Нигә шул мөртәт Исраил кавеменә биргәннең меңнән берен генә дә бирми икән соң алла аларга? Нигә соң аларны бер йотым суга тилмертеп үтерә икән? 1921—1922 елларны хәтерләгез. Татарстан, Башкортстан, Пермь, Оренбург, Саратов, Сембер, Самар, Нижний һ. б. бик күп өлкәләрдә ничә миллион мөселман ачыкты. Гомергә намазлык өстендә утырган, кулыннан тәсбих, теленнән «ләилаһа» төшмәгән эбиләр, чал бабайлар, имчәк балалары бер кабым икмәккә тилмереп үлде! Унары, йөзәре, меңәре берьюлы. Муса таягы кайда булды ул чакта!? Юк ул. Алласы булмаган кебек, аның таягы да юк. Ә бу уңай белән мулла абзыйлар сезгә янә бер хитап. Инде әле һаман да таяк бар дисез икән, атаклы дәһри Ярославский тәкъдим иткәнчә, шул бәни Исраил гизгән ком сахрасына дөньяның барлык мөфтиләре, ишаннары, әүлияләры белән җыйналып чыгып карагыз. Бер үк вакытта сезнең белән иң дә дәһри, иң дә дин дошманы булган биш-алты гына эшче чыксын. Бер ел, ун ел, кырык ел, үлгәнче кулыгызны күккә күтәреп дога кылып ятырсыз, билләһи дип әйтәм, сезгә җир бер йотым су бирәчәк түгел, ә безнең шул биш-алты дәһри эшче берничә көн эчендә артезиан коесы казып, сезнең бөтенегезне эчерерлек, тәһарәт алдырырлык, госел коендырырлык, бөтен нәсел-нәсәбегезгә җитәрлек су чыгарып бирер. Инде, безнең дәһриләрне, алар күз буа, дип шикләнсәгез, бу тәҗрибәне үзегез генә эшләп карагыз. Ягъни, дога урынына җиң сызганып, шул ук сахрада берәр атна көрәкләр белән эш итегез. Ант итеп әйтәм, нәтиҗә шул ук булачак... Ходай кушып, шуннан эшләп ашарга да өйрәнеп китмәссезме... Ә эшләп ашау, ай, ничек тәмле!.. Тагын корсакны үстерми, йокы татлы була. Чынлап әйтәм, әйдәгез, бер шундый тәҗрибә ясап карыйк...

10

## КИРЕ БЕТКӘН БӘНИ ИСРАИЛ. «СИНЕҢ АЛЛАҢНАН ҮЗЕБЕЗНЕҢ БОЗАУ ӘЙБӘТРӘК». «БЕЗГӘ САРЫМСАК БУЛСЫН».

Муса могҗизалары, гомумән, могҗизалар дини китапларга кайдан килеп кергән соң? Аларның ике төп чыганагы бар. Беренчесе — борынгы фантастик әкиятләр. Элекке кеше коточкыч авыр шартларда терсклек иткән бит. Мәккәдән Шамга дөя унар көн бара, җилкәнле көймә Мысырдан Һиндстан ярларына дүрт атна йөзә. Кеше моның белән килешә алмый. Ничек тизрәк бара торган итәргә?.. Кеше хыялы канатлы ат, оча торган палас әкиятләре иҗат итә... Йөз меңнәрчә кеше бөек Кытай стенасын 40 ел ясый бит. Мысыр пирамидаларын, мәһабәт гыйбадәтханәләрне салганда дистә еллар буе тир түгә. Ничек тизрәк салырга, ничек ансатрак салырга? Кеше бер төн эчендә гүзәл сарайлар салып бирүче, шәһәрләрне бер җирдән икенче җиргә күчереп куючы гыйфритләр турында әкиятләр иҗат итә. Еллар үтә, йөз, мең еллар... Яңа буын халыклар бу әкиятләрне инде әкият итеп түгел, кайдадыр, кайчандыр булган хәл итеп кабул итә башлый. Ә диннәр барлыкка килгәч, дип әһелләре аларны илаһилаштырып, геройларын пәйгамбәрләргә, фәрештәләргә әвереләдереп, үз мәнфәгатьләре өчен файдаланалар. Шул рәвешле бу әкиятләр, яһүд, христиан, ислам диннәре барлыкка килү белән Тәурат, Инҗил, Забурга, алар аша Коръәнгә килеп керәләр.

Могҗизаларның икенче чыганагы — табигать үзе. Бер ут кабызу өчен җан тирләре чыкканчы агачны агачка ышкып утырырга тиеш булган кешенең иң камил коралы таш пычак булган. Кеше өчен иң куәшы

кием эшкәртелмәгән хайван тиресе булган. Борынгы кеше өчен яшен яшьнәү дә, күк күкрәү белән җил-яңгыр да, хәтта салават күпере генә дә могҗиза. Кичә кичтән хәтфәдәй яшел болын иде, бүген иртән көтүен шул болынга дип куып алып килсә, анда күл! Кичә яшел, тын, матур бер тау иде, бүген иртән торып чыкса, башыннан яман зур куәт белән ут бәркелә, ут белән бергә эреле-ваклы ташлар атылып чыгып, тирә-якка сибелә. Кичә диңгезнең бу урынына ау салып киткән иде, бүген иртән торып барса, биек тау пәйда булган...

Бүген җиденче класс баласы нилектән, ничек икәнен җиңел аңлатып бирә торган мондый табигый күренешләр элекке кеше өчен могҗизаның да могҗизасы булып күренгән. Ә диннәр барлыкка килгәч, дин әһелләре аларны да үз мәнфәгатьләре өчен файдаланганнар, алла тарафыннан эшләнә торган могҗиза дип аңлатканнар, һәм болары да бара-тора фантастик хикәяләр кебек үк Тәуратка, Инҗилгә, алар аша Коръәнгә килеп кергәннәр.

Бер кызык мисал. Газ белән нефть безнең заман кешеләрен инде әз генә дә гаҗәпләндерми бит. Ә бу нәрсәләр бәркелеп торган Апшерон ярыматавын исламга кадәрге кеше могҗизалар иле, изге җир дип белгән. Иран, Ирак, Һинд илләреннән кәрван-кәрван төялеп килеп, корбан чалып китә булганнар.

Коръән һ. б. дини китаплардагы могҗизаларның шундый сабын куыгы икәнлекләрен бер хәл бик төпле рәвештә исбат итә. Күз алдыгызга китерегез. Кыргый кеше. Үзеннән көчле ни нәрсә күрсә, шуңар табынырга әзер. Ул Кояшка, Айга, йолдызларга, утка, суга, җилгә табына. Балчыктан, таштан сын ясап куя да шуны алла ди. Шуннан, пәйгамбәрләр килеп чыгып, күктә алла барлыгын исбат итү теләге белән, имештер, әнә нинди могҗизалар эшләп күрсәтәләр, ә шуларга ышанмый. Имештер, алла, ачуланып, кешеләрне батырып үтерә, күктән таш яудырып һәлак итә, монысына да ышанмый!.. Мисалның иң ачыгы — бәни Исраил. Муса аларга ни тикле гыйбрәтле могҗизалар күрсәтте. Пәйгамбәр чырае күрми яшәгән 512 елда да үзенең Иосыф пәйгамбәр өйрәтеп калдырган диненә кер тидермичә саклаган бу халыкның моннан соң бөтенләй әүлия булып китүе, мәгарәдән чыкмый гыйбадәт кылып ятуы, әлбәттә, шагыйрәнә табигый булыр иде. Ә алар, беләсез нишли?— Муса пәйгамбәр килгәч, киресенчә, көфер дигәндә дә көфер юлга басалар! ...Бу хәл шуннан башлана: Муса таягы ярдәмендә диңгез аша чыгып Фиргавеннән котылганнан соң болар сыннарга табынучы мәҗүси халыкка юлыгалар. Муса бу халыкны кырып ташларга әмер бирә. Моңар каршы бәни Исраил менә нәрсә ди:

«Әй, Муса, тәңрең белән сез икеңез сугышыгыз, без монда утырып торабыз».

*(Коръән, «Ризык» сурәсе, 27 аять, «Кассас-эл-әнбия», 255 бит.)*

Коръәннең «Сыер» сурәсе, 77 аяте ышандырып маташуга карaганда, имештер, бәни Исраил кайчандыр аллага: «Без синнән гайри һичкемгә буйсынмыйбыз» дип, кулларыннан язу да биргән булалар». Хәзер Муса шул хакта исләренә төшерә, бәни Исраилне куркытып та бага, ә бәни Исраил: «Сугышмыйбыз, бетте-китте».

Анысы-анысы әле, безгә дә әнә шул мәҗүсиләрнеке төсле сыннар табып бир дип, Мусаның теңкәсенә тиеп бетәләр. Муса шурли кала... Ярдәмгә алла үзе төшеп җитә. Анысына да исләре китми. Соңра алла Мусаны Тур тавына чакырып ала. Ә Муса алла янында кырык көн торып, аңардан, ниһаять, Тәурат китабын алып төшсә, ни күзе белән күрсен, Исраил кавеме Фиргавен хатыннарыннан алдап алып качкан алтын-көмештән бозау ясап куймасыннармы! Рәхәтләнеп шуңар табынып ятмасыннармы! Нинди генә бозау әле, чын бозау кебек мөгрәп тора!..

Муса, үзен-үзе белешмәстән, Тәуратны күтәреп бәрә. (Пәйгамбәр тикле пәйгамбәр!.. Тәурат тикле Тәуратны!! Алланың кырык көн буена иҗат итеп яткан изге китабын!!! Чүлмәк такталарга язылган. Такта саен йөз сүрә. Сүрә саен мең аять. Тышы кызыл якуттан...)

Күтәреп бәрә дә:

«Ә син, минем энинең улы, нәрсә карап тордың? — дип, Һарунның мөбарәк сакалыннан тотып йолкый».

(Җәяләр эчендә генә булса да әйтеп китәргә кирәктер, Һарунның алла юлында бөтен хезмәте дә шул бозау сынын ясаганны карап тору һәм дә Мусадан сакалын йолкыту була.)

Ачуы бераз басылгач, Муса Тәурат битләрен җирдән җыеп ала, бөтен илаһи сәләтен җигеп, бәни Исраилне дингә өнди. Аларга Тәуратны укып күрсәтә.

— Әем, бик мәшәкатьле икән... Үзебезнең бозау яхшырак...

Күктән алла:

«Әй, Исраил балалары! Минем сезгә булган шәфкать-мәрхәмәтемне хәтерләгез, минем сезне бөтен дөньяда иң өстен халык иткәнемне хәтерләгез, — дип тә бага. — Фиргавен золымыннан азат иттем, бер зыян-зәуратсыз диңгез аша кичердем, ә сез, мин Мусага тауда күрсәтмәләр биреп яткан арада, бозауга гыйбадәт кылгансыз, оятыгыз кайда», — дип тә бага. Исраил кавеме төкереп тә бирми.

Нишләргә? Күктән Җабраил фәрештә төшеп җитә. Кулында тау. Әйе, тау. Эльбрус тикле генә булмаска тиеш. Ник дисәң, бәни Исраилнең бөтенесенең өстенә каплап куярга җитмәле. (Ә бәни Исраил бу чакта, алла вәгъдә иткәнчә, һавадагы йолдызлар санынча ук булмаса да, шактый ишәйгән — 600 мең баш.)

— Иман китерегез, бозавыгызны җимереп ташлагыз, югыйсә хәзер шушы тауны өстегезгә төшерәм, — ди Җабраил.

— Төшермәгәен...

Җабраил тауны бәни Исраилнең баш түбәләренә кадәр төшерә. Тезләнеп утыралар. Тагын түбәнрәк төшерә, — сузылып яталар. Тәмам сыта башлагач кына беркадәресе иман китерә, ә Җабраил өсләреннән тауны алып күккә очып менеп киткәч, алары да: — мә тәһарәтеңне, китер кәвешемне!..

*(Коръән, «Киртәләр» сүрәсе, 101—172 аятьләр, «Ибраһим» сүрәсе, 5—8 аятьләр, «Бәни Исраил» сүрәсе, 2—4, 103—106 аятьләр, «Шагыйрьләр» сүрәсе, 9—67, аятьләр, «Кырмыскалар» сүрәсе, 7—14 аятьләр, «Хикәя» сүрәсе, 1—42 аятьләр, «Таһа» сүрәсе, 8—101 аятьләр, «Юныс» сүрәсе, 76—93 аятьләр, «Һуд» сүрәсе, 99—101 аятьләр, «Кыйсас-эл-әнбия», 194—237 битләр.)*

Әйтәсем килгәне: әгәр чыннан да нәкъ шулай бөтенесе Коръән, Тәурат һ. б. дини китаплардагыча булса, алла чыннан да булып, Коръәндәгечә бер-бер артлы шундый могҗизалар күрсәтеп, җиргә фәрештәләр төшереп торса, бер кыргый Исраил кавеме димим, бүгенге кеше дә, иң югары белемле кеше дә, уйга калыр иде, мин үзем дә, иң беренче булып, башыма чалма чалып, ак ыштан киеп, ялан аякка кәвеш эләктереп, камыш таякка таянып, мәчеткә элдертер идем.

Нух туфаны кебек үк Муса әкияте дә оригиналь түгел. Мусаны диңгезгә агызып җибәрү юлы белән Фиргавеннән коткарып калу кебек әкиятләр дә Тәурат, Коръән һ. б. дини китапларга кадәр көнчыгыш илләрдә әллә кайчан телдән телгә күчеп сөйләнеп йөргән. Мәсәлән, Персия шаһы Кир турындагы әкият нәкъ шундый. Ә Тәуратка кадәр 2.500 ел элек яшәгән Ассирия патшасы Сороган шундый ук бер әкиятне башыннан үткән хәл рәвешендә үз кулы белән язып калдырган. Аерма тик шунда: Сороган әнисе үзенең патша булачак малаен, сандыкка тү-

гел, сумалаланган кәрзингә салып агыза. Аны да шулай ук судан табып алып, тәрбиягә үз әнисенә бирәләр.

Муса белән Фиргавен әкиятенең кайбер урыннары «Мең дә бер кичә» әкиятләрен, Дефоның «Лилипутлар илен» хәтерләтә. Аерма тик шунда: бу әкиятләр тапкырлык, батырлык тәрбиялиләр, әдәп-әхлак, эстетика тәрбиялиләр. Муса әкиятендә, гомумән Коръәннең бөтен әкиятләрендә, моның нәкъ киресе. Аннан соң бу әкиятләрдә һич бертөрле логика юк. Мәсәлән, бәни Исраил бозау вакыйгасыннан соң 40 ел адашып йөргән чагында гыйфритләр шәһәренә килеп чыга. Буйлары 300 аршын, ә бәни Исраилнең иң озын кешесе 15 аршын... Галимнәр 4 мең генә түгел, 40 мең ел элек яшәгән кешеләрнең сөякләрен казып алып өйрәнделәр. Иң озын кеше өч метрга житми. Күптән түгел 500.000 ел элек яшәгән кешенең баш сөяге табылды. Аның күләме безнекеннән әз генә дә артык түгел. Ә Коръән гыйфритләре, имештер, өч йөз аршынлы булганнар!.. Ягъни 80 катлы йорт буе!.. Һәм бу фальшь тагын бер фальшь китереп чыгара. Анысы болай. Муса үзенең 12 кешесен шул мәжүси гыйфритләргә илче итеп җибәрә.

— Ник килдегез?

— Илче булып.

— Ха-ха-ха, әллә сугышмакчы буласызмы?

— Әһә.

Сакчы гыйфрит, имештер, боларның алтысын бер кесәсенә, алтысын икенчесенә салып, патша сараена алып китә...

Уйлап карыйк. Гыйфритләр Исраил кешеләренә караганда 20 тапкыр авыррак. Аерма — хәзерге олы кеше белән яңа туган балалар чамасы. Әйтегез, мулла абзыйлар, ике кесәгә яңа туган унике баланы сыйдырып буламы?

Шуннан патша боларга бер йөзем җимеше бирә. Муса кешеләренең икесе, имештер, шул йөземне көчкә күтәреп кайта. Йөзем җимешләре һәр илдә кешенең буена карап үстеләр ди. Димәк, чама белән гыйфритләрнең йөземнәре безнекенә караганда 20 өлеш зуррак. Ягъни 400 грамм. Шул йөземне 15 аршынлы ике кеше көчкә күтәргән булып чыга!..

Бер йомгак ясап алыйк.

Бәни Исраил мәсьәләсендә алланы тик ятты дип әйтерлек түгел, күрдегез, Муса туганчы ук хәстәренә кереште. Ниһаять, 40 көн буена Тур тавында бәни Исраилгә ничек-ничек җитәкчелек итү турында Мусага күрсәтмәләр биреп ятты, Тәүратны язып бирде. Анысы да шул ук бәни Исраил өчен... Мусаны да түшәмгә төкереп ятты дисәк, дөрес булмас. Ә нәтиҗә? Хәтта Мысыр Фиргавене кулында чакта каты җәбер-золым астында хак мөселман булып яшәгән 600 мең бәни Исраилнең 588 меңе мәҗүси дингә чыгып, бозау сынына иман китертә. Ә калган 12 мең? Аларын алла маймылга әверелдерә. Беләсезме нәрсә өчен? Тегеләр, бу манна белән бытбылдык туйдыра башлады, безгә, сарымсак, суган, ясмык кебекләр дә булсын иде, диләр. Әлбәттә, бәни Исраил хаклы. Кешенең организмы өчен болар зарур ризыклар. Алла исә, бу хәлгә ачуы килеп: «Ә, әле сез мин биргәнгә канәгать түгелмени?!» — ди. Юк, монысы өчен тими әле, алла яман да каты кисәтү генә ясый. Тегеләр тәүбәгә килә. Ләкин озак та үтми, алланың тагын да катырак ачуына дучар булалар. Яһүдләргә шимбә көн эшләү язык бит. Әлбәттә, балык тоту да язык. Ә шимбә — балык иң чиртә торган көн була!.. Нишләргә? Болар алланы утыртмакчы. Балыкны шимбә тоталар да, яшереп торып, өйләренә якшәмбе көн генә алып кайталар. Ә алла (алдарсың, бар, алланы!..) яһүдләрнең бу мутлыкларын сизеп алып, бер нәгъръә орып, маймыл булыгыз, бәдбәхет токым! — ди һәм тегеләр шундук җыенысы маймылга әверелә. Алла белән Муса пәйгамбәр тырышлы-

гының бөтен нәтиҗәсе энә шуңардан гыйбарәт. Я әйтегез, бәни Исраилне шуның өчен Фиргавен золымыннан коткарып тору кирәк идеме?

Ә бәлкем мәҗүси дингә чыккан 588 мең кеше, бер көн килеп, яңадан мөселманга кайткандыр? Кайтмаган. Муса аларга:

«Йа, минем халкым! Бозау сынына табыну белән сез үзегезгә үзегез начарлык эшләдегез. Хәзер сезнең өчен иң яхшысы шул: алла юлына кайтып, бер-берегезне үтерегез», — ди.

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 51 аять.)*

Имештер, бәни Исраил шулай итә дә.

— Берсе дә исән калмыймыни?

Кала. Алары да:

«Әй, Муса, алланны үз күзебез белән күрми торып, иман китерәсебез юк, диләр. Башта күрсәт алланны. (Урынлы дигәндә дә урынлы таләп — Г. Г.) Ләкин монысы өчен аларның да күбесен яшен сугып үтерә.

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 153 аять, «Сыер» сүрәсе, 52 аять.)*

Я, әйтегез, шуның өчен бәни Исраилне Фиргавен золымыннан коткарып тору кирәк идеме?

Мулла абзыйлар җавап әзерли торсын, без сезнең белән яңа сәхифәләрне ачыйк.

## 11

## БЕР ТӨНДӘ ҖИТМЕШ ХАТЫН. ТУКСАН ТУГЫЗ ХАТЫНЛЫ ПӘЙГАМБӘР. ҖЕННӘР ХӘЙЛӘСЕ. АЛЛАНЫҢ ТАГЫН БЕР ЯЛГАНЫ

Бу бүлек нәкъ әнә шул ялганны фаш итү белән башланып китсен әле.

«Балкортлары» сүрәсенең 38 аятендә алла, ике төрле аңларга урын калдырмаслык итеп:

«Без һәрбер халыкка пәйгамбәр җибәрдек», — ди. Һәм Коръән үзе үк моның ялган икәнен фаш итә. Коръәндә һәм башка дини китапларда мәгълүм булган 28 пәйгамбәрнең, хак пәйгамбәрнең, берсе генә дә кытай, һинд, индус, инглиз, рус, француз, украин, белорус кебек ишле халыкларга килми: үзбәк, татар, казакъ, кыргыз һ. б. лар кебек йөзләрчә вак милләтләрнең хак пәйгамбәр турында ишеткәннәре дә булмый. Гарәпләргә бер, насара халкына бер пәйгамбәр килә. Ә менә җир йөзенең ике меңнән нибары бер өлешен биләп торган, җир йөзендәге халыкларның ике меңнән нибары бер өлешен тәшкил иткән бәни Исраилгә (ягъни борынгы яһүдләргә) пәйгамбәрнең килеп торган көне! 28 пәйгамбәрнең 26 сы: Мусасы, Йосыфы, Ибраһимы — бар да, бар да шуларга!..

Сәер түгелме? Менә тагын да сәеррәге. Бәни Исраилне әле генә кайсын үзара кырылыштырып, кайсын яшен белән һәлак итеп, калганын маймылга әверелдереп бетергән иде бит. Әллә бу турыда онытты, әллә яңадан терелтте, әллә инде бер мәзәк булсын, диде, — Мусаның гәүдәсе суынып та өлгермәде, — алла бәни Исраилгә янә пәйгамбәр җибәрә, берне түгел, икене!.. Давытны һәм аның сөекле улы Сөләйманны. Бәни Исраил дә әллә үзенең һәлак булганын онытты, әллә яңадан туды, әллә просто мәзәк өчен, берни булмаган кебек, яңадан дөбердәтеп яши башлады!..

Гадәттән тыш сергә әйләнгән бу халыкның яңа пәйгамбәрләре гадәттән тыш сәләткә, гадәттән тыш кодрәткә ия булалар. Сөләйман үзенә кадәр килгән һәм үзеннән соң киләчәк пәйгамбәрләрнең берсе дә эшли алмаган эшләрне башкара. Башкалар кешеләрне генә дә тыңлата алмаган дие бит, моңар исә кош-кортларга хәтле буйсына.

Дөньяда ничә мең төрле кош бар, — бу бөтенесенең телен белә, бөтенесе-бөтенесе моның хезмәтенә тәйяр, хуҗалык эшләрендә генә түгел, дин юлында да тугры ярдәмчеләр. Һәд-һәд дигән кош берәр җирдә берәр халыкның мәҗүси диндә идекен күрдеме, — хәзер моңар кайтып әйтә. Сөләйман пәйгамбәр тегеләрне хәзер дингә өндәп кертә.

Анысы бер хәл әле. Хәтерегездәме, җир йөзендә кешеләр кебек яшәгән чакларында җеннәр аллага каршы баш күгәргән иделәр? Хәтта әнә шул җеннәр Сөләйман пәйгамбәргә килеп баш ия. Сөләйман алардан кяферләр белән сугышыр өчен көчле гаскәр төзи. Хәтта шайтан хәтле шайтаннар да бу шанлы пәйгамбәрдә диңгез төбеннән энҗе аулаучы водолаз булып хезмәт итә. Моны сезгә мин түгел, имештерки, алла үз авызы белән әйтә:

«Без аңа шайтаннарны, төрле-төрле төзүчеләрне, водолазларны һәм бер-берсенә чылбыр белән тагылган кешеләрне (колларны — Г. Г.) буйсындырдык. Бу сиңа безнең бүләк. Мәрхәмәт ит яки теләгәнчә туздыр».

*(Коръән, «Сад» сүрәсе, 36—38 аятьләр.)*

Башкага ни сан, тауларга хәтле буйсына Сөләйманга, таулар хак мөселман диненә керәләр. Әйе, әйе. Кич-иртә, Сөләйман белән бергәләп, аллага гыйбадәт кылалар таулар.

Давыт белән Сөләйманны мин Коръән үзе пәйгамбәр дип атаганга күрә генә пәйгамбәр дим. Миңа калса, аларны ярты алла дияргә булыр иде. Алланың үзенә буйсынмаган шайтанны буйсындырсын әле! Шайтан башы белән, хурланмыйча, шул бер адәми затка хезмәт итеп йөрсен әле!

Арттырып әйтүем түгел, Сөләйман күп мәсьәләдә, мәсәлән, зирәклек белән хәйләдә алланың үзеннән дә уздырып җибәрә. Алла үзен һәр очракта: мин хәйләгә иң оста, иң зирәк зат, ди бит, бу исә алай шапырынып йөрми, ә булдырыйм дигәнен булдырмый калмый. Хәтерегезгә төшереп үтим. Алланың тәхетен дүрт фәрештә күтәреп йөри бит. Заман ахыры булгач, бу эш өчен сигез фәрештә кирәк булачак. Сөләйман исә эшне шулай көйләгән: диңгездә корабны җил ничек йөртсә, моның тәхетен дә җил очырып йөртә.

«Без Сөләйманга җилне буйсындырдык, кайсыдыр ки аның боерыгы белән ул теләгән якка исә».

*(Коръән, «Сад» сүрәсе, 35 аять.)*

Алла Сөләйман пәйгамбәргә җилләрне хезмәт иттерү белән шул кадәр мавыга, авызы ни әйткәнне колагы ишетмәс хәлгә килә.

«...Сөләйманга җил хезмәт итте. Иртә белән ул бер ай исте, кич белән дә бер ай исте...»

*(Коръән, «Саба» сүрәсе, 11 аять.)*

Бер тапкыр моңар бер җен фәлән илдә искитмәле бер матур кыз яшәгәнен кайтып әйтә. 70 көнлек юл. Бу үзенең тәхетенә утырып, җилне җигеп, әлеге кыз янына өч көн дигәндә барып җитә.

Көннәрдән бер көн моның янына бер ханбикә килергә тиеш. Ханбикә тәскә-биткә чибәр, ләкин тәнен яман да җөнтәс дип сөйлиләр. Бүтән берәр пәйгамбәр аптырап калыр иде, ә Сөләйман, беләсезме, нишли? — Ханбикә килгән урынга саф пыяладан сарай салдырып куя. Ханбикә, бусагадан атлауга, күлгә килеп кердем дип белеп, итәкләрен күтәрә. Сөләйманга шул гына кирәк тә: тәненең йонсыз икәнен күреп кала.

Сөләйман пәйгамбәрнең хәйләгә оста булуы турындагы риваятьләрне тавык чүпләп бетерерлек түгел. Имештер ки, үлгәннән соң да әле аның хәйләкәрлек сәләте бетми. (Өлкәнрәкләрнең хәтерендәдер, ул риваять-

ләрне хәзрәтләр безгә мәдрәсәдә бик төчеләнеп сөйлиләр, без дә мөкиббән китеп тынлый идек.) Ләкин, хикмәти хода, бер тапкыр җеннәр хәйләдә моның үзеннән уздырып җибәрәләр. Озынга китсә китәр, бу турыда язып үтүне тиеш таптым. Үзегезне әллә ни шаккатырып булмас, ә балаларга укыр өчен кызыклы гына.

Бәйтелмөкаддәс дигән мәчет була. Имештер, аны атабыз Адәм үзе үк сала башлаган, шуннан бирле пәйгамбәрдән пәйгамбәргә күчә килеп, Давытка килеп житкән. Давыт пәйгамбәр дә үзе салып бетерә алмагач, Сөләйманга васыять итеп калдыра. Сөләйман бу эшкә үзенең җеннәрен куша. 35 ел көн-төн тир түгә җеннәр; алай да бетерә алмыйлар. Хәзер Сөләйман нишләргә тиеш? Җитмәсә, әнә Газраил! Җан алучы килгән!..

Газраил Сөләйман пәйгамбәр, мәчет михрабында таягына таянып, өммәтенә вәгазь сөйләп торган чакта килә. Дивар ярылып китә дә, пычагын кул йөзенә кайрый-кайрый очып килеп керә ул мәчеткә. Һәм кәрә-керүгә пычагын Сөләйманның бугазына сызып та җибәрә. Ләкин пәйгамбәр җебеп төшми, үлгәнен җеннәргә белдермәс өчен, җеннәр Бәйтелмөкаддәсне ташлап качмасын өчен, таягына таянган килеш басып тора бирә. Артык түгел, ким түгел, нәкъ бер ел тора ул шул хәлендә. Егылмый, череми. Мөселманнар мәчеткә киләләр, намаз укыйлар, китәләр, ә михрабта әллә пәйгамбәр, әллә багана, ник берсе күтәрелеп карасын!.. Елның ел буена өйгә кайтмавы хатыннарының ник ике ятып бер төшләренә керсен!.. Тик җеннәр генә, ник моның тавышы тыны юк икән дип, шиккә төшәләр. Үзләре килеп карарга уңайсызланалар. Һәм менә нинди хәйлә коралар. Моның янына агач корты җибәрәләр. Корт шыпырт кына таякны кисә һәм Сөләйман шап итеп идәнгә ава. Җеннәргә шул гына кирәк тә. — «Үлгән!..» — Богауларын өзеп ташлап, Каф тавы артына, үз илләренә качалар!..

*(«Кассас-эл-әнбия», икенче җөзьә, 267 бит.)*

Менә ничек кызык итәләр җеннәр Сөләйман пәйгамбәрне.

Инде Сөләйманның этисе — Давыт пәйгамбәр турында. Давыт пәйгамбәр дә улы кебек үк хәйләкәр, тапкыр, зирәк, сәләтле булу белән бергә, хатын-кызга яман да хирес була. Хәләл җефетләре генә дә туксан тугыз. Юк, гиперболик туксан тугыз түгел, туксан сигез белән йөз арасындагы чын туксан тугыз! Төрләнгән чакларында, тыкрык өйләргә борылып керүне дә онытмый... Әйтеп торасы да юк, җеннәр белән кошларны буйсындырырлык сәләте булган пәйгамбәргә хатын-кызның гына башын-күзен әйләндерү әллә ни читен булмагандыр дип фараз кылырга нигез бар. Һәм менә моның ачык мисалы. Көннәрдән бер көн моның күзе Бәтхәш исемле бер күрше хатынга төште. Төште — бетте! Иреннән аертып, хатынны үзенә никахлый. Күрше берсез дә калды, аның каравы пәйгамбәрнең хәзер түгәрәк сан — йөз булды!!!

Тора-бара ул, бәлкем, икенче йөзгә дә керешкән булыр иде. Ләкин (гөнаһсына керешмик, пәйгамбәрнең бу эшеннән алла үзе дә риза булмый) алла бик әйбәтләп моның арт сабагын укыта, Бәтхәшне аерып, элекке иренә кайтарып бирергә куша:

— Шул туксан тугыз да бик житкән сиңа!..

Әйтергә кирәк, алла бу боерыкны Давытка гади тел белән түгел, киная белән аңлата. Һәм ул үзе бер кызык әкият. Эш шунда ки, Давыт— пәйгамбәр генә түгел, бик зирәк һәм гадел судья да була.

«Бер заман суд залына дивар аша ике кеше килеп керде. Менә алар Давыт янына килделәр. Давыт алардан куркып китте. Алар әйтте: «Курыкма, без бер-беребезгә дошман кешеләр, беребез икенчебезгә усаллык эшләде, безне хаклык белән хөкем ит, безне туры юлга алып чык. Бу минем абыем, аның туксан тугыз сарыгы бар, минем — бер; абыем, сүзе белән юмалап, минем шул бер сарыгымны да тартып алды...»

*(Коръән, «Сад» сүрәсе, 20—22 аятьләр.)*

Зирәк пәйгамбәр моның үз бакчасына атылган таш икәнен аңлый, күрше хатынын аерып, иренә кайтарып бирә. Пәйгамбәр янә туксан тугыз хатын белән кала.

Авыр туфрагы җиңел булсын, Давыт углы Сөләйман пәйгамбәр дә бу мәсьәләдә әтисеннән бик әзгә калыша. Ачыклык кертеп китим, фәкать сан ягыннан гына калыша. Ә җенеси гайрәт, җенеси дәрткә килгәндә!.. Көннәрдән бер көн хатыннарын санап караса, ташлап киткәннәрдерме, үлә башлаганнардырмы җитмешкә калган!..

— И-и, болай ярамас, нәсел үрчетү хәстәренә керешергә вакыт...

«Сөләйман пәйгамбәр әйтте: бу кичне шул җитмеш хатыным белән якынлык кылыйм, җитмеш угыл тудырып бирсеннәр...»

Әйтте — бетте:

«Бер кичтә җитмеш хатыны белән якынлык кылды».

Ләкин пәйгамбәрнең тырышлыгы бушка китә, гөнаһ шомлыгына каршы, теләге кабул булмый. «Чөнки «инша алла» диярга онытты. Җитмешеннән бер бала туды, ул да гарип иде».

*(«Кассас-әл-әнбия», 260 бит.)*

Ашык-пошык кына укып китмә, укучым, уйлан бераз. Кыска булса да, гыйбрәт алган кешегә гыйбрәтләр бар монда: андый эшкә «инша алла»сыз керешсәң, Сөләйман пәйгамбәр көненә каласыңны көт тә тор дигән сүз бу!

Баштагы сүземә кайтып кабат әйтәм, юк, аталы-уллы бу ике пәйгамбәрне бер дә башкалар белән бер исемлектә йөртә торган түгел. Бүтән яклары белән онытсагыз да, җенеси сәләтләкләре белән кылт итеп исләрегезгә төшәчәкләр.

Тагын бер хикмәтле сыйфатларын әйтми калсам, бу ике мәшһүр пәйгамбәрнең портретлары тулы булмас иде. «Көннәрдән бер көн Давыт пәйгамбәр, мөнбәргә менеп, вәгазь-нәсихәт кылды, соңра Забур китабын алып, олуг тавыш белән укыды. (Бу олуг тавыш ирләргә ничек тәэсир иткәндер, безнеңчә, кимендә, тәһарәтләре сынган булса кирәк — Г. Г.) Тирә-юньдәге хатыннар һушсыз булып егылып, бала төшерделәр».

*(Коръән, «Кырмыскалар» сүрәсе, 15—45 аятьләр, «Пәйгамбәр» сүрәсе, 78—82 аятьләр, «Сад» сүрәсе, 16—25 аятьләр, «Кассас-әл-әнбия», Сөләйман белән Давыт кыйссалары.)*

Безнең заманда, бездә димим, иң кыргый илдә дә куркытып бала төшертү кебек «мәзәкне» берәрсе эшләсә, юк дигәндә хулиганлыкта гаепләп, төрмәгә ябарлар иде. Алла исә, моны изге эш күреп, булдыра бит минем пәйгамбәр дигән кебек сокланып күктән карап тора...

Мулла абзыйларга тагын бер сорау: без бу мәзәктән нинди гыйбрәт алырга тиеш булабыз?

## 12

### ГАЙСӘНЕ КЕМ УЛЫ ДИП БЕЛӘСЕЗ? «МЕНӘ ХӘЗЕР ТАБЫНЫРЛАР ИНДЕ». БЕЗНЕҢ БӘХЕТКӘ КАРШЫ УЛ ЮК. «ШУЛАЙ БУЛГАЧ, ПӘЙГАМБӘР НИГӘ?»

Бер төн эчендә җитмеш хатын... Сәламәтлегең шулар какшаттымы, аллаһ тәгалә бу изге пәйгамбәрнең җанын тизрәк җәннәтенә кертергә ашыкты, — Сөләйман сиксән яшенә чыгу белән югарыда бәян кылынган рәвештә җан тәслим кылды. Дин китаплары озакламыйча әтисенә дә шул көн килү турында хәбәр иттәләр: монысы фани дөнья белән бәхилләшкәндә туксан тугыз яшендә иде. Туксан тугыз абыстае ятим калды, ничәмә сабый ятим калды, йөзләрчә бүтән милләтләр ник шунда чәнче-

леп китми, — әлеге дә баягы, — бәни Исраилебез, үзебезчә әйтсәк, еврейләр ятим калды... Ләкин озакка түгел, алла үзенең сөйгән халкына тиз көндә яңа пәйгамбәр җибәрергә карар кыла. Ләкин ничек? Мусаны диңгездән таптылар, Йосыфны коедан алдылар, Якупны 89 яшьлек әби тудырды. Тукта, яңа пәйгамбәрнең дөньяга килүен тагын да шаккатмалырак, тагын да мәзәгрәк, тагын да гыйбрәтлерәк итсен әле!..

Әйтте — бетте. Пәйгамбәр булачак баланы алла Мәрьям атлы гыйффәтле кыздан, никахлы ире булса да Йосыф Зөләйхасы кебек гыйффәте сатылмаган кыздан һич бертөрле ир затын орындырмыйча-нитмичә тудырта.

Тын калыгыз, дөнья уйларын башыгыздан чыгарып ташлагыз. Хәзер аллаһ тәгалә моны безгә тасвирлы һәм тәэсирле итеп үзе, үз теле белән сөйләп бирә:

«Менә Мәрьям үзенең әти-энисеннән качып, көнчыгыштагы бер җиргә килде. Кешеләрдән чаршау белән томаланды. Шуннан без аның янына сулышыбызны юлладык. Сулышыбыз Мәрьям янына кеше кыяфәтендә килде».

«Мәрьям әйтте: әгәр алладан курыксаң, кит, мин монда аллага сыену урыны эзләп килдем».

Ул (алланың кеше кыяфәтенә кергән мөбарәк сулышы — Г. Г.) әйтте: мин фәкать алланың илчесе генәмен, сиңа саф бала бүләк итәр өчен килдем».

«Мәрьям әйтте: минем ничек итеп малаем булсын? Миңа ирләрнең орынганы да юк. Минем бозык кыз булып йөргәнем юк».

Сулыш Мәрьямне тынычландырып әйтте:

«Алла үзе шулай диде: бу эш минем өчен бик җиңел, диде алла. Ул баланы без кешеләргә гыйбрәт итәрбез, бу мәсьәлә хәл кылынган, диде».

Мәрьям янына кеше кыяфәтендә килгән сулыш, ходаның хикмәте, Җәбраил фәрештә булып чыга!

«Җәбраил галәйһиссәләмнең бу рәвеш күренмәкенә **Мәрьямнең шәһвәте кузгалып, балалык капчыгына акты**. Җәбраил фәрештә **гыйффәтле кызның билгеле урынына** тиз генә алла җибәргән сулышны өрде. Сулыш Мәрьямнең эченә китте. Җидеме-сигезме ай дигәндә, пәйгамбәр булачак углан, дөньяга килеп, үзенең тавышын ишеттерде».

*(Коръән, «Мәрьям» сүрәсе, 16—22 аятьләр, «Кассас-әл-әнбия», 307—308 битләр.)*

Инде моннан соң да аллага ышанмаска мөмкинме? Моннан соң да алланың зирәклегенә, аның кодрәтенә, беркем башына килми торган мәзәкләрне ничек ансат уйлап чыгара торган тапкыр зат булуына хәйран калмаска мөмкинме?!

Шул ук Коръән «Пәйгамбәрләр» сүрәсенең 91 нче аятендә бу вакыйганы тагын да тәэсирлерәк, гыйбрәтлерәк итеп тасвир итә. Монысында тагын шунысы гыйбрәтле, биредә инде без алланың бу изге эшне баштанаяк бер үзе башкарып чыкканын күрәбез.

**«Үзенең кызлыгын саклаган кызга без үзебезнең сулышыбызны өрдек,** — әй алла, — Мәрьямне һәм аның улын бөтен дөньяга үзебезнең бар икәнебезнең билгесе иттек».

«Билгесе» итүең — вак мәсьәлә. Җирләрне-күкләрне юктан бар итеп тә барлыгыңа ышанмаганнар икән, моның белән генә барыбер ышандыра алмыйсың. Ышанганнар өчен исә бу — бишенче тәгәрмәч. Галимнәр җир әйләнә оча торган һава корабы ясап, кеше очырып йөрткәннән соң, менә без мондыйларны да булдырабыз дип, безгә кул арбасы китереп күрсәтсәләр, бу бик көлке чыгар иде, без ул галимнәрне, һичшиксез, акылдан язган санар идек... Бу аятьнең безне тәэсирләндерә торган, күзләребездән яшь килерлек итеп безнең күңелләребезне эретә торган җире — беренче өлеше. Яшь кыз, алла бик тырышып кызның **билгеле бер**

жиренә сулыш өреп тора. Кызның женеси дәрте кузгалып, шәһвәте китә. Шәһвәт, алланың мөбарәк сулышы белән бергә кушылып, кызның аналыгына керә... Мондый изге, мондый илаһи күренешне рәсем белән аңлатканда нинди күңелле чыгар иде, әйе бит?

...Мәрьямгә оят. Ул, бу хурлыкны күргәнче, үлсәм иде ичмаса, ди. Шул чак, — сезгә ялган, миңа чын, — Мәрьям астыннан алла эндәшә. Әйе, әйе, алла! Ә нәрсәгә кергән соң ул картлач Мәрьям ана астына? Нәрсә дип эндәшә ул Мәрьямгә? Бу урында минем телем әйләнми. Әнә алла үзе әйтсен.

«Кайгырма, Мәрьям! Синең аллаң синең астыңа **чишмә агызды».**

*(Коръән, «Мәрьям» сүрәсе, 24 аять.)*

Моннан соң алланы, кайбер художниклар ясаганча, тәхетендә кулларын жиң очларына тыгып йокымсыранып утырган кыяфәттә күз алдына китерсәк, вә һәм дә кайчак мутланып алырга яратмый дисәк, безне хакыйкатьтән ерак торуда гаепләмәсләрме?

Дөресен генә әйткәндә, иптәшләр арасында бу җәнҗаллы вакыйганы китаптан төшереп калдырырга киңәш итүчеләр дә булды. Ә мин үзем болай уйладым. Алла хәтле алла шуны эшләргә дә оялмаган, җитмәсә, әнә ничек тасвирлы итеп үзенең Коръәненә керткән, бүгенгесе көндә мулла абзыйларның наданнары, мәгънәсен үзләре дә белмәгән хәлдә шул юлларны мәет өстендә, мәчетләрдә әһле исламга ничек мөкиббән китмәле тәмле көйләп укыйлар... Мәчеткә йөрмәүчеләр дә мәхрүм булмасын, дидем.

...Малайга Гайсә дип исем бирәләр.

Әлбәттә, орлыгы ана карынына шул рәвешчә фәүкыйгадә бер ысул белән кергән бала үзенең буш кеше түгел икәнен дөньяга килгәч тә күрсәтә башлый. Бишектә чакта ук инде камил акылга ия була. Зинадан туган диючеләр белән якалаша. Моның акылы, зирәклеге, сәләте каршында теләсә кайсы пәйгамбәр мескен бер күләгә булып кала. Әйе, әйе, мондый фикерне әйтергә минем бик төпле нигезем бар. Пәйгамбәрләрдән иң иртә өлгергәне дә үзенең эшчәнлеген 40 яшендә башлап җибәрә, моны исә алла бишектә чакта ук пәйгамбәр итеп билгели, аңар шундук Инҗил исемле махсус шәригать китабы индерә. Әле генә без Сөләйманның кошлар белән сөйләшә белгәненә хәйран калып укыган идек, бу исә кошларны үзе ясый. Сукырларны күзле итә, үлгәннәрне терелтә. Ә беләсезме, кемне терелтә? Дүрт мең дә егерме бер ел элек вафат булган Самны, Нух пәйгамбәрнең өченче улын!..

Бу юлларны укыганда әһеле ислам: сөбеханалла, дияр, һа-а, дияр. Ә кире беткән бәни Исраил, хикмәти хода, бу хикмәтнең бөтенесен үз күзе белән күреп торса да, исе китми. Гайсә пәйгамбәргә ни бары унике кеше иман китерә. Аның каравы, үзен туйганчы мәсхәрә итәләр. Аңар карата авызларында иң «ягымлы» сүз: мәҗнүн дә сихерче... Янау, эзәрлекләү... Ләкин, алла ташламаса, бүре ашамас: яһүдләр Гайсәне тотып үтерү теләге белән, күрәсең, ниндидер бер хәйлә корган булалар. Алла да аларга каршы хәйлә кора:

«Алар хәйлә корды. Алла да (аларга каршы) хәйлә корды. **Ә алла — иң оста хәйләкәр».**

*(Коръән, «Гыймран» сүрәсе, 47 аять.)*

**Алла — иң оста** хәйләкәр... Бередә укучы бик хаклы рәвештә алланың искиткеч хәйлә корганын көтә. Ләкин иң оста хәйләкәр алла шыр тиле адәм башына да килмәслек тилелек эшли. Гайсәне турыдан-туры күккә ашырасы урында менә нәрсә эшли ул:

«Гайсә, мин сине үлемгә дучар итәм. Аннары үземнең янга күтәрәм. Сине иман китермәүчеләрдән коткарам».

*(Коръән, «Гыймран» сүрәсе, 47—48 аятьләр)*

һәм шулай итә дә. «Гайсә дип белеп, башка берәүне тотып үтерәләр, ә Гайсәне алла күккә ашыра. Ул хәзер дә шунда, алланың үзеннән өч кенә кат түбән күктә яши».

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 156 аять, «Кассас-эл-әнбия», Гайсә бабы.)*

Бу әкиятнең мәзәге башкаларыннан бер дә ким түгел, әйе бит? Ләкин очы очка килеп бетми шул. Коръән һ. б. изге китаплар раславынча, Мәрьям туташ Муса белән Һарун пәйгамбәрләр сеңелесе була бит. Бу исәптән ул инде алла «сулышы»ның куенына кергән көннәрдә бернечә йөз яшендә булырга тиеш иде. Ә ул шул ук Коръән раславынча, нибары 13 яшьлек гыйффәтле туташ!.. Коръән раславынча, Мәрьям белән Гайсә, Мысырда уникe ел яшәгәннән соң, Насара карьясенә күчеп киләләр. Ә ул карья Гайсә әкияте барлыкка килгән заманда бөтенләй булмый әле, Гайсә үлгәннән соң салына гына башлый!.. Инде шуларга өстәп, күп кенә изге китаплар әйтүенчә, шул җөмләдән Тәурат әйтүенчә, Гайсәнең Ирод исемле патша заманында яшәгәнен, чынлыкта исә, бу патшаның Гайсә әкияте дөньяга килүдән 500 ел элек вафат булганын да әйтеп бирсәк, бу әкиятнең бөтенләй тузга язмаган, һич берниндн нигезе булмаган әкият икәнлегенә, шөт иншалла, һичбер кешедә шик калмас.

*(«Мәрьям» сүрәсе, 28—29 аятьләр; «Кассас-эл-әнбия», 307 бит; «Әнбияләр тарихы», 14 бит.)*

Ә соң дөнья йөзендә нинди дә булса берәр төрле Гайсә булганмы? **Берәр төрлесе** булган булуы мөмкин. Хәтта аның пәйгамбәрлек дагъва итеп, мин алланың җир йөзендәге тулы хокуклы һәм чиктән тыш вәкаләтле илчесе, дип йөрүе дә бик мөмкин. (Борынгы заманда андый шарлатаннар аз булмаган.) Ләкин Коръән Гайсәсе, аңар бәйләнешле могҗизалар, алда әйткәнемчә, бөтенесе нигезсез. Моны исбат итү өчен түбәндәге хакыйкать үзе генә дә җитә.

Коръән белән Инҗилдә тасвирланган Гайсә «яшәгән» заманда дөньяда инде философлар, тарихчылар, язучылар күп кенә була, һәм алар шул замандагы юк кына вакыйгаларны да язып калдыралар. Ә бөтен яшәеше могҗизалардан гыйбарәт Гайсә турында ләм-мим. Әгәр Гайсә тарихи шәхес булган булса, философлар, тарихчылар, язучылар арасында бөтен гомерләрен аның турында язуга багышлаучылар да табылыр иде. Чагыштыру өчен Гайсәдән элек кенә телгә алынган Давыт белән Сөләйманны китерергә мөмкин. Алар булган, безнең эрага мең ел кала яшәгәннәр. Сөләйман, Коръәндәгечә, чамадан тыш бай булган, искиткеч зиннәтле сарайлар салдырган, Коръәндәгечә һ. б. дини китаплардагыча, хатыннары 99 булган. Ләкин ул пәйгамбәр түгел, патша. Израил (еврейләр) патшасы. Чын исеме Шеломо, тарихка Соломон булып кергән, Тәуратта да шулай йөри. Давыт та, нәкъ Коръәндәгечә, Сөләйманның әтисе. Әлбәттә, монысы да һичбер пәйгамбәр түгел, патша, шул ук еврей патшасы, бердәм Израил мәмләкәтен төзүче адәм. Залимлектә, кансызлыкта тиңе юк. Бозыклык үрнәге. Хатынын үзләштерү максаты белән үзенең полководецын үтергән кеше.

Әйтәсем килгәне: аталы-уллы бу ике патша турында шул заманның бөтен язучылары да язганнар, бик күп язганнар, әйткәнемчә, Гайсә турында бер сүз юк. Чөнки Гайсә үзе юк.

Гайсәгә кадәрге пәйгамбәрләрнең әкиятләре Коръәнгә Тәураттан кергәнен әйтеп үткән идек. Гайсә әкиятенең Коръәнгә тик, әлеге дә баягы, артык әдәпсез урыннары: Гайсәнең тиңдәшсез фахиш булуы, гомеренә иң пычрак фәхишәләр белән чуалуы, тагын торгапы ил өстеннән ашап йөрүче әрәм тамак булуы төшереп калдырылып, Инҗилдән кергән. Һәм бу кергән кадәресенең бәгъзе бер урыннары бераз кыскартылган яки озынайтылган. Сизелерлек үзгәртелгән урыннары бик аз. Ин-

җилдә агачка, Гайсәнең унике шәкертеннән берсен түгел, үзен кадаклыйлар. Өч көннән аңар янәдән җан керә, кырык көн үтүгә ул да Коръән Гайсәсе кебек үк күккә аша һәм хәзер дә шунда яши бирә. Тагын бер үзгәлек: Инҗил, бер дә тартынмыйча (мин әйтер идем, әкият рамкаларында бик хаклы рәвештә), Гайсәне алла улы ди. Коръән аның шулай икәнен үзенең битләрендә, югарыдагыча яхшы ук образлы итеп тасвирласа да, турыдан-туры улы ук дип әйтеп бетерми. Ләкин юкка! Ысулы гына үзгә булган бит... Бу эшне кайсы гына илнең суды тикшерсә дә, алиментны, әлбәттә, алладан түләтәчәк.

Гайсә әкияте Коръән өчен оригиналь булмаган кебек, Инҗил өчен дә оригиналь түгел. Ул Инҗилгә бик борынгы халыклардан килеп кергән бер миф. Һәм аның вариантлары берничә. Борынгы грек мифындагы тиңсез батырлыклар күрсәткән пәһлеван Геракл (Геркулес)ның да әнисе, имештер, җир кызы, әтисе — алла үзе була. Кытай, япон һәм индуслар алласы — Будда шулай ук Майя исемле гыйффәтле кыздан туа. Будданың да нәкъ Тәурат һәм Коръән Гайсәсенеке кебек уникe шәкерте була, аның да бер шәкерте хаин булып чыга. Фригия халкының киң таралган бер мифындагы Аттис исемле алла сыман пәһлеванның да әнисе Нина исемле гыйффәтле кыз, ә әтисе бер могҗиза. Аттис шулай ук бер үлгәч яңадан терелеп яши башлый. Грек мифындагы Загрей-Дионис та үлгәч терелә. Тик янәдән җиргә кайтмый, җир асты патшалыгында үлекләр судьясы булып кала. Персия белән Индиянең Митра дигән бик борынгы бер аллалары гыйффәтле кыз — алладан туа, төрле могҗизалар эшләп йөри. Үләр көннәре җиткәч, үзенең шәкертләрен җыеп кунак итә. Һәм, аларга вәгазь-нәсихәтләр биреп, кайчан да бер янә җиргә төшәсен, динсезләрне дингә кертәсен әйтеп, әнисе янына күккә күтәрелә. Коръән белән Инҗил Гайсасе дә нәкъ шулай. Кыямәт алдыннан ул да җиргә төшәргә тиеш... Мондый үлгәч терелеп күккә күтәреләләр, янәдән җиргә төшүләр, гыйффәтле кыздан туу кебек тузга язмаган әкиятләр бөтен дөньядан җыйсаң, берничә дистәгә тула.

Чынбарлыкта исә үлгәнне терелтү бары безнең заманда гына күренә башлады. Ләкин моны бернинди аллалар түгел, безнең врачлар эшли. Моның иң күренекле мисалы — 1963 елның көзендә безнең илдә, Минск шәһәрендә булды. Виктор исемле 21 яшьлек егет врачлар кулында үлә. Йөрәге бөтенләй туктый. Кызганыч, кичә генә техникумны тәмамлап чыккан иде бит... Профессор Сергей Либов һәм аның коллегалары 38 минуттан соң егетнең күкрәк сөяген ватып кереп, үлгән йөрәгенә «ясалма йөрәк» аппараты тоташтыралар... Бер минут үтә, ике, өч, дүрт, биш... Алты минут дигәндә мәеттә яшәү билгеләре төсмерләнә башлый. Егетнең үлгән йөрәгенә янәдән «җан» керә. 18 минуттан «ясалма йөрәк»нең кирәге калмый. Бер тәүлек үтүгә Виктор аңына килә.

*(«Известия», 1963 ел, 20 ноябрь.)*

Күптән түгел Норвегия илендә тагын да искитмәлерәк хәл булды. Сабый бала батып үлә, 30 минуттан гына күл төбеннән табып алалар. Шундук малайның веналарындагы үлгән канын агызып, яңа кан җибәрәләр. Ясалма сулыш алдыру, йөрәгенә массаж... Табипләрнең фидакарь тырышлыклары үлемне җиңә, алланы җиңә! Өч сәгать үтүгә сабыйда яшәү билгеләре төсмерләнә башлый, алты атна дигәндә сабый аңына килеп, күзләрен ача.

Коръәндә егерме сигез пәйгамбәр. Аларның барчасына тукталу мөмкин түгел, хәер, кирәге дә юк. Чөнки югарыда бәян ителгәнчә, бер-берсеннән фәкать маҗаралары белән генә аерылалар. Дин юлындагы хезмәтләре белән исә берсе икенчесенә игезәкләр кебек охшаганнар. Дингә бөтенесе бер рәвештә өнди, кеше аларның бөтенесен бер рәвештә кире

кага, бер рәвештә мәсхәрә итә. Һәркайсы, бер үк сүзләр белән аллага ялварып, кире беткән кяферләрдән коткаруын сорый. Рәхим ит!.. Алла кяферләрнең үзләрен генә түгел, бер гөнаһсыз бала-чагаларын гына да түгел, терлек-туарына, тавык-чебешенә, чәчкән игеннәренә хәтле һәлак итә. Һәлак итә һәм, масаеп диик микән, болай ди:

«Кайсы гына шәһәргә кайсы гына пәйгамбәрне җибәрсәк тә, без анда яшәүче халыкны берәр афәт белән һәлак итә идек...» ди. Һәм, үзенә генә хас бер каһкаһә белән көлеп, болай дип өсти:

«Менә инде хәзер иман китерерләр».

*(Коръән, «Киртәләр» сүрәсе, 92 аять.)*

«Без сиңа кадәр дә төрле халыкларга илче җибәрдек, аннары һәлак иттек», — ди алла һәм тагын каһкаһә белән көлеп, болай дип өсти:

«...Менә хәзер, бәлкем, юашланырлар инде».

*(Коръән, «Хайван» сүрәсе, 42 аять.)*

«Киртәләр» сүрәсенең 192 аятендә үзенең бер пәйгамбәренә хитап итеп (безнеңчә, алардан да шулай ук каһкаһә белән көлеп) болай ди:

«Аларны тугры юлга өндәсәң ни дә өндәмәсәң ни, алар барыбер Сезгә иярәчәк түгел».

*(Коръән, «Ясин» сүрәсе, 8—9 аятьләр.)*

**Өндәсәң ни дә өндәмәсәң** ни. Рус әйтмешли, вот это здорово! Соң, шулай булгач, ул пәйгамбәрләр нигә? Шул хәтле пәйгамбәр нигә? Патшаларга хатыннарының тәннәрен сатып йөрү яки кызларын азгын ирләр алдына чыгарып ташлату өченме? Мәҗүси патшага министр булу, ачлык елны халыкны талатып яткыру өченме?.. Чыннан да, **өндәсәң ни дә өндәмәсәң** ни булгач, нигә ул пәйгамбәр? Алла бу сүзне «Хикәяләр» сүрәсенең 56 аятендә бер пәйгамбәргә тагын да ачыграк итеп әйтә:

«Тугры юлга кертүче син түгел. Тугры юлга син үзең теләгән кешене кертә алмыйсың, алла гына кертә ала...»

Күчерәм, үз күзләремә үзем ышанмыйм. Тагын шул ук сорау: дингә кертә алмагач, ул пәйгамбәрләр нигә? Алла хәтле аллага бу курчак уены нигә?

Алланың үзенә күрә моңар җавабы бар. Ләкин бу җавап шул кадәр кыргый, шул кадәр әшәке, шул кадәр оятсыз һәм беркемнең дә башына килмәгән дәрәҗәдә наив, — аңа динсезләрне түгел, динлеләрне дә ышандыру кыен. Шунлыктан мин аны алланың, дөресрәге, Коръәнне язган кешенең тагын кайбер сыйфатларын ачканнан соң гына фаш итәргә булдым.

Анысы алдагы бүлектә.

*(Дәвамы бар.)*

—·✦·—

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

*Баязит Бикбай*

# КҮҢЕЛ АША ҮТКӘН ЯКТЫЛЫК

Әдәбият дөньясында шундый язучылар була, алар үзләренең иҗаты белән тарихи бер чорның рухын билгелиләр һәм шул чорның тере һәйкәле булып калалар. Пушкин яшендә палачлар кулыннан һәлак ителгән патриот шагыйрь Муса Җәлил шундый язучылар сафына керә. Ул инде татар әдәбиятының гына түгел, бөтенсоюз совет әдәбиятының якты йолдызы булып әверелде. Без, башкорт язучылары да, аның исеме белән горурланабыз, искиткеч рухи батырлыгына сокланабыз.

Муса Җәлилне мин кечкенәдән үк күреп белә идем. Мина 1923 елдан башлап, биш ел буе Оренбургта укырга туры килде. Бу чакта ул шәһәрнең иң актив комсомол оештыручыларыннан берсе һәм танылып килгән шагыйрь иде инде. Артык яшь булганлыктан, әле ул чакта үземне әдәбиятка багышлаячагым турында исемә дә килмәгәнлектән, мин М. Җәлил белән якыннан аралаша алмадым. Шәһәрнең Карл Маркс исемендәге клубында, рабфак, совет-партия мәктәбе сәхнәләреннән шагыйрьнең ясаган ялкынлы чыгышлары яхшы хәтеремдә калган. Ул туры сүзле, үз карашында нык торучан, һәртөрле искелек калдыкларына каршы аяусыз көрәш алып баручы кеше иде. Шәһәр комсомолларының иң яраткан трибуннарының берсе иде ул.

Ул безнең Караван-Сарайга да еш кына килгәли. Үзе кебек яшь шагыйрь һәм якташлары Габдулла Амантай, Сәгыйт Агиш белән бик дуслар. Бездә һәр ял көненә каршы концерт бирелә, я спектакль куела. Кичәдән соң — танцалар. Муса Җәлил һәрбер кичәдә диярлек килми калмый. Муса танцага да бик дәртле егет. Ул биюгә артык оста булмаса да, көлке сүзләр, үз шигырьләре белән авара ясап, иң чибәр кызларны да үзе белән биергә алып чыга иде.

Азак, үзем дә шигырьләр яза башлагач, Җәлилне мин 1931 елның җәендә Туймазыда күрдем. Ул чакта без, язучы Б. Дим (Баянов) белән, районда «Ленин юлы» газетасын оештырып, икенче ел эшләп килә идек. Б. Дим — М. Җәлилгә якын дус кеше. Шул көннәрдә Муса Җәлил күрше Ютазы районының бер колхозына ялга килгән. Аннан Б. Дим хат алды. Җәлил шушы көннәрдә Туймазыга киләчәген белдергән. Көтә башладык. Ниһаять, Муса килде. Бездә Уфадан ике кунак та бар иде. Алар да шагыйрьнең яхшы танышлары икән. Бергәләп күңелле ике көн үткәрдек. Билгеле, нидән генә башласак та безнең сүзләребез әдәбият мәсьәләләренә кайтып кала иде. Мин әле ул чакта беренче китабым да чыкмаган яшь кеше. Шулай да кунакка бернichә язган нәрсәмне укып күрсәттем. Алар Муса Җәлилгә артык тәэсир калдырмадылар, бугай. Әмма Ленин турында язылган:

**— Ленин! Ленин!..**
**Чакырсак та,**
**Сагынсак та кайтмас янадан.**
**Син, большевик булсаң,**
**Ленинсыз да**
**Ленин юлы белән бара ал! —**

дип башланган шигырем аңарга ошады. Бу шигырь шул ук елны Казанда «Авыл яшьләре» журналының беренче тышлык битендә басылып чыкты. Мин аны редакциягә җибәрмәгән идем бит, кайдан алдылар икән? Муса Җәлил «Ленин юлы» газетасының бернichә санын алып киткән иде. Хәзер, газетадан алып, шигырьне «Авыл

яшьләре»нә ул бирмәде микән дигән уй килә.

Коллективлашу кызу барган, кулак калдыкларының каршылыгы бик кискенләшкән чаклар иде бу чор. Авыл Советы председателе Гафуровның кулак калдыклары тарафыннан ерткычларча үтерелүе бөтен районны шаулатты.

— Их, егетләр, менә бит тема! Сез шушы тормышның эчендә үзегез кайныйсыз, уйлап чыгарасы түгел. Шушы фактны гына язганда нинди тетрәткеч әсәр булачак. Языгыз, егетләр, языгыз, — диде Муса, дулкынланып.

Б. Дим прозаик иде. Мин дә бу өлкәдә каләм сынаштыра башлап йөргән чак. Мусаның тәкъдиме безне уятып җибәргән төсле булды. Б. Дим хәрби темалар белән кызыксына иде, озакламый үзе дә армиягә Ерак Көнчыгышка китеп барды. М. Җәлилнең сүзләре һаман минем исемнән чыкмады. Күп уйлап тормый, ашыгыбрак булса да, «Кояшлы көн» исемле повесть яза башладым. Бу әле минем беренче тәҗрибәм иде. Повестьны очлап та бетермичә, беренче кисәген аерым китап итеп чыгардым. Ә азагы, ниндидер сәбәпләр чыгып, язылмаган килеш калды. Бу темага мин фәкать егерме еллардан соң гына яңадан кайттым һәм «Акчеләм ташканда» исемле роман итеп эшләдем.

Шушыннан соң, үкенечкә каршы, Муса Җәлил белән миңа яңадан очрашырга насыйп булмады. Мин аны шигырьләре, соклангыч «Алтынчәч» операсы белән генә якынымда тойдым. Күп тә түгел, бары — ике көн, ә онытылмаслык эз калды. Күктә бер балкып үткән метеор да озак онытылмый бит, ә Муса Җәлил минем күңелем аша якты балкып үтте. Мондый яктылык гомергә онытылмый!

# ИПТӘШ, ДУС ҺӘМ ТУГАН

Танылган татар язучыларыннан һәм шагыйрьләреннән Муса Җәлил, Мансур Крыймов, Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Ерикәй, Шәйхи Маннур, Мәхмүт Максуд һәм башка кайбер иптәшләр 1930 еллар башында Мәскәүдә торып эшлиләр һәм газета-журналларда актив катнашалар иде. Алар арасында иң актив һәм иң эшчәне Муса Җәлил иде дисәк, әллә ни арттыру булмас кебек. Уйлап карагыз, Муса Җәлил бер үк вакытта «Октябрь баласы» журналының җаваплы редакторы, «Ударниклар» журналында редколлегия члены, МАПП-ның татар секциясендә җитәкчеләрнең берсе, өстәвенә, агымдагы күп төрле җәмәгать эше.

1931—1932 елларда мин Мәскәүдә башта «Эшче» газетасы редакциясендә әдәби сотрудник булып, аннары «Ударниклар» журналында секретарь булып эшләдем. Муса Җәлилне көн саен күрә идем. Ә аны күрсәң, сөйләшмичә калып булмый, я берәр киңәш сорыйсың, я инде ул үзе сүз ача. 1931 елның көзендә «Октябрь баласы» журналы редакциясен дә, «Ударниклар»ны да «Молодая гвардия» нәшрияты бинасына күчерделәр. Башта редакция саен берәр бүлмә бирелсә дә, соңыннан, ике журналда да штат зур түгеллеген (икешәр кеше) искә алып, безне бер бүлмәгә утырттылар. Зур бинаның беренче катындагы ике тәрәзәсе дә ишек алдына караган бу бүлмәнең зурлыгы 25 квадрат метр чамасы булгандыр. Ишек нәкъ урта бер урында уелган. «Октябрь баласы» редакциясе бүлмәнең сул ягына, «Ударниклар» — уң якка урнашты. Шулай итеп, мин көн саен берничә сәгать вакытны Муса Җәлил белән кара-каршы утырып үткәрә башладым. Эш көне сигез сәгать булса да, Муса байтак вакытын редакциядән читтә (типографиядә, мәктәпләрдә, ВЛКСМ Үзәк Комитетында) уздыра. Умарта корты төрле чәчәкләрдән бал җыеп кайткан шикелле, Муса Җәлил дә барган җиреннән нинди дә булса материал алып кайта, күп кенә вакыт материалларын безнең белән дә уртаклаша.

— Максуд, минем кабинетка кер әле, — ди Муса. Мин өстәлемне калдырып өч-дүрт атлау белән аның «кабинетына» килеп җитәм. Муса «кабинетында» вакыт әрәм булмый, ул төрле мәсьәләләр кузгата, редакцияләрнең планнарын кат-кат тикшерә, аларга эш барышында кирәкле үзгәртүләр кертеп тора.

«Октябрь баласы» журналы чор сораган мәсьәләләрне эзлекле рәвештә, номердан номерга биреп бара, башлаган нәрсәсен ярты юлда ташламый. Мәсәлән, дингә каршы пропаганда 1931 елда чыккан 12 журналның алтысында бар; язгы чәчү, урып-



М. Җәлил һәм С. Баттал. 1928 ел.

жыюга карата булган материаллар тугыз номерда бирелгән.

Муса Җәлил турында истәлек язучылар да, аның турында сөйләүчеләр дә, «Муса Җәлил бик гади кеше иде», диләр. Бу шулай, әлбәттә. Әмма болай гына әйтү азрак та булыр кебек. Кояшлы көннәр дә төрлечә (я жылы, я эссе, я суык) булган шикелле, гади кешеләр дә бер төрле генә булмыйлар бит. Мусаның гадилеге үзенә хас өстәмә сыйфатлар белән тулыланган иде. Мусаның гадилеген бер генә сүз белән аңлатуы да кыен. Ничек әйтергә соң, Муса гадилеге югары культура белән цементланган гадилек иде ул. Берәү янына барырга икеләнеп торасың, ә икенче кеше сине, магнит тимерне тарткан шикелле, үзенә тартып китерә. Муса әнә шундый иде. Шуның өчен дә «Октябрь баласы» журналы хәбәрчеләргә бай булды, редакция бүлмәсе күп вакытта балалар тавышы белән гөрләп торды.

Журналга килгән күп материаллар арасында төрлесе була иде (ул хәзер дә шулай, билгеле). Кайберәүләр бөтенләй кирәксез мәсьәлә күтәрәләр, кайберләренең грамотасы җитеп бетми... Мондый авторларга, күбесенчә, Муса үзе хат яза, аларга төрле киңәшләр бирә, якында торучыларын редакциягә чакыра, ләкин бер вакытта да язучының хәтере калырлык җавап язмый иде. Редакция секретаре Рабига иптәш Зариповага да:

— Деткорларга хат язганда дәртләндерерлек итеп язарга кирәк, белмәссең, араларыннан Тукай да чыгуы мөмкин, — дип, басым ясап, әйткәне бар Мусаның.

Деткорлардан бик күбесе, редакциягә килеп, Муса абыйларының киңәшләрен тыңлап, ярдәмен алып китәләр иде. Моннан утыз биш ел чамасы элек булган бер картина әледән-әле күз алдына килә. Бүлмә ишеге әкрен генә, аз гына ачыла һәм аннан чәче тузгыган баш күренә. Ул башлап бүлмәне карап чыга, шуннан соң гына:

— Муса абый кирәк иде, — ди.

— Кер, энем, кер, — ди Рабига. Баш иясе, дүрт-биш малай ияртеп, бүлмәгә уза. Озакламый Муса кайтачак. Балалар журналлар карап вакыт уздыралар, тыннары да чыкмый. (Сүз рәтендә әйтеп китим, Муса кая гына китсә дә кайчан кайтачагын әйтеп китә, әйткән вакытында кайта алмаслык булса, телефоннан хәбәр итә иде.)

Муса кайтып керү белән балалар бөтенләй үзгәрделәр, бүлмәдә шау-шу китте. Башта Муса үзе дә аларга кушылып шаулашты, аннары өстәл тирәсенә утыртып әшлекле әңгәмә башлады...

«Октябрь баласы» редакциясенә балалар гына йөрми иде, әлбәттә. Зурлардан Мансур Крыймов, Әхмәт Ерикәй һәм композитор Латыйф Хәмиди еш-рак булалар иде. Журнал битләрендә бу иптәшләрнең байтак әйберләре басылды.

Муса Җәлил журналистика сукмагына аяк баскан бик күп яшьләргә булышты. Минем үземә дә Мусаның ярдәмен татырга туры килде. Мин редакция эшенә хәбәрче-

лектән күтәрелгән кеше, әмма эш буенча бернинди махсус мәктәп тә, курс та үтмәгән идем. 1931 елда КИЖда (Коммунистик Журналистика Институты) Мәскәүдә чыга торган газета-журналларда эшләүчеләр өчен бер еллык кечкә курслар оештырылды. Муса Җәлилнең тәкъдиме буенча бу курсларга мине дә җибәрергә булдылар. Мин башта икеләндем, эшләп уку чиксез авыр булыр шикелле тоелды. Әле ул вакытта эшләп укучылар өчен хәзерге студентларга бирелә торган льготалар юк иде. Көн саен сигез сәгать эш өстенә дүрт сәгать уку җиңел түгел, билгеле. Лекцияләргә әзерләнәсе дә бар бит. Бу шикләнүемә Муса бик кызык чик куйды.

— Мәхмүд абыең эшли-эшли университет бетерде. Муса дигән егет тә университетта уку өчен эшен ташламады, — диде ул. Мусаның шәхси үрнәгенә иярмичә мөмкин түгел иде, мин риза булдым...

Эштән соң редакцияләрдә калырга ярамый иде. Местком членнары көн саен бүлмәләрне карап чыгалар, күзләренә күренсәң, «ял сәгатенә керә» дип, гауга куптаралар. Институтка барырга исә бик иртә була. Эш сәгате беткәч тә, «Ударниклар» редакторы Гәрәй Әхмәтов, «Октябрь баласы»ннан Муса Җәлил һәм Рабига Зарипова чыгып киткәләр, мин, ишекне эчтән биклим дә, дәресләргә хәзерләнәм.

Сирәк-сирәк кенә Муса да редакциядә кала. Мин үзем эндәшмәсәм сүз кушмый, берәр нәрсә сорасам, иренмичә җавап бирә. Шундый кичләрнең берсендә Муса миңа бер кечкенә шигырь укыды. Шигырь миңа ошаган иде, ләкин икенче көнне автор аның бик нык үзгәртелгән вариантын күрсәтте. Мин гаҗәпләнүемне яшерә алмадым:

— Кичәгедән якасы гына калган бит, — дидем. Муса көлемсерәде дә, русчалатып, Маяковскийның түбәндәге юлларын, иҗекләгәндәй ачык итеп, сөйләп бирде.

> **Поэзия ул —**
> **шул ук радий табу.**
> **Бер грамм табыш өчен**
> **бер ел көч куясың.**
> **Бер сүз өчен**
> **актарып ташлыйсың**
> **Меңнәрчә тонна**
> **сүзләр рудасын.**

Муса Җәлилнең үз иҗатына Маяковскийча таләпчән булганлыгын күрсәтә бу эпизод.

Ул елларда Донбасс шахталарында татар эшчеләре күп иде. Муса Җәлил Донбасс белән элемтә урнаштырды һәм барган саен аны киңәйтте, җанландырды. Макеевка шәһәрендәге мәктәп укучылары журнал битләрендә аерата актив катнашалар иде. Донбассның бер округында татар эшчеләре арасында оештыручы булып эшләгән Алфади иптәш белән күмәк тәнкыйть мәкаләсе язуы («Ударниклар» № 4—5, 1932) бу элемтәнең никадәр нык һәм тирән булуын күрсәтә.

Муса Җәлилнең шәхси тормышына бәйләнгән кайбер нәрсәләр хәтеремдә саклана. 1931—1932 еллар кышында, бер ял көнендә базарга чыгып, тормыш иптәшемә фитр итек алган идем. Ул итек кечерәк булып чыкты. Икенче көнне эш арасында бу турыда зарланып алдым, «алуы бер хәл иде, ничек базарда итек сатып йөрисең», дим. Мусаның сеңелесенә итек бик кирәк икән, икенче көнне үк алып килдем. Иртәгесен эшкә килгәч Муса:

— Хәдичәдән дә, миннән дә рәхмәт, итек аның аягына үлчәнеп эшләнгән шикелле, — диде. Шулай итеп, мин базарга итек сатарга чыгудан котылдым, ә Муса сеңелесе Хәдичәнең аягы җылынды.

Казанга кайткач, 1938 елда (ае-көне хәтеремдә түгел) Муса Җәлил безнең Бишбалтадагы квартирага килеп байтак утырды. Өч яшьлек кызыбыз идәндә уйнап йөри, берничә айлык улыбыз бишектә ята. Кызыбыз Мусага бик тиз ияләнде. Ияләнмәслек тә түгел, әллә нинди кызыклы әйберләр сөйли, мандолинада матур итеп уйный. Шул арада үзенең кызчыгы Чулпан турында сүз кыстыра. Мусаның Чулпанны ничек тирән яратканлыгы аның шигырьләреннән, хатларыннан барыбызга да билгеле. Ә түбәндәге юллар беренче кат биреләләр шикелле. Муса бездән китәргә җыена башлады һәм, куен кесәсеннән кызының рәсемен алып, аның артына миңа һәм иптәшемә атап, берничә юл язгач, шушы шигырь не өстәде:

> **Миңа инде сигез ай,**
> **Күзем ялкын, йөзем ай,**
> **Мин — Муса Җәлил кызы,**
> **Якты Чулпан йолдызы.**

Бу кыйммәтле истәлекне мин соңыннан Мусаның тормыш иптәше Әминә ханымга тапшырдым.

Муса Җәлил чын мәгънәсе белән иптәш, дус һәм туган иде. Аны югалту барыбыз өчен дә авыр булды, әмма аның искиткеч зур мирасы халыкларга хезмәтен дәвам иттерә, Мусаның үлемсезлеге турында сөйли. Шунысы безне шатландыра.

**Х. МАКСУД.**

# ЯКТАШЫМ

1919 елның көзе иде. Оренбург шәһәренең элекке «Хөсәения» мәдрәсәсе бинасында Халык мәгарифе институты ачыла. Бәләбәй, Богрыслан якларыннан, Урал һәм Сакмар су буйларыннан менә шул институтка укырга дип килгән чабаталы крестьян малайлары арасында мин дә бар идем. Институтның югары курсларында революция дулкыны белән азатлык көрәше юлына баскан «Хөсәения»нең элекке шәкертләре укый, ә безнең кебек 4—5 класслы авыл мәктәбен бетергәннәр өчен әзерлек класслары ачылган иде. Шәһәрдә әле күптән түгел булып үткән гражданнар сугышы эзләре ярылып ята. Якын-тирәдә генә Кызыл Армия Дутов гаскәрләре калдыкларына һәм башка контрреволюцион көчләргә каршы канлы көрәш алып бара. Шуның өстәвенә, шәһәрдә һәм өяздә башланган рәхимсез тиф авыруы һәм ачлык халыкны бугаздан ала башлаган. Муса Җәлил белән миңа менә шушындый шартларда таныш булырга туры килде. Муса институтка үзенең электән таныш иптәшләре янына килеп йөри иде. Ул күбрәк вакытын, институтның озын коридоры буйлап йөри-йөри, иптәшләре белән ниндидер мавыктыргыч әңгәмә яки күңелле бәхәстә уздыра. Үзенә караганда яшькә күп мәртәбәләр олы булган кешеләрнең бу 13 яшьлек Мусаны шулай игътибар белән тыңлауларына һәм ихтирам итүләренә без, аның тиңдәшләре, кызыга идек, хәтта малайларча көнләшә дә идек. Муса һәрвакыт кара калын сукнодан «толстовка» фасонында тегелгән гимнастеркадан була иде. Гимнастеркадан ак күлмәк якасы күренеп торыр.

Ул бервакытта да, хәтта зур төркем иптәшләре арасында да, кычкырып сөйләшмәс. Аның йомшак тавышы һәм елмаю катыш ягымлы сүзләре тыңлаучыларны үзенә җәлеп итә. «Р» авазын сакаулабрак әйтүе дә сөйләменә ниндидер ягымлылык бирә кебек. Җитди мәсьәләләр турында оста һәм акыллы әңгәмә алып баручы булуы белән бергә, ул уен-көлке дә яратучан, юморга бай кеше иде. Ул еш кына институтта булган кичәләрдә сәхнәгә чыгып үзенең шигырьләрен укый, мандолинада уйнау белән катнаша иде. Аның «Кара песи» дигән шигырен берничә мәртәбәләр сәхнәгә чыгып үзенә генә хас юмор белән башкаруы бүгенгедәй күз алдымда.

Ул елларда кытыршы, сары кәгазьгә басылган «Кызыл йолдыз» газетасын институтка алып килеп, бушлай тараталар иде. Газетада Муса шигырьләре дә очрый иде.

Муса минем якташым. Оренбург — Урал олы юлы өстендә утырган Мостафа авылы безгә — Җәгъфәр авылына 50—60 чакрым гына. Юл пычрак чакларда, безнең авыллар Оренбургка Мостафа аша йөриләр иде. Үз гомеремдә бер мәртәбә шул олы юлдан үтәргә туры килде миңа һәм шул чак мин Мусаның туган авылы Мостафаны һәм аның туган йортын күрү бәхетенә ирештем. Бу 1926 елның җәендә булды. Казанда Татар Коммунистлар Университетында (ТКУ да) укыган чагым. Икенче курсны бетергәч, каникулга туган якларга кайтырга булдым. Минем бәхеткә каршы, Мостафа авылы аша кайтучы атлы кеше дә очрады.

Авыл урамына керү белән беренче күренгән кешедән Муса Җәлилнең йортын сорадым. Урамны ике яклап, купчелегенең түбәләре салам ябылган, гади крестьян йортлары тезелеп киткән. Менә без сораган йорт: тәбәнәк кенә нигезгә салынган, ике тәрәзәсе урам якка, берсе йорт якка караган, әзрәк артка таба чүккән. Киртәләрдән генә корылган койма һәм җил капка аша йорт эче күренеп тора. Без капка төбенә килеп туктау белән, ишек алдына уртача буйлы, таза гәүдәле, карарак чырайлы, мөлаем йөзле 40—45 яшьләрдәге бер хатын килеп чыкты. Бу Мусаның әнисе иде.

— Муса минем таныш иптәшем, мин аны Оренбургта чакта беләдер идем, — диюгә хуҗа хатынның йөзе тагы да яктыра төште. «Кунак икәнсез, бик әйбәт, өйгә рәхим итегез» дип, үзе тиз генә өй алдына кереп китте. Без олаучы белән атны тугарып өйгә кергәндә анда самовар гөжләп утыра иде инде. Чәй янында без Муса турында, тормыш-көнкүреш турында сөйләшеп киттек. Алар миңа Мусаның байтак вакыт Оренбургта комсомол эшендә эшләве турында сөйләделәр һәм хәзер аның Мәскәүдә икәнен әйттеләр. Мусаның үзен күрә алмавым мине борчылдырса да, аның гаиләсе белән булган бу күңелле очрашу миндә зур канәгатьләнү тудырды һәм мәңге онытылмаслык бер истәлек булып күңелемдә саклана.

**ХӘБИБ САЛИХОВ,**
ТАССР культура министрлыгы инструкторы.

# КӨРӘШТӘШЛӘР

*Бәлки, минә шушы үлем безгә*
*Мәңге бетмәс яшәү китерер?*

*М. ЖӘЛИЛ.*

«Мөстафад-эль-әхбар» исемле хезмәтенең 228—29 битләрендә күренекле галим Ш. Мәржани Алишевлар нәселенең тарихы турында яза. Хезмәттән күренгәнчә, Алишевлар буыны XVI гасырның икенче яртысында яшәгән Галишаһ (соңыннан Галиша — Галиш-Алиш булып киткән) исемле кешедән башлана. 9 бабадан килгән фамилия халык бәхете өчен көрәшүче берничә күренекле кеше биргән. Шулардан безгә якынрак чорда яшәгәннәре дүртәү. Киев шәһәрен ак поляклардан азат итү сугышларында катнашкан «тимер батальон»ның комиссары Хатип Алишев. 1920 елның көзендә һәлак булган. Шул ук шаулы, давыллы елларда дошман пулясыннан тагын бер Алишев егыла — Кульбай Мораса авылында партия ячейкасы секретаре, авылның беренче коммунисты Габделхәй Алишев үтерелә.

Туган илебезне фашист басып алучылардан арчу өчен барган дәһшәтле сугыш кырларында Исхак Алишев ятып кала. Ниһаять, күренекле балалар язучысы, Муса Җәлилнең якын дусты һәм көрәштәше Абдулла Алишев. Абдулла Алишның иҗаты, ул калдырган бай әдәби мирас турында да, аның немец тоткынлыгындагы тормышы һәм көрәше турында да безнең матбугатта азмыкүпме язылды инде. Билгеле әйберләрне кабатлап тормастан, мин биредә А. Алишның бала чагы, аның кешелек сыйфатлары турында гына берничә сүз әйтмәкче булам.

Абдулла Алишның балалык еллары Татарстанның Куйбышев районы Көек авылында үтә. Беренче бөтендөнья сугышы башланганда Абдулла әле 6 яшьлек малай гына була. Ул, башка малайлар белән, урамда «немеч»кә каршы сугышып йөри, һәр нәрсәне күзәтүчән, үткен күзле, нечкә тойгылы малай киң болыннарда, кырларда сәяхәт итә, тирән сулы көмеш елгаларда коена. Әтисе Габделбарый абзыйдан малайга да бик яшьләй уку һәвәскәрлеге, китап ярату тойгысы күчә. Ул үзенең иптәш малайларына төрле хикәя, әкият, шигырь китаплары, авыл хатыннарына солдатлардан килгән хатларны укый торган була.

Абдулла Алиш 11 яшеннән крестьян эшенә җигелә: җир сукалый, тырмалый, хайваннар карый. Әмма, тормыш авыр булуга карамастан, укуын ташламый. Әтисе дә аны ничек тә укытырга тырыша. Шуларны кичереп үскәнлектән, Берлин төрмәсеннән туганнарына язган хатында ул үзе дә балаларымны «укытырга тырышыгыз», ди.

А. Алиш кече яшьтән иҗат эшенә хирыслык күрсәтә. Башлангыч мәктәптә укыганда ук үзен бәетләр әйтергә, әкият сөйләргә һәвәс укучы итеп таныта. Авылда берәр кызыклы хәл булса, я кырын эш килеп чыкса, бу турыда Абдулла шунда ук шигырь чыгара иде, дип сөйлиләр.

Көек авылында берничә байның һәм мулланың сепараторы булган. Һәрберсе үзенә күбрәк сөт аертучылар тарту өчен тырышкан. Шул җирлектә алар арасында еш кына тавыш-гауга, төрле низагълар чыга торган була. Кечкенә Абдулланың әлеге бай һәм муллалардан көлеп язылган шигыре бөтен авылга тарала.

Кечкенә Алиш кош-кортларны һәм хайваннарны, төрле бөҗәкләрне ярата. Аларның берничә баш умарталары була. Күп вакытын ул шул умарталар янында, шуларны күзәтеп уздыра. Шулай бер вакыт, нәрсә аркасындадыр, аларның бер чебиләре авырып китә. Аны тәмам терелткәнче, Абдулла чеби яныннан китми. Ат саклау, көтү каршы алу Абдулланың бик теләп һәм яратып башкара торган эшләреннән санала.

Булачак язучыга хас сыйфатларның тагын берсе — аның балалар яратуы. Спасскийда һәм соңрак Казанда җир төзелеше техникумында укыганда Абдулла җәйге ялга туган авылы Көеккә һәм Салман, Алпар, Әлки авылларына кайтып йөри. Аның авылга кайтуы балалар өчен чын бәйрәмгә әйләнә иде, дип сөйли Илсөяр Сункишева. Ул балаларны бик тиз кызыксындыра һәм юата белгән, аларга кызыклы әкиятләр сөйләгән. Эшли башлагач, кардәшләренең балаларына һәр уку елына уку кирәкяраклары, китаплар алып бирә, «Яшь ленинчы» газетасы һәм «Пионер каләме» журналлары яздырып җибәрә торган була.

Меңләгән укучыларның һәм аны якыннан күреп белгән танышларының хәтерендә күренекле балалар язучысы, патриот шагыйрь Абдулла Алиш әнә шундый бик гади һәм ягымлы кеше булып саклана.

**С. АЛИШЕВ.**

## Совет властеның 50 еллыгына

*Ибраһим Дәүләтшин*

# ИДЕЛ ӨСТЕНДӘ ТАҢ

*Очерк*

## I

1917 елның мае. Иделнең уңъяк ярына таралып утырган Тәтеш шәһәре өстендә кичке караңгылык куерып килә иде. Шау чәчәккә төренгән зур-зур бакчалардан урамнарга, тәрәзәләре ачып куелган өйләргә шомырт, алмагач чәчәкләреннең хуш исе агыла. Текә ярлары арасында тыныч кына сулап яткан чал Иделдән кичке дымлы һава күтәрелә.

Ләкин кеше күңелен табигать тудырган рәхәтлекләр генә канәгатьләндерә алмый шул. Аның йөрәге нинди дер башка хисләр белән тулган була.

Менә Фуражковлар өе. Алар гаиләсендә бүген үзенә күрә тантана: гаилә башлыгы Дмитрий Флегонтович Фуражковның солдаттан кайтуы хөрмәтенә мәҗлес бара.

Мәҗлестәгеләр йотлыгып йорт хуҗасы Дмитрий Флегонтовичның сөйләгәнен тыңлыйлар:

— Безгә буржуйлардан мәрхәмәт көтеп ятасы түгел,— ди ул, тыныч кына. — Монда сөйләгән монда калсын, менә мин сезгә үземнең серемне ачам.

Әнә әни шаһит, мин шушы 34 еллык гомеремдә күпне күрдем... Үзебезнең өязнең суд следователендә секретарь булып эшли идем... Тәтеш купецларының, кулакларның махинацияләрен, әшәкелекләрен «гадел хөкем»нең ничек яшереп килүен үз күзләрем белән күреп яшим. Көннәрдән бер көнне әйтеп ташладым бит следовательгә: «Хам сез!» — дидем. Әйтүем булды, икенче көнне эштән куып чыгардылар. Шуннан кайткач, әти мәрхүм янына чакырып алды да әйтте: «Болар синең, Митя, барыбер көн бирмәсләр, кит син моннан»,— диде. Киттем. Бакуга барып чыктым. 1905 ел иде бу. Баку гөж килә. Эшчеләр восстание күтәргәннәр. Кемнәргәдер ияреп, мин дә кушылып киттем восстаниечеләргә. Буржуйларга Тәтештә үк ачуым кузгалган иде инде. Бакудагы хәлләрне дә күргәч, ярсуым чигенә җитте. Тик шунысы үкенечле — революция булды, әмма власть барыбер капиталистлар кулында калды. Өстәвенә, буржуазия халыктан үч ала башлады. Моны әни дә үзем генә беләм: миңа да эзәрлекләүдән байтак качып йөрергә туры килде. Әйт-

сәм-әйтим инде, менә әле бу юлы да мин... Монда барысы да үзебезнең кешеләр... Мине сез солдаттан кайтты дип уйладыгыз инде, шулай бит?

— Солдаттан булмыйча? — диде хатыны, гаҗәпләнеп.

— Төрмәдән кайттым мин.

— Төрмәдән?!

— Дөресме, абый?

— Нишләп эләктең, күрше?

— Болай булды. Сембер гарнизонында хезмәт итеп ятабыз. Ишеткәнсездер, былтыр көзге якта солдатлар арасында чуалышлар көчәйде бит. Шуннан эзләү-эзәрлекләүләр китте. Минем дә эзгә төштеләр шакаллар. Сугышка каршы, патшага каршы котыртуда гаепләделәр. Шуннан — таш капчыкка. Менә шул. Быел февраль ахырында гына ычкына алдым.

Мәҗлестәгеләр шикләнешеп бер-берсенә караштылар. Бу сүзләрдән соң мәҗлес тә ничектер үзеннән-үзе сүрелде. Фуражковның якын дусты Блинниковтан калганнары, хуҗалар белән саубуллашып, өйләренә кайтып киттеләр. Хуҗа хатын балалары янына йокларга ятты. Блинников белән Фуражков, лампаның утын батыра төшеп, мич буена идәнгә чүгәләделәр.

— Я, Тәтеш ни хәлдә? — диде Фуражков, сак кына тавыш белән, һәм Блинниковка сораулы караш ташлады. Блинников дәшмәде. Аның бер-берсенә тоташа язган куе, кара кашлары җыерылып куйды, калын иреннәре кыймылдап алды, күзләре киңрәк ачылды һәм эре сөякле йөзенә яшь егетләргә хас булмаган бер җитдилек билгесе йөгерде.

— Ник дәшмисең, әллә ышанмыйсыңмы миңа?

— Ышанам, Дмитрий Флегонтович...

— Курыкма, туган. Озакламый без җиңәчәкбез. Ишетмәдеңмени, Ленин кайткан бит, моннан 3—4 атна элек кенә әле. Вокзалга үзен каршыларга килгән Петроград эшчеләре алдында чыгыш ясаган. Бөтен власть Советларга күчәргә тиеш, дигән.

— Шул-а-аймыни?!

— Әйе. Ә безнең Тәтештә эшләр кая табанрак тәгәри соң?

— Колсанов кебекләр, акчаларын-алтыннарын җыйнап, каядыр шылдылар. Ә туган-тумачалары монда әле. Элеккечә үк типтереп яшиләр.

## II

Июнь киче. Офык читендә карачкыл болытлар белән аралашкан алсу пәрдә пәйда булды. Табигатьнең бу күренеше иртәгә көннең аяз булмаячагын искәртә иде. Алдан сөйләшкәнчә, Василий Рыжковлар өенә башта Фуражков, бераз соңрак Блинников килеп керде. Василий аларның һәр икесен Урюм авылыннан кайткан Карасев белән таныштырды.

Дмитрий Дмитриевич Карасев 35 яшьләр чамасындагы урта буйлы кеше; өстендә кара төстәге арзан бәяле костюм, ап-ак күлмәк, ландыш сурәте төшерелгән галстук; йөзе түгәрәк, сакал-мыек такыр итеп кырылган, салмак хәрәкәтләнүчән соры күзләр, киң ачык маңгай...

Рыжковлар семьясында Василийдан кала тагын 11 бала булуга карамастан, бүген кич аларның берсе дә күзгә-башка чалынмады. Тик буйга җиткән бер кызлары гына кухняда әнисенә булышып йөрде. Өстәлгә аш-чәй китереп куйгач, тәрәзә пәрдәләрен төшереп, Василий да килеп утырды.

— Дмитрий Дмитриевич, каенэнегез сезгә обстановканы аңлаткандыр инде, — дип, сак кына тавыш белән сүз башлады Фуражков.

— Аңлатты, — диде Карасев, үзенә генә хас бер йомшак тавыш белән.

— Тирә-як авылларда элемтәгә керердәй ышанычлы кешеләрегез бармы? — дип әңгәмәгә кушылды Блинников.

— Бар, — диде Карасев. — Пролей Кашида Шепелин, Большаков, Курковлар, Килдештә Яков Левштанов, Александр Токин белән элемтә тотабыз. Шушы иптәшләр аркылы бу авыллардагы чуваш, мордва, рус крестьяннарына илдәге моментны аңлатырга тырышабыз.

— Тик бик күп нәрсә үзебезгә дә ачык түгел шул әле, — диде Василий. — Политик әдәбиятны кулга төшерүе кыен.

— Менә миндә бер документ бар, иптәшләр, — диде Блинников һәм күкрәк кесәсеннән тәмәке кәгазе кебек итеп бөкләнгән «Рабочий» газетасын тартып чыгарды. Таушалып, каралып беткән бу газетаның бер өлешенә «Казан большевиклары органы» дигән сүзләр язылган иде.

Өстәл тирәсендәгеләр тынып калдылар. Барысының да күзләре газетага төбәлде. Блинников, асылмалы лампага якынрак шуышып, РСДРП Казан шәһәр оешмасының II конференциясе турындагы корреспонденцияне укыды:

«Сугыш аркасында килеп туган хәзерге экономик һәм политик тирәлештән, — диелгән иде бу хәбәрдә, — Россияне бары тик бөтен властьның эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Советы кулына күчүе генә чыгара ала». Газета авыл ярлыларын крестьян комитетлары төзәргә, шул комитетлар ярдәмендә, Учредительный собрание чакырылуын көтмәстән һәм властьларның каршылык күрсәтүләренә карамастан, алпавытларның җирләрен тартып алырга чакыра иде.

— Бусы әйбәт булды. Менә моны да укы әле, — диде Рыжков, газетадагы кыска бер хәбәргә төбәлеп. Блинников укый башлады:

«5 июньдә Алафузовлар предприятиеләрендә башланган забастовкалар эшчеләрнең җиңүе белән тәмамланды... Эш хакын 50 процентка арттыруга, сугыш барган вакытлар өчен тагын 10 процент өстәмә түләү алуга ирештеләр».

— Здорово! — дип кычкырып җибәрде Рыжков, юан-юан тамырлары бүртеп чыккан иләмсез зур йодрыгы белән өстәл читенә сугып. — Безнең купецларны да...

Фуражков тынычрак булырга киңәш бирде:

— Тсс, кызма, егет. Көчеңне сакла, кирәк булыр әле. Ярый, иптәшләр, мәсьәләгә якынрак килик... Безгә, иптәшләр, татарлар арасыннан да ышанычлы кешеләр табарга кирәк.

— Мин Яруллага сүз катып карадым. Риза булыр төсле, — диде Блинников. — Аның аркылы тагын берничәне табарбыз.

— Ярый, — диде Фуражков, ризалыгын белдереп. — Ә яшьләрдән кемнәрне әзерли алырбыз?

— Семинариядә, гимназиядә укучылар арасында бик шәп егетләр бар, — диде Василий. — Кузьмин Михаилга шикләнмичә эш йөкләргә була. Милләте буенча чуваш. Бик төпле егет. Патшага каршы язган шигырьләре дә бар. Тагын Павел Бекшанскийны тәкъдим итә алам. Михаилның сердәше, бик кыю, фикерен ачык итеп әйтеп бирә ала, оештыру сәләте бар. Михаил Куприянов та безгә файдалы кеше булачак. Ул — менә дигән художник. Ибраһим Батыршинны да һич шикләнми тартырга була.

— Яхшы, — диде Фуражков һәм урыныннан торды, — сөйләшәсе сүз сөйләнеп бетте шикелле. Эшкә, иптәшләр! Ләкин сак булыгыз, дошман яңадан котырына...

### III

Василий Блинников, үзе белән Рыжковның сөйгән кызы Җиһанны, грузчик Яруллланы ияртеп, татарлар яши торган яр буе урамындагы мәчеткә таба юл тотты. Алар барып җиткәндә, картлар, җомга намазын укып, мәчет янындагы чирәмгә чыгып утырганнар. Араларында урта

яшьтәге ирләр дә юк түгел, егетләр дә бар. Барысының да карашлары башына ап-ак чалма ураган түгәрәк кара сакаллы Габдулла муллага юнәлгән. Мулла исә, күзләрен әле яшел мәчет манарасына юнәлдереп, әле алдындагы чирәмгә текәп, тавышын үзенә бертөрле көйгә салып, вәгазь сөйли.

Ярулла, башындагы кепкасын алдын артка әйләндереп киде дә, халык арасына кереп чүгәләде; башкаларның кәефенә яраклашу өчен моңсу бер кыяфәткә кереп, күзләрен йома төшеп, оеды. Җиһан белән Блинников, мәчет почмагына яшеренеп, күзәтеләр, тыңладылар.

— Җәмәгать, күңеленә февраль шаукымнары вәсвәсә салган әдәмнәр бу зәхмәттән тизрәк арыну гамәлен кылырга ашыксыннар. Власть алыштырабыз, фәлән-фәсмәттән итәбез дип котырынып йөрүчеләргә мин теге вакытта ук әйтә килдем, урысларга карап акылыгыздан ваз кичмәгез, дидем. Тыңламадылар. Менә хәзер ходаның ачы каһәре төште үзләренә. Ишеткәнсездер, Питрдә дә, Мәскәүдә дә изге хөкүмәтебез Совет дигән афәтнең тамырын корыткан. Аллаһы тәгаләнең әмере кабул булды. Дога кылыйк, мөселманнар. Аллаһы әкбәр...

Картлар киң итеп җәелгән куллары белән битләрен сыпырып алганнан соң, Ярулла картларча итеп тамак кыра-кыра муллага эндәште:

— Мин яшь кеше, хәзрәт, алай-болай ялгыш сүз ычкындырсам, гаепкә ала күрмәгез. Бу дөньяда минем өчен сездән дә олуг, сездән дә галим кеше юктыр.

— Дөрес әйтәсең, фаразан, бик дөрес. Я, сөалеңне бир.

— Менә минем кибәк баш һич кенә дә шуны төшенә алмый: урыс кешесен безнең динебез мөселманның дин дошманы дип атый. Хаталансам, хәзрәт абзый, зинһар, төзәтә күр.

— Хаталанмыйсың, кем Ярулла, бик дөрес аңлыйсың.

— Соң урыс мөселманның дошманы булгач, ни өчен кайбер тәти татарларыбыз, урыс белән бер сүзле булып, татарны бушка эшләтәләр, ат урынына җигәләр?

— Аңламыйм, кем Ярулла, аңламыйм. Ачыграк сөйлә.

— Ачыгракмы?! — диде Ярулла, кинәт тавышын калынайтып, һәм кепкасын алды белән әйләндереп киде. — Ачыграк әйтергә дисеңме, хәзрәт?! Әйтәм: менә син безне урысларга каршы котыртасың, ә үзең урыс Колсаны белән бергә хәмер эчәсең!

— Эх, имансыз, денеңнән язган нәрсә! — дип чинады мулла. — Тотып кисегез үзен!

Халык шаулаша башлады. Кемнәрдер йодрыкларын төеп Ярулла өстенә ташландылар. Шул чак мәчет почмагыннан Җиһан атылып чыкты да:

— Разбой, көпә-көндез кеше үтерәләр! — дип, нәзек тавыш белән кычкырып җибәрде. — Мулла абзый нәрсә карап торасың, мәчет ишеге алдында шулай кеше җәберләтү шәригатькә сыя торган эшмени?!

Көтмәгәндә ишетелгән хәвефле хатын-кыз тавышы халыкны сискәндереп җибәрде. Мулла үзе дә хатын-кыз заты алдында бу тамашаны дәвам иттерүне мәгъкуль күрмәде. Халык таралышты. Блинников, яшеренгән җиреннән чыгып, тегеләр янына килде дә:

— Молодец, Ярулла! — диде. — Җиһан син дә.

— Ничек алай дип әйтә аласың, син татарча белмисең ич,— диде Ярулла, кәвеш эзеннән кызарып калган битен сыйпый-сыйпый.

— Ә мин синең мулла белән сөйләшүеңне аңа тәрҗемә итеп бардым, — диде Җиһан.

Блинников, саубуллашып, пристаньга төшеп китте. Җиһан өйләренә кереп калды. Ярулла, өе ягына борылган иде дә, бу ниятеннән шундук кире кайтып, пристаньга — үзенең грузчик дуслары янына юл тотты.

## IV

Фуражков көндез пар тегермәнендә булып, андагы ышанычлы бер-ничә эшчегә Алафузовлар фабрикасындагы хәлләрне аңлатты. Кичке якта купец Колсановның Тәтеш белән Людоговка авылы арасындагы амбарына юнәлде. 15 ләп эшче, бүгенгә җитеп торыр дигәндәй, амбар чистартуны туктатып, тәмәке көйрәтеп утыралар иде. Фуражков та чигүле янчыгыннан алып тәмәке төрде һәм тегеләр янына килеп утырды.

— Яңа уңыш ашлыгы салырга урын әзерләп ятумы? — дип сүз баш-лады ул.

— Шулай дигән булабыз, үзебезгә калса,— дип, кырыс кына җавап кайтарды кысык күзле бер ир.

— Шуңа ашыгабыз әле менә, озакламый Колсанов үзе кайтып җи-тәчәк диләр бит,— дип, иренеп кенә әйтеп куйды сары мыеклы агай.

— Туктагыз әле, агай-эне, мин фотокарточкалар алып килгән идем,— дип, Фуражков кесәсенә тыгылды. (Ул фотография белән дә шөгыльләнә иде.) — Үзегез килеп ала белмисез, ә минем өегезгә илтеп бирергә вакытым юк.

Кысык күз каядыр китеп барды.

— Алдыңнан артың матур, — дип көлеп калдылар иптәшләре.

— Я, Дмитрий Флегонтович, бүген нинди яңа хәбәрләр алып кил-дең? — диде сары мыек һәм Фуражковның янына ук килеп утырды. Башкалар да елыштылар.

— Яңалык шул, иптәшләр, эсәрлар, меньшевиклар властьны бөтен-ләе белән яңадан буржуазия кулына тапшырдылар.

— Соң болай булгач, слободаны төштә генә күрергә калдымы инде?

— Көтмә инде аны хәзер.

— Әйтәм, Колсанныкылар бик әтәчләнеп йөри башладылар.

— Ну, борыннарына сугып булмады сволочьларның.

Фуражков, кем нәрсә уйлый шуны әйтә бирсен диптер ахры, дәшми-чә утырды. Аннары, тегеләр тынып калгач, әйтте:

— Төшенкелеккә бирелмәгез, иптәшләр. Революция җиңәчәк. Ихти-мал, каты бәрелеш булыр, кан түгәргә туры килер. Әмма без җиңәчәк-без.

— Син, Дмитрий Флегонтович, бик тә ышанычлы итеп сөйлисең инде.

— Мин, иптәшләр, Ленинга ышанам, партиягә ышанам, пролета-риатка ышанам.

Сөйләшү тәмамлангач та Фуражков кайтырга чыкты. Төн. Шәһәр ягыннан эт өргән тавышлар ишетелә. Күпергә җитәрәк, күл буендагы каберлектән бер кеше йөгереп чыкты.

— Минем синең белән аңлашасым бар,— диде ул, теш арасыннан гына, Фуражковның юлына аркылы төшеп.

— Әйдә, аңлашыйк, Михаил Полусохин, — дип сабыр гына җавап кайтарды Фуражков. Шулай диюе булды, купец малае бөтен көче белән аның яңагына сугып җибәрде. Фуражковның борыныннан кан китте, гәүдәсе чайкалып куйды. Ул, кычкырмый-бакырмый, һаман артка чиген-де. Ә артта — текә ярлы күл. Чигенде дә, кинәт туктап, тегенең ар-тына төште.

— Менә хәзер аңлашырга була! — диде Дмитрий Флегонтович һәм киерелеп торып дошманының аяк астына кундырды. Егет мәтәлчекләп китте һәм акыра-бакыра, күлгә тәгәрәп төште. Аның үкергән тавышына каберлек ягыннан тагын 2 кеше йөгереп чыкты. Берсенең кулында юан күсәк булуын күреп, Фуражков эшнең кая таба барганлыгын аңлап алды. Бердән-бер чара качу иде. Ул арада, шабыр суга манчылып, ку-пец малае да ярдан менеп килә иде.

Фуражков тимерче алачыклары ягыннан күпергә табан йөгерүче ке-шене күреп алды.

— Вася! — дип кычкырды ул, аны йөрешеннән үк танып.

Рыжковның килеп чыгуы булды, тегеләр өчесе өч якка качтылар.

— Җиңү безнең якта! — диде Рыжков, сызганган җиңнәрен төшерә-төшерә.

— Әйе, Вася, бусы да ярап тора хәзергә. Әмма сугышның зурысы алда әле, брат.

## V

Бөек Октябрь революциясенең җиңүле ташкыны, үз юлында зур каршылыкларга, тоткарлыкларга очрый-очрый, Россиянең ерак почмакларына җәелде.

Тәтеш буржуазиясе үзенең тамырларын саклап калу өчен ярсып каршылык күрсәтте. Купецларның, байларның байлыкларын тартып алгач, аларны контрибуция түләргә мәҗбүр иткәч, власть башына халыкның үз вәкилләрен куя башлагач, сыйнфый көрәш тагын да кискенләшә төште.

Фуражков — нардом мөдире, Рыжков шәһәр Советы аппаратында, Блинников ревкомда эшлиләр. Халык өчесен дә беренче чакырылыш шәһәр Советының депутатлары итеп сайлаган. Армиядән демобилизацияләнгән матрослар Иван Трузгин, Николай Линьковлар белән кулгакул тотынып, Рыжковлар Советка каршы элементларны авызлыклыйлар, шәһәрдә һәм авылларда яңа тәртипләр урнаштырып йөриләр.

1918 елның марты. Кич. Килдеш авылы ярлылары Яков Левштанов өенә җыелдылар. Бу эшне оештыручы Александр Токин — үткен карашлы, киң битле мордвалы, — идәнгә утырган крестьяннарга карап, сүз башлады:

— Авылдашларым, ниһаять, Тәтештә безнекеләр властьны тулысынча үз кулларына алдылар. Без дә сезнең белән авылыбызда Совет власте урнаштырдык. Хәзер эш үзебездән тора инде. Әйдәгез, сөйләшиккиңәшик, туганнар.

— Әнә, Урюмда җирне артель булып сөрергә карар кылганнар икән, әллә без дә шулай эшлибезме, җәмәгать? — дип сүзгә кушылды өй хуҗасы Яков.

— Чыннан да, мужиклар, бергәләп эшләү мәслихәт булыр төсле, — дип куәтләде тула оеклы аягына өр-яңа чабата сарган Петр Калашников. — Ник дисәң, бер ишебезнең аты юк, аты булса, сабанының төрәне сынган...

Ишек алдында аяк тавышлары ишетелде. Ул арада булмады, урам як тәрәзәдән, пыяланы чәлпәрәмә китереп, өй эченә ярты кирпеч очып керде. Өйдәгеләр, шомланып, сикереп тордылар. Тышкы яктан ишекне каерып, өйгә сүгенә-сүгенә бер төркем ирләр ыргылды. Кулларында балталар, сәнәкләр, тагын нәрсәләрдер... Атаман-кулак Никита Кочнев, наганын Токинга якын ук итеп төзәде дә, ямьсез тавыш белән акырды:

— Сиңа Совет власте кирәкме? Менә ал!

Пуля Токинның маңгаена тиде. Кулакларның икенчесе лампаны сугып төшерде. Караңгылыктан файдаланып, крестьяннарның да берничәсе чыгып качарга өлгерде. Кочнев йөгереп тышка чыкты. Аның артыннан бүтәннәр дә иярде. Кайсыдыр ишекне тыштан бикләде. Кочнев ватык тәрәзә янына килде һәм эчкә граната ташлады. Өйдә гөрселдәп шартлаган тавыш ишетелде. Шул мизгелдә кемнәрнеңдер үкереп сүгенүләре, ыңгырашулары ишетелеп калды.

Бу канлы вакыйганың иртәгесен үк Килдешкә Тәтештән Семен Кузин командалыгындагы 60 кешелек кызыл гвардия отряды килеп төште. Кыр капка төбенә житкәч, берәү отрядка каршы чыгып:

— Туктагыз! Сез кемнәр? — дип кычкырды.

— Күтәр кулларыңны! Ташла коралыңны! — дип әмер бирде Кузин.

Сакчы башкача каршылык күрсәтмәде. Отряд, халык ишарәсе буенча, шикле кешеләрне кулга алды. Кызыллар штабы Токиннар күршесенә урнашты. Шикле кешеләрне шунда алып килделәр. Командир тегеләрдән сораштыра башлады. Арттарак, ишек төбендәрәк басып торучы ике кеше, бер-берсенә күз кысыштылар да, тәмәке тарту сылтавы белән ишек алдына чыктылар. Кузин боларны күреп калды һәм, колагын ишеккә куеп, тыңлый башлады. Тышкы яктан мондый сүзләр ишетелде:

— Атыңны җик тә Мантово кардонына, безнекеләр янына ычкын. Качсыннар тизрәк, югыйсә эзгә төшәләр диген.

— Киттем!

— Юк, китми тор әле!— дип кычкырды Кузин, кинәт ишекне ачып.— Ялгызыңа гына күңелсез булыр, менә безнең взводны да алып бар кардонга!

Взвод фетнәче кулаклар өерен авылга алып кайтты. Халык җыелды. Фетнәчеләргә Совет власте исеменнән, авыл ярлылары ихтыяры белән хөкем карары чыгарылды. Атаман Кочневны, улы белән икесен бергә бастырып, халык алдында аттылар.

Кулаклар тарафыннан вәхшиләрчә җәзалап үтерелгән Токинны, Левштановның хатынын, кул-аяклары каерып ташланган, күзләре казып чыгарылган тагын 3 крестьянны, халык авыл уртасына — туганнар каберлегенә зурлап күмде.

## VI

Интервентлар һәм контрреволюционерлар яшь совет Республикасын буарга маташтылар. Себердә һәм Урта Идел буенда алар, чехословаклар корпусын үз якларына аударып, фетнә оештырдылар. Акгвардияче офицерлар, алпавыт һәм капиталист малайлары шул корпуска керделәр.

Самараны басып алганнан соң, акчехлар Сембергә һөҗүм иттеләр. 22 июльдә шәһәр алар кулында иде инде. Киракле хәзерлек эше үткәргәннән соң, дошманның Казанны басып алу өчен билгеләнгән отрядлары, 21 судноға төялеп, Сембер районыннан Идел белән югары менеп китте.

1 августта Тәтештән 7—8 километр ераклыктагы Балымер авылы янында дошман флотилиясе белән безнең флотилия арасында сугышлар башланды. Акчехларның Тәтешкә килүен дүрт күзләп көткән купецлар, аларның хатыннары һәм кызлары киенеп-ясанып, шушы Балымер авылы янындагы утрауга җыелдылар. Утрау турысында гына хатын-кызлар монастыре һәм кечерәк кенә чиркәү дә бар иде. Чехословак офицерларын һәм акгвардиячеләрне каршыларга килгән купец кызлары гыйбадәтханәдә зур эчү мәҗлесе оештырдылар, үзләрен коткаручы офицерлардан бернәрсәләрен дә кызганмадылар...

Шул чак кызыл флотилиянең кечерәк кенә бер группасы Тәтеш пристанена килеп туктады. Аның командиры Тәтеш властьларына:

— Моторлы көймәбез тишелде, шуны тиз генә ямыйсы иде, — дип мөрәҗәгать итте.

— Карап-карыйк, — дип, шундук эшкә тотынды тимерче Александр Журин. Ярты сәгать узмагандыр, көймә яраклы хәлгә килде. Шуны гына көтеп торган матрослар, көймәгә 2 пулемет куйдылар да, ашыгып китеп бардылар.

— Тагын ни боерасыз? — дип, командирга мөрәҗәгать итте Журин.

— Сез бик уңган кеше булып чыктыгыз,— диде командир, аның без сабы шикелле кимекләнеп беткән бармакларына карап. — Әнә теге «Братство» пароходына туп беркетәсе бар иде. Бәлки, булдыра алырсыз?

Журин, пароходка кереп, дүрт кырынлап юнылган имән бүрәнәне тишә башлады. Ярдәмгә 2 матрос та килгәч, эш тиз барды. Төш житәрәк, туп ныгытып беркетелгән иде инде.

Пароход кузгалды. Журин эш белән мавыгып, чыга алмый калды. Балымерга барып житәргә бер чакрым чамасы калгач, акчехлар ут ачтылар. «Братство» да ут белән җавап бирде. Ләкин аның бер снаряды да цельгә тими иде. Журин тупчы солдатка күз салган иде, хәйран калды: солдат бөтенләй ата белми икән ләбаса.

— Рөхсәт итегез, мин — артиллерист! — дип, Журин командирга мөрәҗәгать итте.

Ул бер тапкыр гына атып калды — снаряд бетте. «Братство», кире Тәтешкә таба борылып, тизлеген бик нык арттырды. Чөнки аның трюмына су керә башлаган иде инде.

Журин Тәтешкә 4 августта гына кайтып керә алды. Яктырып кына килә иде әле. Акчехларның берничә хәрби пароходы Тәтеш пристанена килеп туктаган. Журин чех офицерлары арасыннан Колсанов малаен — акгвардияче офицерны танып алды. Теге вакытта Сембергә качты дигәннәр иде шул. Боларга шуннан ияреп кайткандыр, кабахәт, дип уйлап алды ул. Колсанов янында Дмитрий Полусохин, тагын берничә яшь купец та бөтерелә иде. Полусохин баржа бушатып торучы грузчиклар ягына төртеп күрсәтә-күрсәтә чех офицерына нәрсәдер сөйли. Менә алар грузчиклар янына килеп, Миңлебай Ярулласын чакырып алдылар.

— Теге вакытта мулланы мыскыл итүче, безнекеләргә каршы күсәк күтәрүче әдәм актыгы син идең бит?! — дип акырды Колсанов.

— Әйе, мин идем! — диде Ярулла, том кара күзләрен офицерның йөзенә текәп.

— Кара син аны, нинди кыю! — дип гаҗәпләнде чех офицеры. Анны кобурасыннан наганын суырып алып Ярулланың борын төбендә уйната-уйната:

— Менә моны татыганың бармы?! — дип акырды.

Колсанов чех офицерына күз кысты да:

— Ярулла, мин сине коткара алам, тик син безгә шуны әйт: Дмитрий Карасев хәзер кайда? — дип сорады.

— Ә мин аны кайдан белим,— диде Ярулла, исе китмәгәндәй.

Чынлыкта исә ул Карасевның, шәһәр Советының бөтен кыйммәтле документларын һәм Фуражковта сакланган документларны җыештырып, моннан бер сәгать элек кенә Казанга китүен үз күзләре белән күреп калды. Ләкин моны тегеләргә әйтмәде.

— Димәк, әйтмисең! — дип җикеренде Колсанов һәм чех офицерына яңадан күз кысты. Тегесе шундук наганын чыгарып, Ярулланың күкрәгенә атып җибәрде...

* * *

Тәтеш акгвардиячеләре, чех офицерларын ияртеп, пристаньнан шәһәргә менделәр. Алар шымчылар ярдәмендә бер үк сәгатьтә шәһәр Советы членнары Абрамовны, Митягинны, Трузгинны кулга алдылар. Блинниковны таба алмадылар. Матрос Трузгин, атарга алып чыкканда суга сикереп, үлемнән котылып калды.

Котырынган офицерлар өере Василий Рыжковны кич белән мунчада юынып утырган чагында тотып алдылар. Аны мылтыклы 8 солдат уртасына алып, пароходка — штабка алып төштеләр. Акгвардиячеләр билгеләп куйган шәһәр коменданты Плотников, чехлар штабы кушуы буенча, шәһәр халкын яр буена җыйды. Янәсе, гыйбрәт алыгыз, совет яклы кешеләр белән менә ничек эш итәләр. Яр буена чыгып баскан халык арасында Җиһан да бар иде. Ул, Василий Рыжковны мылтыклар астында

пароход палубасына алып чыгуларын күргәч, тыела алмыйча, үкереп елап җибәрде. Пароход ярдан 10—15 метр гына ераклыкта якорьда утыра иде. Андагы галәмәтләр, хәтта сөйләшүләр дә яр буендагы халыкка ап-ачык күренеп, ишетелеп тора. Менә Рыжковны йөзе белән халыкка каратып, палуба читенә бастырдылар. Куе бөдрә чәчләре маңгаена тузгып төшкән, ялангач киң күкрәге алга чыгып тора, беләк мускуллары элеккегедән дә юанрак булып кабарганнар, күзләре ут кебек яна, үзенең хәзерге хәлате белән ул нииндидер очсыз-кырыйсыз биеклеккә очарга торган тау бөркетен хәтерләтә иде.

Колсанов, Рыжков янына килеп басты да, тәкәббер генә сорады:

— Бәлки яр башындагы өтекләргә әйтәсе сүзең бардыр? Ха-ха-ха!

— Сүзем юк, тик туган шәһәремә, халкыма тагын бер генә минут карап торырга рөхсәт ителүен сорыйм, — диде Рыжков көр тавыш белән.

Колсанов чех офицерына карап алды, тегесе «мөмкин» дигән ишарәне ясады. Шул минутта яр өстеннән Җиһаннның:

— Вася! Вася! Җаным! — дигән әрнүле тавышы Идел өстенә яңгырап таралды. Бу хәл палубадагы офицерларның игътибарын җәлеп итте. Рыжковның күкрәк мускуллары кинәт кенә сикергәләп алдылар. Шул мизгелдә гаҗәп бер хәл булды: Рыжков, кулларын бәйләгән дилбегә очын өзеп ыргытты да, яшен тизлеге белән суга чумды. Палубада ыгы-зыгы, ә яр өстендә тантаналы кычкырышлар башланды. Өч офицер, акайган күзләрен су өстендә ялт-йолт йөртеп, револьверларын төзәгән килеш, Рыжковның калкып чыкканын көттеләр. Ярты минут үтте... бер минут... Әмма Рыжков бармагын да күрсәтмәде. Аның куәтле мускуллары, иркен сау үпкәсе таныш Идел төбендә эшләде дә эшләде. Тыны бетү ахыр чиккә җиткәч кенә, пароходтан 100—150 метр аргы якка китеп ул су өстенә калыкты. Бинокольле офицер аны күреп алды. Офицерлар шул якка пуля яңгыры яудыра башладылар. Кинәт Рыжковның кул башы кайнарланып киткән кебек булды һәм су өстенә кып-кызыл кан таралды. Ул, бернигә карамастан, үлем белән тартыша-тартыша, каршы як ярга йөзде. Ерак та калмады инде йөзеп чыгарга, 200—300 метрдан артык түгелдер. Ә ярга чыга алса, куе урман китә, Три Озера крестьяннары да бар анда...

Берничә солдат, моторлы көймәгә утырып, Рыжковны куа киттеләр...

* * *

Төн буе күк күкрәп, яшенле яңгыр яуды. 5 нче август иртәсендә күкне куе болыт каплаган иде. Тәтешнең карт балыкчысы Федор Миронович Елисеев, көймәсен өскәрәк тартып куйды да, пристань баскычыннан күтәрелергә куркып, яр астындагы сукмак буйлап кына өенә юл тотты. Шарлавык чишмә чокырына килеп җиткәч, ул коточкыч күренешкә тап булды: чокырда 7—8 үле ир-ат гәүдәсе ята. Кайсының аягы-кулы каерып ташланган, кайсының... Балыкчы карт көч-хәл белән генә Рыжковны һәм Фуражковны танып алды. Василий Рыжковның 2—3 җирдән күкрәге тишкәләнгән, бармаклары сындырып ташланган, берничә урыннан баш тиресе каерып алынган, күз урыннарында тирән чокырлар гына калган.

Карт байтак вакыт акылын җыя алмыйча торды. Чехларның пристань ягыннан килгән шау-шулары гына аны айнытып җибәрде. Ул, өенә дә керә тормыйча, туп-туры Феоктиса әбигә барды. Өй бусагасын атлап, хәл-әхвәл сорашкандай итте дә шомлы хәбәрне ирештерде. Ана кешенең телгәләнгән йөрәге бу авыр хәбәрне күтәрә алмады: ул «улыңны үтергәннәр», дигән сүзне ишетү белән телдән калып, идәнгә иелеп төште, аяк-кулларын паралич сукты.

## VII

Дошман эзәрлекләвеннән качып калган Трузгин белән Блинников, бик нык яшеренгән хәлдә, чехлар һәм акгвардиячеләр урнаштырган властька төрлечә комачаулык итәргә тырыштылар. Алар дошман каршында ышанычын югалтып өлгермәгән кешеләрдән файдалану тактикасын кулландылар. Нармонка авылында яшәүче элекке матрос Николай Линьков, элекке солдат, Казан губернасы Советының солдатлар секциясе члены, хәзер Тәтештә ямщик булып эшләүче Шамил Мөхәммәтжанов — шундыйлардан иде; тимерче Александр Журиннан да чехләр шикләнмиләр иде.

Ак офицерлар котырынып һөҗүм итәләр, Карасевлар семьясында көн саен тентүләр булып тора, Екатерина Ивановнадан ирен табып бирүне таләп итеп, балаларын кырып бетерү белән яныйлар. Дмитрий Карасев бу көннәрдә Казаннан җәяү кайтырга чыгып, дошман кулына эләкмәс өчен Идел буендагы урманнарда яшеренә-яшеренә, Тәтешкә якынлашып килә иде.

Бердәм революцион бурыч шундый: шәһәрдә һәм өяздә дошман армиясенә мобилизацияне өзәргә, ә Кызыл Армиягә һәрьяклап ярдәм итәргә!

Николай Линьков Нармонка күршесендәге Чинчурино авылына килеп кергәндә, акгвардиячеләр тарафыннан куркытылган крестьяннар, ыгы-зыгы килеп, хәрби пунктка китәргә җыеналар иде. Николай, арбаларның берсенә менеп басты да:

— Мужиклар, китәргә ашыкмагыз әле, минем сезгә сүзем бар, — дип сөйли башлады.

Китәргә җыенучылар да, аларны озатырга килгән хатын-кыз, карткорылар да, арба өстенә баскан тельняшкалы матроска төбәлеп, тынып калдылар. Бирелә легендар «Аврора» крейсерында хезмәт итеп кайткан, Кышкы сарайны штурмлауда катнашкан бу егетне якыннан белүчеләр күп иде. Аның кыю сүзләре Чинчурино кешеләре йөрәгендә өмет ялкынын кабызып җибәрде.

— Мужиклар, күршеләр, — дип дәвам итте матрос, — азатлык һәм жир өчен, эшче-крестьян властен яулап алу өчен меңнәрчә кешеләр башларын куйдылар. Ә бүген революция дошманнары яңадан үз властьларын урнаштырыр өчен крестьянны ут эченә куып кертмәкче булалар. Иптәшләр, сез акларга хезмәт итәргә телисезмени?! Алар сезнең кулыгызга пулемет, мылтыклар бирерләр. Атарга боерырлар. Ә кемгә каршы атарсыз соң сез? Совет властен яулап алган аталарыгызга, абыйларыгызга, туганнарыгызга каршы атарсыз. Үзенең атасын, агасын, энесен, ярлы дустын үтерергә кемнең кулы күтәрелер икән?!

Минем сүзем бетте. Менә үзегез сайлагыз инде...

— Нишләргә соң? — дип сорап куйды кайсыдыр. — Бармасак, артыбыздан тагын килеп житәчәкләр бит.

— Урманнарга качыгыз! — диде Линьков. — Әллә ни озак ятарга туры килмәс анда сезгә. Тиздән безнекеләр килеп җитәчәк. Аларга кушылырсыз.

— Николай дөрес әйтә. Валлаһи, дөрес әйтә!

Иртәгесен Линьков Тәтешкә килде. Җыелу пунктында аркасына биштәр аскан крестьяннар байтак иде. Ә Чинчуринодан берничә генә кеше килгән. Урюм, Пролей-Каши якларыннан берәү дә юк. Утка баскандай чабышалар ак офицерлар. Күз буяр өчен Линьков та китүчеләр кыяфәтендә килгән иде. Ул, халык арасына кереп, таныш-белешләренә сүз салды:

— 2 сәгатьтән бөтенебезне пароходка төяп сугышка озатачаклар. Берәмләп, ике-өчәрләп кенә таегыз моннан. Федоровка урманына юл тотыгыз. Калганын анда баргач сөйләшербез...

Җыелган халык сафлары торган саен сирәгәя барды. Тик... Төрле кешеләр була бит арада: куркаклары да, шымчылары да табыла. Шуларның кайсысыдыр барып әйтте ахры, көтмәгәндә дүрт офицер килеп Линьковны, кулларын бәйләп, Идел читендәге төрмәгә илтеп яптылар.

Кичкә табан Линьков төрмәнең бу сасы бүлмәсендә ялгыз түгел иде инде: Пролей-Каши авылыннан монда тагын берничә крестьянны китереп яптылар. Линьков алар арасыннан Игнатий һәм Елисей Шепелиннарны, Сергей һәм Иван Курковларны, Абрам Большаковны танып алды.

— Менә тагын бергә булдык,— диде Линьков, Большаковның иңбашына сугып.

— Әйе, сукмаклар бер үк юлга алып чыккач, очрашмый булмый икән шул, — диде Большаков, уйчанланып.

— Я, братва, сөйләгез әле, ничек-ничек булды? — дия-дия, Линьков болар янына килеп утырды. Большаков сөйләп бирде.

Чехларның Тәтешкә якынлашуын ишеткәч үк, Пролей-Каши крестьяннары отпор чаралары күргәннәр: авылда булган сугыш кораллярын учетка алганнар, андый-мондый хәл була калса, чиркәү чаңы ярдәмендә сигнал бирү өчен кешеләр билгеләп куйганнар. Корал исәбен алу комиссиясенә солдат Абрам Большаков җитәкчелек иткән.

Тәтешне чехлар басып алгач, авыл кулаклары алпавыт Лапаев җитәкчелегендә үзләренең контрреволюцион эшләрен активлаштырып җибәрәләр. Моңа җавап итеп, крестьяннар җыелып, бердәм карар чыгаралар: «Чехословаклар хәрби хезмәткәрләрне «халык армиясе»нә мобилизацияли калсалар, җыелу пунктына беркем дә бармаячак». Беркетмәгә 85 кеше кул куя.

Крестьяннар карарларында нык торалар — хәрби пунктка берәү дә бармый. 15 августта Пролей-Кашига кораллы отряд җибәрелә. Ул Земское управоның барлык хезмәткәрләрен, шул исәптән аның председателе И. Гришинны кулга ала, коралларны тапшыруны, комиссия исемлеген бирүне таләп итә. Бу вакыт халык кырда — уракта була. Менә билгеләгән кешеләр чиркәүгә менеп тревога сигналы бирәләр. Кырдагы бөтен эшен ташлап, халык авылга кайта һәм Земское управо янына җыела. Крестьяннар отряд начальнигыннан кулга алынган кешеләрне азат итүне таләп итәләр. Отряд моңа винтовкадан ату белән җавап бирә. Пуля яшь егет Курзаевны аяктан ега. Бу хәлне күреп, крестьяннарның ярсуы чиктән аша. Халык отряд өстенә ташлана. 6 солдат һәм офицер үтерелә, берсе каты яралана. Калганнары табан ялтыраталар. Крестьяннар шактый корал кулга төшерәләр. Бу вакыйгадан соң авыл халкы, кулларында булган бөтен коралларын җыеп, ата белүче кешеләргә өләшәләр. 42 мылтык һәм аның һәркайсына 250 патрон туплана. Авыл чикләренә төнге саклар куялар. Иртәгәсен алпавыт Лапаев командалыгындагы 50 кешелек отряд авылга һөҗүм итә. Ул пулемет һәм гранаталар белән дә коралланган була. Авылның бай катлавы ак флаглар күтәреп, аларны каршы ала. Каты сугыш башланып китә. Крестьяннар соңгы патроннарына чаклы сугышалар, ахыр чиктә кул сугышына күчеп, дошманны тукмыйлар. Ләкин кул белән генә пулеметка каршы торып булмый шул. Кулаклар восстание оештыручы крестьяннарны кулга алырга булышалар...

* * *

Кызыл Армиянең ударлары астында чехословаклар һәм аквардиячеләр сентябрь урталарында Тәтештән чигенделәр. Иртәгә чигенәсе кичне төрмәдәге тоткыннарны «Игорь» дип аталган үлем баржасына утыртып каядыр алып киттеләр. Тәтеш балыкчылары 3—4 көннән соң Кече

утрау уртасында Николай Линьковның, Дмитрий Карасевның һәм Пролей-Каши восстаниесен оештыручылардан берничәсенең су өстенә калкып чыккан үле гәүдәләрен күреп кайттылар...

## VIII

Үлем тозагыннан котылып калган Василий Блинников, Николай Трузгин, Совет власте өчен һәлак булган дусларының революцион эшен дәвам иттереп, шәһәрдә һәм авылларда зур эш җәелдерделәр. Партиянең өяз комитеты физик һәм идея ягыннан үсеп, чыныгып килүче яшьләргә зур өмет баглады: 1918 елның азагында семинариядә һәм ирләр гимназиясендә укучыларның партиягә теләктәшлек итүче бер төркеменә Тәтештә яшьләр оешмасы төзүне йөкләде. Оешмага 30 кеше язылды. Алар культура-агарту эшләре алып бара башладылар. Ләкин 1919 елның язында, Иделгә Колчак якынлашу сәбәпле, оешманың күпчелек членнары үзләре теләп фронтка киттеләр. Партия комитеты яшь инициаторларга яңадан задание бирде: оешманы торгызырга, үстерергә кушты. Җәй урталарында яшьләрнең өяз конференциясе җитәкче орган төзеде. Өяз комитетының председателе итеп Павел Бекшанский, аның урынбасарлары итеп Михаил Кузьмин (Мишши Сеспель) һәм Ибраһим Батыршин сайланды. Комсомолның өяз комитеты нардом бинасына урнашты.

* * *

Комитет членнары авыллардан барысы да нәкъ утырыш билгеләнгән вакытта — кичке җидегә кайтып җиттеләр. Павел Бекшанский утырышны ачып җибәрде.

— Беренче мәсьәлә, — диде ул, — халыкны тәрбияләү эшендә партия оешмасына безнең ярдәмебезне көчәйтү.

Байлардан тартып алган китапларның безнең өчен кирәк булганнарын сайлап алдык шикелле. Инде китапханә ача алабыз. Бинабыз бар. Китапханәче кирәк. Кемне тәкъдим итәсез, иптәшләр?

Берничә кешенең фамилиясе телгә алынды:

— Дмитрий Флегонтовичның сеңелесе Анна Фуражкова.

— Екатерина Ивановна Карасева.

— Анастасия Ильинская.

Бекшанский тәкъдимнәрне туктатырга кирәклеген аңлатып ишарә ясады да:

— Бу кандидатуралар өчесе дә яхшы, — диде. — Ләкин аларга башка эш йөкләнгән бит. Анна Фуражкова шәһәр Советы аппаратында эшли, Екатерина Карасева белән Анастасия Ильинская детдомда.

Клава Гавриловны куйсак ничек булыр?

Тәкъдим күпчелек тавыш белән кабул ителде. Бекшанский икенче мәсьәлә буенча Михаил Кузьминга сүз бирде. Өстенә хәрби гимнастерка кигән 20 яшьләр чамасындагы чуваш егете, ике кулы белән дә өстәл читенә таянып, рус телендә бик оста итеп комитетка рапорт бирде:

— Җиде авылда булдым. 600 кешене яшь добровольцлар отрядына язып кайттым. Алар бүгеннән фронтка китәргә әзер торалар.

Комитет утырышына чакырылган яшьләр, гади генә итеп, үзләрен чәй янында гәпләшеп утыргандай иркен тотып, шәһәрне саклауда, дезертирларны тотуда, акгвардияче офицерларны фаш итүдә, кулакларның һәм купецларның яшергән алтыннарын эзләп табуда, милекләрен конфискацияләүдә ничек катнашулары турында сөйләделәр.

Утырыш төн урталарына кадәр барды. Ә иртәгәсен шәһәр яшьләре, комитет членнары җитәкчелегендә, якшәмбе өмәсенә чыктылар. 100 гә якын кеше көн буе пристаньда баржадан утын бушаттылар. Аны шәһәр

мәктәпләренә, больница, балалар йорты ишек алларына ташып өйде-ләр.

Эш беткәч, кояш инәр алдыннан, өмәчеләр Идел буендагы болын-лыкка төштеләр. Кызлар, егетләр түгәрәк ясап бастылар. Гармоньчы егет «барыня»ны тартып җибәрде. Шуны гына көтеп торгандай, Павел Бекшанский уртага очып төште һәм өстендәге утын тузаннарын кага-кага биеп китте. Аны башкалар алыштырды... Биеп туйгач, җырлап әй-ләнделәр. Түгәрәк уртасына Михаил Куприянов чыгып утырды. Ул каяндыр каты кәгазь табып алган да, тезенә куеп, шуңа нәрсәдер сызга-лый. Биш минут та узмагандыр, ул, торып басып, кулындагы кәгазен югары күтәрә. Анда Павел Бекшанскийның карикатурасы төшерелгән. Павел 4 куллы итеп ясалган: берсе белән попның сакалын чорнап тот-кан, икенчесе белән өяз газетасына мәкалә яза, өченчесе белән купец-ның амбар йозагын ача, дүртенче кулы белән баржадан утын бушата.

Рәсемне күргәч, түгәрәктәгеләр шаркылдап көлештеләр. Ә Бекшан-ский Куприяновның аркасыннан кочып:

— Шәп художник булырсың син, — дип мактады.

Җыр, уен-көлке авазлары Идел буенда караңгы төшкәнче яңгырап торды. Һәм шул кичне...

* * *

Пролей-Каши авылының бер малае — чехларга каршы крестьян восстаниесендә катнашкан Курков Иванның энесе, 13 яшьлек Тихон, 5 ле лампа алдында тирән уйга чумып утырды-утырды да, хат язарга кереште. Ак кәгазьгә бер-бер артлы түбәндәге сүзләр тезелеп китте:

*«Кадерле Ленин!*

*Социализмның тизрәк җиңүен теләп, Сезгә сәлам язам. Мин, дингә ышанган һәм надан ата-анам тәрбиясен алган, ә хәзерге вакытта үзем һәм социалистик Россиям өчен сукалы авылда иген игүче 13 яшьлек ма-лай Сезгә хат язарга уйладым, ягъни бөтен дөнья социалистик револю-циясенең бөек юлбашчысы иптәш Ленин белән чын күңелемнән теләк-тәш булуымны белдерергә теләдем.*

*Кадерле Ленин!!!*

*Мин Сезгә революция өчен файдасы булмаган шундый хат язуым өчен үземне орышам, чөнки мондый хатлар Сезне эшегездән аера. Лә-кин, беләсезме, мин Сезне бик яратам, шунлыктан Сезгә язмый түзә алмадым.*

*Иптәш Ленин! Сезгә шуны хәбәр итә алам: мин Пролей-Кашида культура-агарту түгәрәге председателе, ревкомиссия члены, авыл Со-веты секретаре булып эшлим.*

*Минем адрес: Казан губернасы, Тәтеш өязе, Пролей-Каши авылы, Тихон Ильич Курков»...*

—●—

Саҗидә Сөләйманова

# ЛЕГЕНДАР ЛЕНИНГРАДТА ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ

## Тере тарих йөри урамнарда

Ленинград...
Сине үзенә тарткан
Сихри көч бар анда, бер ут бар.
Гасыр түрләреннән Пушкин калка,
Некрасовлар калка, Блоклар...

**Бу юлларны шагыйрь Сибгат Хәким 1965 елның октябрь аенда Ленинградта уздырылган татар әдәбияты кичәләренең берсендә утырганда, открытка артына язып куйган иде. Күрәсең, бу легендар шәһәргә һәркайсыбызны ниндидер сихри көче тартып китергән...**

**Ленинградта исемнәре бөтен дөньяга танылган язучылар аз түгел. Өстәвенә, монда көн саен диярлек чит ил кунаклары, әдәбият, сәнгать осталары килеп тора. Безне Ленинград ничек каршылар? Шушы сорау юл буе күңелгә борчу да салып барды.**

**Вокзалга килеп төшкәч, барыбызны да борчып килгән уйлар бераз таралгандай булды. Кунакларны каршыларга язучылар, эшче яшьләр, студентлар, интеллигенция вәкилләре килгән иде. Каршылаучылар арасында драматург Риза Ишморат та бар. Ленинградта ул студент елларын үткәргән һәм яшьлек хатирәләре белән очрашырга барыбыздан да иртәрәк киткән. Чәчәкләр, чәчәкләр... Чәчәкләрдән дә бигрәк — каршылаучыларның кояштай йөзе. Озак күрми торган якын туганнарыбыз белән очрашкандай тойдык үзебезне. Вокзалдан гостиницага барганда ук һәркем үзенә юлдашлар табып алды. Минем ике ягымда ике башкорт кызы: Миңлегөл һәм Гадилә. Бу чибәр кызлар педагогия институтының беренче курсында укыйлар икән. Кыска гына вакыт эчендә тормышлары, укулары, туган авыллары турында сөйләп алдылар. Ул арада булмый, Ленинградта яшәүче Кырым шагыйре Риза Халид иҗат эшләре, безнең шигырьләрне тәрҗемә итү хәлләре турында хәбәрләр сөйли; китапханә хезмәткәре Энҗе Сәгыйдова килеп таныша (без аны соңыннан «зәңгәр Энҗе» дип йөрттек).**

**Кичке Ленинград кунакларны күз камаштырып җемелдәгән утлар букеты белән каршы алды. Автобуста барганда күзгә төсле елкылдаган асфальт урамнар, эрелеваклы елгалар, челтәрле күперләр, мәһабәт һәйкәлләр чалынып калды.**

**Шәһәр белән таныштырырга безне иртән алып чыктылар. Бу әкият-шәһәрне күз алдына китерим дисән, иң беренче Пушкин сүзләре искә төшә:**

Сөям, Петр иҗат иткән кала,
Сөям җитди һәм төз сыныңны,
Нева, синең гранит ярларыңда
Горур аккан мәшһүр суыңны.



Ленинград. Петр I гә һәйкәл.

Коймаларда чуен бизәгенне,
Сөям айсыз якты төннәреңне
Мин үземнең шәмсез бүлмәмдә
Укыйм, язам шундый төннәрдә
Ачык күренә тын, буш урамнар,
Йокыдагы зур таш диварлар,
Адмиралтейский түбәсе,
Аның балкып торган энәсе.


Шушы юллар аны әкият-кала итеп күңелдә сеңдереп калдыргандыр да. Безнең беренче тукталыш — күңелләрне еректан җәлеп итеп торган һәйкәл — Сыбайлы Петр I. Дөньяда иң матур һәйкәл. Бу данны аңа, скульпторның осталыгы белән бергә, бөек шагыйрьнең үлмәс әсәре китермәде микән? Адым саен тарихи истәлекләр. Декабристлар мәйданы. Деспотизм режимын тамырыннан тетрәткән кыю бәрелеш нәкъ шушы урында булган. Урам буйлап барасың, һәм синең күз алдыннан рус революциясенең бөтен тарихы уза. Монда һәр урам, һәр йорт, һәр борылма дөнья тарихында тиңе булмаган революция эзләрен саклый. Әнә патшага бомба аткан урын. Дворян революционерларны народниклар алмаштыра. Азатлык өчен көрәш, буталчык, фаҗигале юллар аша үтеп, тарихның үзен тудыручы эшчеләр кулына күчә. Күп тапкыр рәсемнәрдә күргән броневик. 1917 елның апрелендә Ленин, шунда басып, буржуаз революциядән социалистик революциягә күчү кирәклеге турында речь сөйләгән. Менә гади генә йортның гап-гади балконы. Моннан Ленин беренче тапкыр социалистик революциянең җиңүе турында игълан иткән. Һәйкәлләрнең кыйммәте аларның затлылыгында түгел икән шул. Җир йөзендә күпме патшалар, үзләренең алтынланган тәхетләренә басып, халык өчен шундый сөенечле хәбәр әйтә алмаганнар?!.

Тере тарих йөри урамнарда...
Очрашабыз тагын, тагын да.
Мәңгелек ут яна мәйданнарда,
Көрәш рухы монда кабына.
Каһарманнар баскан һәрбер чатта,
Өнсез сыннар сиңа дәшәләр...

Кәрәш эзләреннән кабат узсаң,
Арган күңел гүя яшәрә.
Җәйге бакча күзгә бизәкләрдә,
Алтын яфрак оча талпынып.
Юлларында бөек шагыйрь йөргән,
Җырга салып йөрәк ялкынын.

Нева, Җәйге бакча, Кышкы сарай, Аврора, Пушкин йорты... Шушы йортта Россия халкы кабатланмас шагыйре белән хушлашкан. Тарих китаплары, шигырьләр белән күңелләргә бала чактан ук кереп урнашкан истәлекле урыннар. Алар турында гади сүзләр белән генә сөйләп тә булмый, гел шигырь белән генә сөйлисе килә. Гид ролен үтәүче Ленинград шагыйре Леонид Хаустов туган шәһәре турында нәкъ шулай сөйләде дә.

Ленинград урамнары иркен, якты. Күп сандагы елгалар, каналлар урамнарны киңәйтеп җибәрәләр. Бу иркенлек ленинградлыларның күңел киңлегеннән дә түгел микән? Ни әйтсәң дә, шәһәр таш бит. Күңел җылылыгы өстәлмәсә, аның салкын тоелуы мөмкин. Ун көн буе без хуҗаларның күңел җылысын тоеп яшәдек. Ун көн буена хуҗалар безне Ленинградның истәлекле урыннары белән таныштырып йөрделәр. Моның өчен Ленинград язучыларына зур рәхмәт әйтәсе килә.


Ленинград. Адмиралтейство бинасы.

Без Разливта. Вакытлы хөкүмәт агентларыннан яшеренеп, Ильич монда көрәштәшләре белән очрашкан, киңәшкән, «Дәүләт һәм революция» дигән гениаль әсәрен язган. Ильич яшәгән шалаш әле дә шул килеш сыман, ул печән чапкан чалгы, ул тоткан тырма әле дә исән. Безнең өчен изге кешенең эзләрен саклаган бу җирдә ниндидер сабыр тынлык: һәркем Ильич сулаган һаваны сулый, ул кичергән хисләрне кичерәдер төсле.

Ленинградны томанлы шәһәр дип беләидек. Ә без килгәч, октябрь кояшы гел көләп кенә торды. Күзгә урман кояш нурлары астында бөтен төсләре белән күренеп калырга тырыша. Төсләрнең төрлелеге, байлыгы ягыннан елның бер чагы да күзгә җитә алмый торгандыр. Табигать төсләренә соклану кеше кулы тудырган үлмәс сәнгать әсәрләренә соклану белән алмашына. Бөек рәссам Репин усадьбасы Пенаты. Пушкин шәһәре (элекке Царское село). Петергоф. Гасырлардан калган истәлекләрне немец илбасарлары хәрабә хәленә китергән булганнар. Халык милкенә әйләнгән бу җәүһәрләрне элекке хәленә кайтару өчен Совет хөкүмәте әле дә күпме көч куя, осталарның күпме тырышлыгы салына! Сугышның нинди вәхшилек икәнлеген монда, сугыш уты көйдереп киткән җирләрдә, бигрәк тә ачык тоясың. Йөрәкләрне сугыш истәлекләре, блокада елларыннан калган җәрәхәт эзләре айкап үтә... Фронт линиясе буйлап утыртылган чыршылар, ул еллардан калган дотлар, Киров заводыннан чыгып, Берлинны урап кайткан танк, исемсез геройларга һәйкәлләр...

— Онытмагыз, без бар әле, без шәһитләр! — дия төсле бу өнсез истәлекләр.

Ленинградның төньяк читендә Пискарев каберлеге.

Монда ленинградлылар ята.
Монда аналар, аталар, балалар.
Алар белән янәшә — күпме солдат...

Үз тормышларын биреп, сине саклап калды алар, Ленинград.
Күп алар бу мәңгелек гранит астында,
Беркем дә онытылмас,
Берни дә онытылмас...

Бу сүзләр, бу ант кан һәм яшь белән гранитка уелган. Миллионнарның үлемсез батырлыгына үлемсез һәйкәл. Үзәктә революция корбаннары мәйданыннан күтәрелгән мәңгелек ут яна. Революция ялкыны буыннан-буынга күчә, йөрәктән-йөрәккә кабына. Мәһабәт «Ватан ана» сыны балаларының мәңгелек йокысын саклый. Беркем дә онытылмас. Берни дә онытылмас. Бу безнең дә ант, легендар Ленинград!

Тере тарих йөри урамнарда... Петропавел крепосте. Бу җан өшеткеч таш коридорлар аша рус революциясенең өч буын вәкилләре үткән. Юеш, караңгы таш капчыклар, җиргә сеңгән тимер сәке, ирекле дөньяның барлыгын сиздереп торган бер сызык якты. Ә ишектә надзиратель күзе өчен уелган яшькелт пыяла тишек. Сынмас ихтыярлы ирләр белән берләттән кызлар, кызлар үлем алды газапларын кичергәннәр бу шыксыз зинданнарда. Генерал кызы Софья Перовская, йомшак ак мендәрләрене юеш таш сәкегә, бөдрә каеннарыңны дар агачына алыштырырга сине нәрсә мәҗбүр итте? Ирек, миллионнар өчен ирек яулап алу теләге!

Җан өшеткеч шыксыз казаматтан
Чыгып бастым Нева ярына.
Бүтән күзләр белән карадым мин
Тормышыма, Кояшка — бәрына.

Тиешенчә шатланмыйбыз төсле,
Тиешенчә, гүя, көлмибез.
Ил иреккә чыккач тугангамы,
Ирекнең без кадерен белмибез.

Бәхеткә дә, ахры, күнегәбез,
Күнеккәндәй һава суларга;
Ничә буын аны яулап биргән,
Без бурычлы, дуслар, шуларга!

Шәүкәт Галиевның бу шигырен безгә инженер Рифкать Шингареев укыды.

## Башка берни дә кирәкми...

...Башка берни дә кирәкми,
Дусларның мин гомрем буе
Тойсам җылы карашын.

Рөстәм Яхинның Сибгат Хәким сүзләренә язган җырын беренче кичәдә үк Эмил Җәләлетдинов җырлаган иде. Тиздән бу җыр безнең гимнга әйләнеп китте. Кичә башланыр алдыннан да, кичәдән соң да һаман шул сүзләрне төрлечәгә борып көйләп йөри башладык.

Башка берни дә кирәкми,
Ленинградта дусларымның
Тойсам җылы карашын...

Беренче кичә барышында ук бу җылы карашны яхшы тойдык без. Филармониянең концерт залы шыгрым тулы иде. Билетлар ике атна элек сатылып беткән диделәр. Кичәне СССР Язучылар союзының Ленинград бүлеге председателе шагыйрь Михаил Дудин ачты. Пианистка Назнинә Сабитовская Казан позывнойларын яңгыратты, Эмил Җәләлетдинов Татарстан халкы исеменнән музыкаль сәлам тапшырды. Анардан соң СССР Верховный Советы депутаты, Тукай премиясе лауреаты Габдрахман Әпсәләмов ленинградлыларга республикабызның сәламен җиткерде. Аннан соң сүз, кичәне алып бару өчен, «Казан утлары» журналының редакторы, тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинга

бирелде[1]. Дилбәгәне кулына Рафаэль Мостафин алгач, йөрәк белән мавыгып утырырга вакыт калмый. Ул әдәби-музыкаль кичәләрне бик җанлы, җыйнак һәм тыйнак итеп алып бара. Артык төче телләнеп тә китми, һәр чыгыш ясаучы турында бер-ике үткен сүз әйтеп куя. Җырчылар, язучылар, композиторлар бер-берсен алмаштырып кына торалар. Әйтергә кирәк, кичәләр бик күңелле узды. Сөйләүче белән тыңлаучы арасында күренмәгән җепләр сузылды. Бу күңел җепләре ахырга кадәр өзелмәде һәм без киткәч тә өзелмәс дип ышанабыз. Татарстан сандугачы Рәисә Билялова Муса Җәлил, Әхмәт Ерикәй, Мөхәммәт Садри әсәрләренә язылган көйләрне сайрата. Тамашачы әле генә сүзләре яңгыраган шагыйрьләрнең үзләрен күрә, аларның яңа шигырьләрен тыңлый. Сибгат Хәким, Әнвәр Давыдов көчле рухлы шигырьләре белән залны бер тетрәтеп алалар. Композитор Фатхрахман Әхмәдиев үзенең киң таралган көйләре белән күңелләрне тибрәндерә. Гариф Гобәй коръән серләрен ачып сала. Әмирхан Еники оста язылган кыска хикәяләрен укый. Арабызда иң яшь язучы Рөстәм Кутуй фәлсәфи шигырьләре белән залны уйга калдыра. Гази Кашшаф герой шагыйрь Муса Җәлил турында истәлекләр сөйли. Драматург Риза Ишморат Володя Ульяновның революция юлында беренче адымнары турындагы әсәреннән өзекләр укый. Хәсән Туфан шигырьләре Леонид Хаустов тәрҗемәсендә русча яңгырый. Риза Халид шигырьләренең кырымча яңгырашын тынлап, музыкасын тоеп утырасың. Ленинград шагыйрьләре Майя Борисова, Елена Вечтомова, Бронислав Кежун, Владимир Торопыгин һ. б. татарчадан тәрҗемәләрен укыйлар.

Тәнәфестә китап сәүдәсе, автографлар, танышулар, сөйләшүләр... Тукай, Такташ, Муса Җәлил, Фатих Кәрим әсәрләренә, җыр китапларына да автографлар куелып



Ленинград А. С. Пушкин һәйкәле.

[1] Гомумән, кичәләрне башлап җибәрү церемониясе озаккарак сузыла иде бугай, безнең йөрәкләр леп-леп тибә башлый. Татарстан Язучылар союзы председателе Мирсәй Әмир килеп җиткәч, бу церемония тагын бер дистанциягә артты. «Безнең» диюемнең нигезе бар. Әллә мин генә шулай дулкынланам микән дип уйлый идем баштарак. Бүтәннәрнең дә күңеле тыныч түгеллеген белдем. Кичәләрнең берсен ачып җибәрү церемониясе барганда, Сибгат абый миңа мөрәҗәгать итеп, Әхмәт Ерикәйдән валидол сорап алуымны үтенде. Әхмәт абый «Миңа да калдырсын», дип, пыяла колбасын сузды. Янымда утыручы Ленинград шагыйрәсе Елена Вечтомовадан бу даруның нинди авырудан икәнлеген сорадым. Ул йөрәгенә күрсәтте. Шулай итеп, һәр кичәне башлап җибәрү алдыннан безнең йөрәкләр сынала иде.

бетте. Кичәләр 3—4 сәгатькә сузыла, тәмамлангач дигәч тә эле язучыларны урап алалар, Татарстан турында, әдәбият проблемалары турында сорашалар, сөйләшәләр, кунакка чакыралар, адреслар алмашалар.

Көндез Ленинградның истәлекле урыннарына экскурсия яки предприятиеләрдә чыгыш. Революция традицияләре белән данлыклы Киров (элекке Путилов) заводында чыгыш бик истәлекле булды. Монда без, өч төркемгә бүленеп, цехларга таралдык. Чыгышлар татарча да, русча да барды. Төркемнәргә бүленсәк тә, билгеләнгән бер сәгать вакытка сыя алмадык — тыңлаучылар һаман сорадылар. Завод җитәкчеләре соңыннан әйттеләр: хезмәт дисциплинасын бозып, конвейрларны туктатып торырга мәҗбүр булганнар.

Кронштадтка бару — үзе бер онытылмас вакыйга. Көн җилле, яңгырлы иде. Шулай булырга тиеш итеп кабул иттек без моны. Җилсез, дулкынсыз диңгез — диңгезмени! Кронштадтта көне буе булдык, өч тапкыр чыгыш ясадык. Таякның авыр башы җырчыларга төште бу көнне. Моряклар бик риза булып калдылар. Кайту төн урталарына кадәр сузылды. Башка көннәрне дә гостиницага төнге уникеләрсез кайтып керә алмый идек. Һәм һәр көн диярлек кичке ашсыз калабыз. Бу юлы да кичке аш турында сүз кузгалып куйды. Безнең белән барган шагыйрь Олег Шестинский Хаям сүзләрен искә төшерде: «Иртәнге ашны үзең аша, төшке ашны дустың белән бүлеш, кичке ашны дошманыңа бир». Безнекеләр көлешеп алдылар: Ленинградта безнең дошманнарыбыз юк шул, дусларыбыз гына.

Автобустан төшеп, ресторанның инде ябык икәнен белгәч, элеге җырны көйләп, номерларга таралыштык:

Башка берни дә кирәкми...

## Иске танышлар

Безнең өчен иң куанычлы нәрсә шул булды — Ленинградта татар әдәбиятының дуслары күп икәнлегенә торган саен ныграк ышана бардык. Бер кичәдән икенче кичәгә йөрүчеләр күп иде. Кичә башланганчы ук килүчеләрне күздән кичереп чыгам: «иске» танышлар бармы? Алар һәр кичәдә була. Залда утыручылар арасыннан кемне дә булса тапмасаң, юксынып та куясың. Ә ул соңлап булса да килеп керә. Башкорт кызы Гадилә Хуҗәхметова, сәламәтлеге бик шәптән булмаган пенсионер Ахметшин Миңлеәхмәт, тимер юлчы Туктаров Ибраһим, опера-балет театры биючесе Рөстәм Садыйков һәм йөзләре генә таныш булган тагын бик күпләр бер кичәне дә диярлек калдырмый йөрделәр. Туган якларны, туган телне сагыну билгеседер инде бу.

Муса Җәлилгә багышланган кичә иң уңышлы кичә булды. Менә кем кеше күңелен бөтенләй билләп ала да, аны үзе теләгән якка ияртеп китә. Тамашачы Җәлил сүзләренә язылган җырларны йотылып тыңлады. Рус шагыйрьләре Мусага багышлаган шигырьләрен укыдылар. Ахырда кочегар Гәбделшакир сәхнәгә үзе ясаган Муса Җәлил бюстын китереп куйды. Гади кешенең герой шагыйрьгә булган тирән ихтирам билгесе иде бу.

Ленинград татарлары өчен Казан кунакларының килүе зур вакыйга булды. Татар үзешчән түгәрәгендә катнашучылар өчен бу вакыйга бәйрәмгә әверелде. Үзешчән түгәрәк членнары безне ике мәртәбә программадан тыш чакырдылар. Түгәрәкнең җитәкчесе Абдулла Хучашев турында нинди генә мактау сүзе әйтсәң дә, аз булыр төсле. Ул үзе баянчы, үзе биюче, үзе җырчы — бер сүз белән әйткәндә, сәнгать түгәрәгенең җаны. 1965 елның маенда Абдулла инициативасы белән оештырылган түгәрәкнең бер еллык юбилеен билгеләп үткәннәр. Баштарак репетицияләр өчен тулай торакларда, квартираларда җыела торган булганнар. Бүлмә алыр өчен Абдулла, хезмәт хакына зур зыян китереп булса да, коммуналь торак хуҗалыгына эшкә кергән. Анда үзләренә кызыл почмак булдыруга ирешкәннәр. Ульяна Громова урамы, 6. Менә шул кызыл почмакка безне чакырдылар да инде. Монда шимбә, якшәмбе көннәрне һәм бәйрәм саен кичәләр була икән. Узган җәйне ачык мәйданда беренче тапкыр сабан туй уздырганнар.

Без килгәндә зал шыгрым тулы иде. Кунаклар белән бергә хуҗалар чыгыш ясадылар, җырчылар, уенчылар, биючеләр үз осталыкларын күрсәттеләр. Әдәби-музыкаль кичә чын мәгънәсендә татар сәнгате бәйрәменә әйләнде. Шунда ук консультация дә бара. Рәисә Билялովадан кызлар яңа җыр өйрәнәләр, Фатхрахман Әхмәдиевтан нота күчерәләр, пианистка Назнинә Сабитовская инженер Наил Юсуповның яңа көен тыңлый. Шигырь сөючеләр үз шигырьләрен укып күрсәтәләр, шунда ук киңәш алалар. Ә зал уртасында ду китереп биләр, оста биючеләр берсен берсе алмаштырып кына торалар, аякларына күз иярми. Ул арада булмый, бөтен залны үз артыннан ияртеп, Эмил җыр башлый, үзе үк дирижерлык итә. Консультация алучыларның да, консультация бирүчеләрнең дә түземлеге җитми, эшләрен куеп, җырга кушылалар. «Кайтам инде», «Сиреньнәр хуш ис тарата», «Сарман», «Җаныем, бәгырем» һәм башка җырлар Ленинград күген таңга кадәр яңгыратып торды.

— И, бар иде бит заманнар, «Сарман»нан бүтән татарча җыр белми идек, — диләр кичәдә катнашучылар.

Хәзер Казан белән элемтә көчәя бара. РСФСРның атказанган артисткасы Зөләйха Хисмәтуллина килгәч, берничә яңа җыр өйрәнеп калганнар. Илһам Шакиров группасы килгәч, шундый ук кичә үткәргәннәр. Илһам бер дә кыстатмыйча бик күп һәм бик илһамланып җырлаган, яңа җырлар өйрәткән.

Бу үзешчән түгәрәккә ярдәм итүчеләр күп. Консерватория студенты Сәгыйт Хәйбуллин хор түгәрәге белән җитәкчелек итә. Актриса Разия ханым Садыйкова җырчыларга консультация бирә. Ә биючеләрнең осталыкларында, һичшиксез, опера-балет театры биючеләре Рөстәм Садыйков һәм Гомәр Сәйфуллиннарның эше күренә. Концертларны инженер-конструктор Рифкать Шингареев алып бара. Аның репертуарында Һади Такташ, Муса Җәлил, Әхмәт Исхак, Шәүкәт Галиев, Гамил Афзал шигырьләре. Азия халыклары институтының гыйльми сотрудникы Сәйфи Муратов, Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәнең СССР халыклары бүлеге мөдире урынбасары Энҗе Кәримовна Сәгыйдова, полковник, шагыйрь Риза Халид — монда үз кешеләр. Бу клубта бар нәрсә дә җәмәгатьчелек тәртибендә эшләнә.

## Зәңгәр ут

Декаданың программасы үтәлеп, официаль йомгаклау кичәсе булганнан соң, ленинградлылар безне тагын бер саубуллашу кичәсенә — «Зәңгәр ут»ка чакырдылар. Бергәләп сөйләшәсе сүзләре, бергәләп җырлыйсы җырлары бар икән. Үтенечләрен кире какмадык, кайтуны бер көнгә кичектердек.

«Зәңгәр ут» яктысына 200 ләп кеше килгән. Монда инженерлар, эшче яшьләр, студентлар, врачлар, артистлар, гыйльми һәм хәрби хезмәткәрләр бар иде. Күбесе иске танышлар, күпләре белән шушы кичәдә таныштык. Зәкия һәм Габделхак Сәйфуллиннарның йөзләре таныш булса да, үзләре белән шушы кичәдә белештек. Зәкия ханым — балалар врачы. Бу мөлаем ханымның аналык хисләре бөтен кичәгә нур чәчеп торды. Ул һәркемне якыннан белә, тормышлары, семья хәлләре, укулары турында сораша, үз итеп киңә шелтәләп тә ала. Бигрәк тә студентлар Зәкия апаларының кайгыртуына мохтаҗлар төсле.

Халыкның байтак булуына да карамастан, кичә бер дус семья табынына охшый иде. Бернинди программасыз, игълан итүсез җырлар җырланды, шигырьләр сөйләнде, фикерләр әйтелде. Моңа кадәр булган кичәләрдә кунаклар сөйли, хуҗалар тыңлый иде. Бу юлы сөйләшү аңгәмә төсен алды. Гел тыңлап кына утырган кеннәрдә хуҗаларның әйтер сүзләре күбәйгән. Яшьләр арасында Рөстәм Кутуй шигырьләре буенча бәхәс кузгалды. Инженер Наил Юсупов фикеренчә, Рөстәм Кутуй «татар» дигән сүзне тамгалы сүз итеп китереп куя, үзенең татар булып тууына үкенгән кебегрәк тә тоела. Үкенергә бернинди нигез юк, ди яшь инженер, безнең горурланырлык кешеләребез, горурланырлык эшләребез башка милләтләрнекеннән һич аз түгел.

Инженер Барый Еникеев Кутуй шигырьләренең темасы кыю, фикере тирән булуын ошата. Аның рус телендә язуы милли рамкаларны киңәйтеп җибәрә, ди (йомгаклау кичәсендә инженер Әхәт Усманов та шул фикерне әйткән иде).

Тимер юлчы Ибраһим Туктаров Наил Юсупов белән бер фикердә. Алар, гомумән, Кутуй шигырьләренең тематикасына каршы түгелләр. Ләкин бу темага тирәнрәк өйрәнеп язылган, җитлеккәнрәк әсәрләр укыйсылары килә. Рөстәм Кутуй шигырьләрендә бала чак тәэсирләре сизелә, ә аның бит инде бала чагы узган.

Гомумән, милләт мәсьәләсен кузгатырга кирәк микән дигән фикер бар кайбер язучыларыбыз арасында. Безнең илдә какшамас милли дуслык урнашкан, шулай булгач, нигә үткәннәрдә казынырга?

Тормышта үз юлын, үз урынын тапкан хезмәт кешеләре арасында, безнең гади совет кешеләре арасында, милли аерма сизелми. Бала чактан без, төрле милләт вәкилләре, бергә уйнап, бер партада утырып, бер-беребезнең нинди милләттән булуын онытып үскән кешеләр. Бергә ирек яулаган, иңне иңгә терәп, илне дошманнан азат иткән көрәштәшләр арасында милли мәсьәләнең кузгалуы да мөмкин түгел.

«Зәңгәр ут»та катнашучылар татар язучыларына бик күп наказлар бирделәр. Татар тормышыннан тарихи әсәрләр юк, Татарстанның үткәне, феодализм чоры, татар милләтенең формалашуы турында әдәби әсәрләр котәбез, диделәр. Тукай һәм Муса Җәлил турындагы романнары өчен өлкән язучыларыбыз Әхмәт Фәйзи һәм Шәйхи Маннурның хезмәтләренә зур бәя бирделәр. Ә менә борынгы язучылар, галимнәр турында бер әсәрнең дә булмавы — татар әдәбияты өчен гафу ителмәслек нәрсә, диделәр. Иң мөһиме, бетмәс-төкәнмәс иҗади уңышлар теләделәр. Эшчеләр сыйныфы турында, республиканың йөзе булган Зур нефть кешеләре турында яхшы әсәрләр укырга теләүләрен әйттеләр. Рухны күтәрә торган, кешене зурайта торган, Ленин премиясенә күрсәтелгән әсәрләр исемлегенә керердәй әйберләр иҗат итүне теләп калдылар.

«Зәңгәр ут»ны кабызып җибәргән җыр авазлары кичә ахырында тагын яңгырап, таң нурлары белән барып тоташты. Җырга кушылмаган бер генә кеше дә юк иде. Монда — җырчы Эмил Җәләлетдиновның бөтен залны үз артыннан ияртә ала торган темперамент көче. Монда халык көенең күңелләрне берләштерә торган дәрте, моңы. Монда бөек Тукайның үз халкына мәхәббәте. Монда халыкның туган илгә, туган телгә булган мәхәббәт көче. Чөнки бу җыр:

И туган тел, и матур тел,
Әткәм, әнкәмнең теле...

———●———

Фатих Исхаков

# АНЫ КОМСОМОЛ ТӘРБИЯЛӘДЕ

*(Истәлек)*

**Аннан бирле күп еллар үтте. Күп нәрсәләр инде онытылган да. Шулай да якын дус, ялкынлы шагыйрь, ил каһарманы, татар халкының сөекле улы Муса Җәлил белән бергә эшләгән һәм бергә яшәгән елларда хәтердә калган вакыйгаларның кайберләрен генә булса да искә төшереп үтәсе, анын авыр сыйнфый көрәш елларында комсомолда шагыйрь булып үсүен, чыныгуын кайбер мисалларда күрсәтеп үтәсе килә.**

## БЕРЕНЧЕ ОЧРАШУ

1922 ел. Оренбург шәһәрендә татар яшьләре өчен ачылган халык мәгарифе институтына безнең волостьтан да укучылар җибәрергә булдылар. Безнең авыл комсомол ячейкасына өч урын бирелгән иде. Һәм менә без, элекке Самара губернасы Бугуруслан өязе Иске Кетлембәт авылының чабаталы өч малае кар катыш яңгыр явып торган салкын октябрь көннәренең берендә, җәяүләп, үзебездән 250 км ераклыктагы Оренбург шәһәренә чыгып киттек. Зур кыенлыклар, газап-михнәтләр белән килеп җитүгә, һичкайда тукталып тормыйча, ашыга-ашыга Татар халык мәгариф институтына, ул вакыттагыча әйтсәк, ТИНОга киттек. Ләкин кызганычка каршы, анда безне «Бик алган булыр идек тә, егетләр. комплект тулды шул», дигән сүзләр белән каршыладылар. Инде ни эшләргә? Кая барырга? Беребезнең дә кире борылып, авылга кайтасы килми иде. Тоттык та, туп-туры комсомолның губерна комитетына юнәлдек. Үзебезнен волость комсомол комитетыннан алган путевкаларыбызны күрсәттек, хәлебезне аңлаттык. Губкомолдан ТИНО җитәкчеләренә хат алып, яңадан институтка йөгердек. Хатның, әлбәттә, файдасы тиде: безнең өчебезне дә укырга алдылар. Завхоз торак бүлмәсен күрсәтеп, буш койкага урнашырга кушты. Мин кызыл сандыгымны күтәреп, кыяр-кыймас кына бүлмәгә кердем. Анда тәбәнәгрәк буйлы, елтыр күзле бер яшүсмер, аскы иренен бераз очлайтыбрак, нәрсәдер язып утыра иде. Ул миңа таба борылды да: «Сез яңа студент буласызмы әллә? Менә минем янда буш койка бар, рәхим итегез, урнашыгыз» дип, минем каршыма килде һәм, кулымдагы төенчекне алып, буш койка янына илтеп куйды. «Кем икән соң ул? Кечкенә булса да кыю сөйли, ярдәм итәргә дә нияте бар», — дип уйлап алдым мин.

Аскы катта звонок шалтырады. Озак та үтмәде, ишектән «Муса, Муса» дип шаулашып, студентлар килеп керде. Муса аларга минем яңа студент икәнемне әйтте. «Әле иптәшнең исем, фамилиясен дә белергә өлгерә алмадым, ягез булмаса, танышыйк», — дип, елмая-елмая үзе дә күреште, иптәшләрен дә минем белән таныштырды.

Звонок булгач, студентлар йөгерешеп аскы катка төшеп киттеләр. Без тагын икәү генә калдык. Муса минем тормышым, кайдан, ничек килүем белән кызыксынды, бертуктаусыз сораулар бирде. Озак көннәр җәяү килгәнне белгәч, ул: «Менә мин үзем дә Мостафа авылыннан 150 чакрымны чабатадан җәяүләдем. Ярый әле сез күмәк булгансыз, ә минем янда эт тә юк иде» дип, авыр сулап куйды.

Дәрестән соң яки ял көннәрендә Муса мине шәһәр урамнарына алып чыга, без урамнар буйлап сөйләшеп йөри идек. Ул үзенең авыр тормышта яшәвен, әтисенең яшьли үлүен, фаҗигале ачлык елларда ач йөрүләрен еш искә ала, күрсенә-күрсенә сөйли иде. Шулай бервакыт, шәһәр урамында интегеп йөргәндә, танышы очрап, Мусаны партия мәктәбенә урнаштырган. Ләкин зурлар белән уку аңа бик авыр булган. Бигрәк тә, мылтык тотып, каравылда торулар йончыткан. Партия мәктәбендә укып чыккангамы, Муса дөньяга карашы, политик мәсьәләләрне төшенә белүе ягыннан бездән күп өстен тора иде. Ул төрле катлаулы вакыйгалар турында дөрес фикер йөртә белә иде.

Ул шигырьләр яза икән. Язган шигырьләрен безгә дә укып күрсәтә иде. Аның ике җыентыгы бар иде, берсенең тышына «1918 ел», икенчесенә — «1919» ел дип куелган. Бу җыентыкларда энҗе бөртеге кебек матур почерк белән язылган шигырьләр, мәсәлләр, бер пәрдәлек пьесалар бар иде.

Муса ул вакытта ук мандолинада яхшы уйный иде. Аның бармаклары гына кылларны чиертеп калмый, бәтен тәне хәрәкәт итә. Кич урынга яткач та ул, мандолинасын кулына алып, моңлы көйләр уйнап ята иде. Аның бу гадәте соңгы елларда да дәвам итте.


Мусаның Оренбургтан Казанга китүе турында шик юк иде инде, тик кайчан китәчәге генә ачык билгеле түгел. Бер көнне, дәрестән чыгып торак бүлмәгә керсәм, Муса юк, ул киткән. Тумбочка өстенә: «Фатыйх дус, мин Казанга киттем. Сиңа уңыш һәм бәхет теләп Муса», дип язып калдырган запискасы гына ята. Шундый кешелекле, кешегә игътибарлы бер иптәштән аерылу авыр булды, билгеле. Мусаның танышу өчен биргән шигырьләр җыентыгы миндә калды. Ләкин мин аны саклый алмадым. Җыентык, кулдан-кулга йөреп, югалды. Берничә ел узгач, бу турыда Мусаның исенә төшергән идем. Ул үзенең язган әйберләрен саклап тота алмавын, инде берничә җыентыгының шулай югалуын әйтте. «Хәер, алар көч сынау өчен язган беренче әйберләр генә иде. Зур үкенечле түгелләр», дип куйды.

## МУСА ОРСКИДА

Казан рабфагын тәмамлагач, 1925 елның көзендә Муса янадан туган ягына, комсомолның Оренбург губкомына эшкә кайтты. Мәсьәләне ачыклау өчен, шуны әйтеп үтәргә кирәк. Ул вакытта губкомолда вак милләтләр бүлекчәсе мөдире булып Закир Рахманкулов эшли иде. Мин комсомолның Оренбург өязе комитетында инструктор идем. Без, Закир Рахманкулов белән губкомолда утырганда, ишектән Муса Җәлил килеп керде. Ул өстенә арты бөрелгән кара пальто кигән, башында шлем, аягында күн итек. Үскән, тазарган — егет булган. Муса Җәлил укуын тәмамлагач, туган авылына кайтып ял иткән. Хәзер югары уку йортына керергә дә мөмкин иде бит аңа. Ләкин аны практик эш — туган якның яшьләре белән бергәләп, яңа тормыш төзү эше — күчлерәк тарткан. Шуның өстенә, Муса әнисенә һәм сеңелләренә материал ярдәм күрсәтүне дә үз өстенә алырга теләгән. Губкомол Муса Җәлилне Орск өязе комсомол комитетына инструктор итеп билгеләде.

Муса белән сөйләшә-сөйләшә Совет урамы буйлап Урал елгасына таба барабыз. Комсомолның Оренбург өязе комитеты Урал елгасына якын бер йортка урнашкан иде. Бакчада утырып байтак сөйләштек. Муса Казанда ничек яшәвен, рабфакны уңышлы тәмамлавын сөйләде. Рабфакны тәмамлауга багышлап, Муса «Эшфак» исемендә инсценировка язган икән. Чыгару кичәсендә ул инсценировка сәхнәгә куелган һәм уңышлы гына чыккан, аны көчле алкышлар белән каршылаганнар.

Эшне белеп, асылына төшенеп, күңел биреп, яратып башкару Муса Җәлилгә хас сыйфатлардан иде. Муса Җәлил авыл халкының тормышы, комсомол ячейкаларының ничек эшләүләре, пионерлар хәрәкәте белән кызыксынды. Укомолга кергәч, минем эш планым белән җентекләп танышты. Планның аерым пунктларын блокнотына күчереп алды. Ул үз алдында авыр, җаваплы, катлаулы бурыч торганын яхшы төшенә иде. Комсомолның эш мәйданы бик киң иде ул елларда. Авылларда яңа ячейкалар оештырырга, яшәп килгәннәрендә комсомол членнарының санын үстерергә, аларны эшкә актив катнашырга өйрәтергә, политик тәрбия бирергә кирәк. Авыл яшьләрендә сыйнфый аң тәрбияләү, аларны сыйнфый дошман йогынтысыннан саклап калу, сыйнфый



М. Жәлил бер төркем иптәшләре арасында. Орск. 1926 ел.

дошманга каршы аяусыз көрәш — комсомол эшенең төп эчтәлеген тәшкил итә. Комсомол оешмалары Совет органнарына кулакларны үткәрмәү өчен, крестьяннар арасында җирне бергәләп эшкәртү ширкәтләре (товариществолар) төзү өчен көрәште. Авылда сәүдә эшеннән хосусый сәүдәгәрләрне кысрыклап чыгарып, кооператив оештыру, наданлыкны бетерү, клублар, китапханәләр ачу, мәктәп файдасына комсомоллар көче белән «уңыш десятинәсе» чәчеп, аларны урып-җыю һәм башка бик күп төрле бурычларны башкаруда комсомоллар актив катнашалар, җиң сызганып эшлиләр иде. Комсомолецлар, авыл укытучылары белән берлектә, яшь пионер оешмаларының эшенә җитәкчелек итteләр, спектакльләр куйдылар, әдәби кичәләр үткәрделәр. Безнең яшь шагыйрь, комсомолның җаваплы работнигы Муса Җәлил, югарыда күрсәтелгән бурычларны үтәүдә авыл комсомолецларына җитәкчелек итәргә, аларга юл күрсәтергә, аларны конкрет эшкә өйрәтергә тиеш иде. Шунлыктан Муса, эшкә дә бик җаваплы карап, алдан ук бөтен эш белән танышып баруны үз алдына бурыч итеп куйды.

Орскида Муса Җәлил муеннан эшкә чумды. Моны Мусаның губкомолга бик еш язып торган отчет хатлары, Орск укомолы работникларының аның турында биргән бәяләре һәм шагыйрьнең Орскида иҗат иткән шигырьләре ачык раслый. Ул, эшне башлап җибәрүе, авыл ячейкалары белән танышуы, ячейка булмаган авылларда ячейкалар оештыруга нигез салуы, яшь пионерлар хәрәкәтенең үсүе һ. б. мәсьәләләр турында сөйләп, күтәренке рухлы хатлар яза иде.

Бервакыт Муса Җәлилдән килгән хатны без бик зур кызыксыну белән, тәэсирләнеп укыдык. Мусаның бу хаты, әйтерсең, сокландыргыч бер повесть иде. Бу хатында ул казакъ авылларындагы эшләре турында яза. Аны бер авылдан икенчесенә үгез җигеп илткәннәр. Үгез хуҗасы казакъ сүзгә бик юмарт булып чыккан. Мусага ул казакъ күп кенә мәкальләр, әйтемнәр, җырлар өйрәткән. Муса аларны язып алган. Авылга барып комсомол ячейкасы секретарен эзләп тапканнар. Секретарь Мусага зур хөрмәт күрсәткән. Аны түр башына утырткан. Комган һәм сөлге китереп куйган. Муса ни эшләргә белми аптырап торганда, ячейка секретаре түрдә утырган килеш кенә Мусаның кул юа башлавын үтенгән. Мусага «бишбармак» ашатканнар. Ләкин, ахырга таба, Мусага шактый кыенлыклар күрергә туры килә бу авылда.

Авыл Советына сайлау үткәрү вакыты икән бу. Ул үзенең хатында авыл Советына членнар сайлау өчен көрәшнең өч көн дәвам иткәнлеген яза. Халык җыелышка бик теләп килгән. Кайсысы атка, кайсысы дөягә атланып килгәннәр. Ләкин авыл Советына ярлы һәм урта хәлле крестьяннарны үткәрү бик кыен булган. Бер ыругның ярлысы, икенче ыругның ярлысын якламаган. Киресенчә, күбесе үз ыругының баен яклаган. Муса Җәлил һәр ыруг ярлыларын аерым-аерым җыеп сөйләшкән. Аннан соң барлык ярлыларны бергә җыеп аңлаткан. Бары шушы озак көрәш нәтиҗәсендә генә авыл Советы составы хезмәт иясе крестьяннардан сайланган.

Муса хатларында кыенлыклардан зарланмады. Үзенең эшкә күнегүенә, авыл комсомолларының саны артуга, активлыклары үсүгә куанып бетә алмый иде.

1925 елның декабрендә татар, башкорт, казакъ комсомол активының губерна күләмендәге киңәшмәсе үткәрелде. Бу киңәшмәгә комсомол ячейкалары секретарьлары, пионервожатыйлар чакырылды, шәһәрдәге комсомол активы, укытучылар, балалар йорты тәрбиячеләре дә катнашты. Көн тәртибенә пионерлар арасында эшләү мәсьәләсе дә кертелгән иде. Бу мәсьәлә буенча доклад ясау Муса Җәлилгә тапшырылды.

Муса Җәлил докладын тирән эчтәлекле итеп, урыннардан күп мисаллар китереп ясады. Киңәшмәдә катнашучылар бу докладны зур игътибар белән тыңладылар. Докладын ул яшь пионерларга багышлап язылган бернечә юллык шигырь белән тәмамлады. Залда утыручылар докладчыны алкышлар белән озаттылар. Бу киңәшмәдәге делегатлар белән төшкән карточка хәзер дә миндә саклана. Анда Муса да бар.

Башка комсомол работниклары белән чагыштырганда, Муса Җәлил комсомолга икеләтә күбрәк өлеш кертте: чөнки бу эшкә ул үзенең каләм көче — шигырьләре белән дә хезмәт итте.

1926 елның августында комсомолның губерна комитетындагы вак милләтләр бүлекчәсендә мөдир булып эшләүче Закир Рахманкулов Казанга Комвузга укырга җибәрелде. Губкомол бюросы аның урынына мине билгеләде, ә Муса Җәлил комсомолның Оренбург өяз комитетына инструктор итеп билгеләнде.

## МУСА ОРЕНБУРГТА

Шулай итеп, Муса Җәлил Орскидан Оренбургка күчте. Озак та үтмәде, Мусаның әнисе Рәхимә апа һәм сеңелесе Хәдичә дә авылдан Оренбургка күчеп килделәр. Алар Урал елгасы аръягында (ул чакта бу тирә «Зауральная Роща» дип йөртелә иде) Хәммат исемле кешенең дачасы почмагындагы бер кечкенә агач өйдә яши башладылар. Әнисе һәм сеңелесе белән бергә тору Муса өчен бик күңелле һәм шатлыклы иде.

Мусаның әнисе Рәхимә апа йомшак күңелле, аз сүзле, бала җанлы, сабыр, уйчан бер ана иде. Ул балаларын күзалмасы кебек саклый, ярата, нинди генә вакыт булмасын, аларга ачык чырай белән эндәшә, кирәк булганда, бик осталык белән, юата белә. Мусаның да әнисенә һәм сеңелесенә мөнәсәбәте искиткеч әйбәт булды. Эш өстендә утырган чагы булса, эшен ташлап, ул йорт эшендә әнисенә булышып ала. Я утын яра, я су китерә, бәрәңге әрчи яки башка берәр эш башкара. Бу — бер караудa бер-берсен аңлый алучы, тату, эш сөючән, гадел, дус бер семья иде.

Урал елгасы аръягында торуның Муса өчен бер уңайсыз ягы, дөресен әйткәндә, куркынычрак ягы да булды. Ни әйтсәң дә, Урал аша чыгу белән — куе урман. Кайвакыт бюро утырышлары, җыелышлар озакка сузыла. Театр, киноларга йөрергә кирәк. Муса киноны бигрәк тә ярата иде. Ул: «Кино минем иҗатыма зур ярдәм итә», дия иде. Караңгы төннәрдә Урал елгасы аша чыгып, ялгыз өйгә кайту уңайсыз иде, билгеле. Муса миңа әнисенең бу турыда бик борчылганлыгын сөйләде. «Мин үзем шикләнмим, миңа кем тисен, тик әни бик борчыла, ә аның борчылуы миңа бик авыр. Әллә безгә күчәсеңме, бергәләп йөрү күңелле булыр иде»,— диде ул миңа. Билгеле, чит кешедә торганчы Муса белән бергә торуның минем өчен бик уңайлы яклары бар иде. Ләкин минем бу тату семьяны бер дә борчыйсым килмәде. Шулай да бу мәсьәләне без җиңел хәл иттек. Без күп вакыт Муса белән бергә булганга, соңга калган төннәрдә мин аның белән бергә барып, аларда кунарга булдым. Мин Мусалар семьясына тиз күнектем. Нәтиҗәдә, мин Мусаларга күчтем һәм без бергә яши башладык.

Урал, Сакмар буйлары күңелле бит. Бу елгалар борылып-борылып агалар һәм Оренбург тирәсендә, гүяки комлыкларда саегып кипмәс өчен, икесе бергә кушылалар. Без, яшьләр, ял көннәрен Урал буе болыннарында, әрәмәлекләрдә үткәрә идек. Ул елларда Салих Сәйдәшевнең яңа көйләрен көтеп ала идек. Муса бу күңел ачуларның үзәгендә була, үзенең шигырьләрен укый, мандолинасында яңа көйләр уйный.

Ул вакытта Оренбург эре промышленность үзәге булмаса да, шәһәрдә зур гына тимер юл мастерское, агач эшкәртү — «Орлес» заводы, тире заводы һәм тегермәннәр бар иде. Бу завод һәм фабрикаларда, аеруча тире заводы һәм Сакмар елгасы буендагы агач эшкәртүче «Орлес» заводында бик күп татар эшчеләре, шул исәптән татар яшьләре дә эшләде.

Муса, гәрчә аның турыдан-туры вазифасы булмаса да, завод-фабрикаларга да йөрде. Анда татар эшче яшьләре арасында культура-агарту эшләре алып баруда, политик тәрбия бирүдә зур ярдәм күрсәтте. Ул эшчеләр тормышы белән танышу, аларны өйрәнү белән бик кызыксына иде. Муса «Орлес» заводында еш була иде. Завод шәһәрдән шактый ерак булганга, соңга калган чакларда эшче яшьләр студентларны яки комсомол работникларын үз өйләрендә кундырып җибәрәләр иде. Муса Җәлилгә дә берничә тапкыр эшчеләр өендә кунарга туры килде. Шул заводка йөргәндә Муса, 1927 елда «Орлес» заводында» исемле шигырен иҗат итте.

Бер кызыклы вакыйга исемдә калган. Муса бер яшь эшче белән йоклап ятканда, завод иртәнге гудок кычкырткан. Болар икесе дә йокыларыннан уянып, сикереп торганнар. Менә шунда өй хуҗасы егет: «Шушы гудок тавышлары колактан тартып торгызгандай була», дигән. Һәр сүзгә игътибар итеп, аңа мәгънә бирүче шагыйрьгә бу яшь эшченең гудокны шулай сурәтләве бик ошаган. Ул заводтан кайткач, бу вакыйганы бик кызык итеп сөйләп, көләп йөрде. «Орлес» заводында» исемле шигыренең беренче вариантында гудок тавышы турында язганда «колактан тартып торгызгандай» дигән сүзләр дә бар иде...

Өстәлдә газеталар ята. Җәлилнең күзләре газетаның беренче битенә басылган бер текстка текәлгән. Иреннәре селкенә, йөзенә ачу билгесе чыккан. Шул рәвешчә бераз утыргач: «Шигырьгә тема табылды, мин китим әле»,— дип губкомолдан чыгып та китте бу. Әле хәзер генә Муса укып утырган газетаның чит ил хәбәрләре бүлегендә

Кытайда империализмга каршы көчле дулкын булып күтәрелгән милли-азатлык хәрәкәтенең басыла башлавы, Чан-кай-Шиның үз халкына хыянәт итеп, империалистларга сатылуы турында язылган иде. Трибун шагыйрь Муса Җәлил кыска гына вакыт эчендә, иптәшләрнең үтенече буенча, Чан-кай-Шига нәфрәт һәм кытай халкына теләктәшлек белдереп, «Еларгамы, көләргәме?» исемле шигырь иҗат итте. Концерт көнне бу шигырьне Муса үзе сөйләде. Шигырь залда утыручыларга нык тәэсир итте. Ләкин ул вакытта Муса бу шигырен «чиле-пешле» дип атады. Шунлыктан булса кирәк, ул шигырьнең текстын соңыннан бик нык үзгәрткән.

Муса Җәлил, шигырьләр генә түгел, хикәяләр, очерклар, төрле темага карата мәкаләләр дә яза иде. Ул вакытта Мәскәүдә чыга торган «Яшь эшче» журналына «Ил аралаганда» исемендә очерк язганы хәтеремдә. Партиянең Оренбург губерна комитеты каршындагы татбашбюро тарафыннан төрле бәйрәмнәргә, әһәмиятле вакыйгаларга багышлап бастырып таратылган аерым «сәхифә»ләрдә Муса Җәлилнең дә мәкаләләре басылып чыга иде.

Муса Җәлилнең «Авыру комсомолец» шигыре ул елларда татар яшьләренең бер юлдашы булды дисәк, һич тә хата булмас. Татар яшьләре генә түгел, Оренбург уку йортларында укучы башкорт һәм казакъ яшьләре дә «Авыру комсомолец»ны куен дәфтәрләрендә йөртәләр иде. Мусаның бу шигыре эшче-крестьян яшьләрен тәрбияләүдә, аларның революцион һәм сыйнфый аңын уяту һәм үстерүдә зур хезмәт итте. Бу шигырьне язып җибәрүне сорап, авыл комсомол ячейкаларыннан укомол һәм губкомолга хатлар килгәне хәтеремдә. Кайда гына, нинди генә концерт яки әдәби кичә үткәрелмәсен, «Авыру комсомолец» шигыре кичәнең программасында күренекле урын алып тора иде. Бу шигырьне ТИНО студенты Зиннәт Гапдерәшитов кебек сүз осталары яки Муса Җәлил үзе сөйләгәндә, зал тына, анда утыручыларның күз алдына үлемгә каршы көрәшүче, ләкин бирешмәгән, көрәштә чыныккан комсомолецның җанлы образы килеп баса. Тыңлаучыларның йөрәге сикерә, күпләр авыр сулыйлар, ә күзләрдән ихтыярсыз кайнар яшь бөртекләре тәгәри торган иде. Муса Җәлил бу шигырендә яшьләрне авыр көрәштә җиңелмәскә, иң авыр хәлдә калсаң да, үлем куркынычы янаса да, көрәшергә, җиңелмәскә чыныгырга чакырды. «Авыру комсомолец» Николай Островскийның «Корыч ничек чыныкты» романы белән бер үк дәрәҗәдә йөрде дисәк тә, әллә ни хата булмас дип уйлыйм. Ләкин, кызганычка каршы, Муса Җәлил иҗаты турында язучылар «Авыру комсомолец» шигыренең ул чордагы яшьләрне тәрбияләүдә тоткан роленә тиешле бәя биреп бетермиләр.

## МӘСКӘҮДӘГЕ КИҢӘШМӘ

1927 елда Оренбургта яз иртә килде. 1 Май бәйрәменә агачлар яфрак ярган, кырлар яшәргән иде инде. Икенче май көнне без Муса Җәлил белән Мәскәүгә киңәшмәгә киттек. Киңәшмәгә автономияле республикаларга кермәгән барлык губерналардан вәкилләр чакырылган иде. Мәскәү миңа таныш иде. Муса Җәлил исә Мәскәүдә беренче тапкыр. Барып төшеп урнашу белән Мавзолейга юнәлдек. Мавзолейдан чыгу белән, Ломоносов исемендәге университетның торак йортына киттек. Муса университетта укучы Гайшә Байчура белән хат языша иде. Университет торагында Гайшә Байчура һәм Гөлчәһрә Такташевалар безне бик куанып каршы алдылар. Гайшә елмаеп Мусага: «Кичә дәрестән соң кайтып керсәм, кроватьта чабата хәтле бер конверт ята. Синнән икәнен конвертыннан ук таныдым», — диде.

Чынлап та, Муса Җәлил хатларын, повесть язган кебек, кызыклы, озын итеп яза торган иде. Гайшә алган хатның конверты «чабата» хәтле зур булуының да сере әнә шунда булгандыр. Гайшә Байчура безне Тимирязев исемендәге авыл хуҗалыгы академиясенә алып барды. Үзенең анда укучы танышы Павлова белән таныштырды. Истәлек өчен дүртебез карточкага төштек. (Бу карточка Гайшә Байчураның истәлеге белән бергә «Азат хатын» журналында басылып та чыкты.)

Мәскәүдәге киңәшмәнең пленар утырышында Комсомол Үзәк Комитеты секретаре иптәш Косарев (Үзәк Комитетның беренче секретаре Чаплин иде) «Актив белән эшләү турында» доклад ясады. Аннан соң төрле милләт бюроларының аерым утырышлары башланды. Татар-башкорт бюросы утырышында урыннардан информацияләр мәсьәләсе буенча безнең дә докладны тыңладылар. Мин комсомолда тәрбия эшенең

торышы турында сөйләдем, ә Муса Җәлил пионер оешмаларының эше турында сөйләде. Бюро утырышы Оренбург губернасында яңалифчеләр хәрәкәтенең киң җәелүен, бу эштә комсомол оешмаларының актив эшләвен күрсәтте, башка губерналардагы татар, башкорт яшьләре арасында яңалифчеләр хәрәкәтен киң җәелдерергә кирәк дип тапты. Ул елларда татар, башкорт хезмәт ияләре «Урак-Чүкеч» исемендә самолет төзү өчен ихтыяри акча җыялар иде. Бюро утырышы шушы фондка акча җыюда Оренбург губернасы комсомолының актив эшләвен күрсәтеп үтте. Пленум Мусаны татар-башкорт бюросының члены итеп сайлады.

Киңәшмә үз эшен тәмам иткәннән соң, башкаланың татар клубында оештырылган бер әдәби кичәдә дә катнаштык. Мәскәүдә татар телендә «Эшче», «Игенчеләр» газеталары һәм «Яшь эшче» исемендәге журнал чыга иде. Клуб залы язучылар, редакция работниклары, укытучылар, студентлар белән тулды. Кемдер, хәтерләмим, кичәне ачып, яшь шагыйрь Муса Җәлилнең иҗаты турында сөйләде, һәм аның Мәскәүгә килүе уңае белән, бу кичәнең аның хөрмәтенә багышлануын әйтте. Муса белән без залда утыра идек. Президиум составы сайланды. Президиумга күрсәтелүчеләр арасында аның исеме чыгу белән, залдагылар гөр килеп кул чаптылар. Муса сәхнәгә юнәлде. Шул вакыт залда үзара пышылдау башланды:

— Кайсысы соң боларның Муса?

— Әнә, теге озын буйлы, күзлеклесеседер...

— Юк, юк ул түгел, ул яшь әле.

Ниһаять, Мусага сүз бирелде. Менә шул чак залда утыручылар тынып калдылар. Бәхәс тукталды. Тик кайберләре: «Һи, Муса Җәлил дигәннәре бик яшь икән ләбаса, буйга да кечкенә икән»,— дип утырдылар. Күрәсең, кайберәүләр инде әсәрләре белән яхшы ук танылган бу яшь шагыйрьне ничектер озын буйлы, пәһлевандай гәүдәле, күзлекле, җитмәсә тагын мыек үстергән бер кеше дип күз алдына китергән булса кирәк.

Бу очрашуда Муса үзенең күптән түгел язылган «Еларгамы, көләргәме?», «Орлес» заводында» һәм башка шигырьләрен сөйләде. Залда утыручылар шагыйрьне нык алкышлар белән каршыладылар һәм аны берничә тапкыр чакырып сөйләттеләр.

Нэп (яңа экономик политика)ның соңгы еллары иде бу. Шуны сизепмедер, нэпман-сәүдәгәрләр «Товар бәяләренә зур скидка ясала» дип, бәя төшерү процентларын ак полотноларга язып, кибетләренә элеп куйганнар. Муса белән икебез дә, яхшырак чалбар һәм күлмәк алу нияте белән, кибетләргә йөри башладык. Кибетләр зур түгел, тар, үзләре караңгы. Йөри торгач, бер кибеттә үзебезгә ошаган чалбарлар очраттык. Сәүдәгәр товарны бик мактый. Бер алдыбызга, бер артыбызга төшә. «Мондый товардан тегелгән чалбарны башка бер кибеттә дә таба алмыйсыз»,— дип тә җибәрә бу. Бәясе дә артык кыйбат түгел. Безнең кесәбезгә туры килә. Шулай да бераз сатулаштык. Икенче кибеттән икебезгә дә бертөрле күлмәк алдык. Ашыгып гостиницага кайттык. Башта, түземсезлек белән чалбар төргәкләрен чиштек. Яктыда чынлабрак карый башласак, ни күзебез белән күрик: без алган чалбарлар искедән әйләндереп тегелгән булып чыкты. Менә шунда без бот чабып көлештек. «Без ачык авыз, беркатлыларны менә ничек утыртты Мәскәү нэпманнары» диде Муса һәм шунда ук блокнотына:

«Нэпманнарның кибетләре
Рәт-рәт булып тезелгән,
Сата торган чалбарлары
Әйләндереп тегелгән,
Яктыдарак карасаң
Җепләре дә өзелгән»,—

дип шигырь дә язып куйды.

Соңыннан, очрашкан саен, бу вакыйганы искә алып көлешә торган идек.

Оренбургта эшләгән чорда Муса Җәлил еш кына авылларда йөри, үзе әйтмешли, «ил аралый», тормышның эчендә кайный иде. Менә шул тәҗрибә аның иҗатын үстерүгә зур ярдәм итте. Комсомолның губерна конференциясе Муса Җәлилне Губкомолның пленум члены итеп сайлады. Ләкин Муса Җәлил Оренбургта озак эшли алмады. 1927 елның август аенда ул Мәскәү университетына укырга китте. Без, Оренбург яшьләре, Муса Җәлилне укуында һәм иҗатында зур уңышлар теләп озаттык. «Олы корабльгә — олы юл, сина да, кадерлебез Муса, олы юл телибез»,— дидек без аңа.

# «АЛМАН ИЛЕНДӘ» ШИГЫРЕ ТУРЫНДА КАЙБЕР ФИКЕРЛӘР

«Алман илендә» шагыйрь иҗатында зур һәм күренекле роль тоткан әсәрләрнең берсе. Бу шигырь, көчле һәм зур әдип булуы белән бергә, М. Җәлилнең бөек гуманист, интернационализм идеяләрендә тәрбияләнгән ленинчыл коммунист булуы турында да сөйли. Кызганычка каршы, М. Җәлилнең әлеге шигъри әсәренә патриот шагыйребезгә багышланган күп санлы китап һәм мәкаләләрдә аз урын бирелә, әсәрне аңлатуда, русчага тәрҗемә итүдә төрле хаталар, төгәлсезлекләр белән дә очрашырга туры килә.

М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләрен» беренче мәртәбә дөньяга чыгаруда, аның иҗат мирасын һәм немец тоткынлыгындагы тиңдәшсез батырлыгын өйрәнүгә күп көч куйган Гази Кашшаф, без тикшерә торган әсәренең язылу тарихына тукталып: «Язучы конспирация өчен Германияне гарәпчә «Алман иле» дип атый» ди. Шушы аңлатма шагыйрьнең күп кенә татарча һәм русча басмаларында да кабатланып килә[1].

Дөрес, гарәпләр немецларны а л м а н (ألمان) диләр[2]. Ләкин гарәпләр генә түгел, Германиянең көнбатыш, көньяк-көнбатыш, төньяк-көнбатыш күршесендә күптәннән бирле һәм хәзер дә германлыларны а л м а н н а р дип йөртәләр. Моны раслау өчен, күп чыганаклардан кайберләрен китерү житсә кирәк.

Ф. Энгельс үзенең «Франкский диалект» дигән әсәрендә һәм бу әсәрдә китерелгән картада алман атамасын куллана[3].

Акад. А. В. Щерба һәм М. И. Матусевич тарафыннан төзелгән «Русча-французча» сүзлектә һәм урта мәктәпләр өчен чыгарылган тарихи карталарда һәм башка чыганакларда без A l l m a n i дигән атаманы очратабыз.

Димәк, шигырьдәге « а л м а н » сүзе конспирация өчен генә кулланылган дип аңлату дөреслеккә туры килеп бетми. Конспирация өчен генә булганда, М. Җәлил исемнәрне дә (К. Маркс, К. Либкнехт, Р. Люксембург, К. Цеткин, Э. Тельман, Гейне, Гете, Бетховен) турыдан-туры атамас, башкачарак бирер иде.

М. Җәлил Германияне германлылар иле дип ала, шуңа күрә шигырьнең исеме дә «Алман илендә».

Безнеңчә, шигырьне матбугатка чыгаручылар тагын бер хата җибәргәннәр: әсәрнең җиденче куплетында Э н г е л ь исемен Энгельс дип алмаштырганнар[4]. «Алман илендә» Муса Җәлил Энгельс турында әйтми, ул С. Энгельны искә ала. 20 елларда комсомол сафында булганнар бу исемне яхшы беләләр. МОПР оешмасында актив

---

[1] Муса Джалиль. Избранные стихотворения и поэмы. Рус телендә. Мәскәү, 1955 ел. Муса Джалиль. Мои песни. Стихи. Рус телендә. Мәскәү, 1956 ел; М. Джалиль. Сочинения. Рус телендә. Казан, 1962 ел һ. б.

[2] Кара: Арабско-русский словарь. Сост. проф. Х. К. Бариков. Госиздат иностр. и нац. словарей. М. 1957, стр. 48.

[3] К. Маркс и Ф. Энгельс. Сочинения (2 изд). Рус телендә. 19 том, 518—546 битләр.

[4] Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. Том 2. 170 бит.

катнашкан, комсомолда җитәкчелек эшендә булган М. Җәлил өчен дә бу исем билгеле һәм кадерле.

Самуил Энгель (1904—1924) Польша комсомолының активисты. Ул 1924 елда немец агентын, провокаторны үтерә. Шуның өчен Польшаның полевой суды бу ялкынлы революционерны атарга хөкем итә. Безнең уебызча, «Алман илендә» шагыйрь менә шушы патриотны искә ала.

Икенче бер күренекле шагыйребез Ф. Кәримнең 1930 елда язган «Яшьләр көне» дигән шигыре бар. Анда ул:

«Мин бу көндә
Барлык комсомоллар
Исеме белән телим бирергә:
Польша комсомолын поляк дими,
Иптәш Энгель диеп йөрергә»[1],— ди.

Моның белән Ф. Кәрим, ә аннан соң М. Җәлил дә, Энгель диеп бер шәхесне генә атамыйча, меңләгән Польша комсомолларын алалар, аларның геройлыгы белән сокланалар.

Муса Җәлилнең «Алман илендә» шигырен русчага тәрҗемә иткәндә (әсәр, гомумән алганда, матур һәм көчле, пафосын югалтмыйча тәрҗемә ителгән) әлеге куплет бөтенләй төшереп калдырылган. Димәк, тәрҗемәчеләр дә әлеге төгәлсезлекне сизгәннәр, шуның өчен ул куплетны төшереп калдырганнар, дип уйларга туры килә. Төгәлсезлек вакытында бетерелергә һәм патриот шагыйрьнең шигыре дөрес итеп, түбәндәгечә бирелергә тиеш:


«Кая соң сез, Гейне һәм Марксны
Тыңлап үскән мәгърур егетләр,
Алар бакчасында үскән гөлләр,
Вильгельм Телль, Энгель кебекләр?»

*Р. ТАҺИРОВ.*

---

[1] Ф. Кәрим. Әсәрләр. I том. Казан, 1954, 80 бит.

———◆———



Жəлил шəһəре.

# ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ЧИТ ИЛ МАТБУГАТЫ

*Муса Җәлилнең героик тормышы, көрәш һәм иҗат юлы белән кызыксыну торган саен үсә, арта бара. Аның әсәрләре күп телләргә тәрҗемә ителә, тормышы һәм иҗаты турында пьесалар, романнар, поэмалар, шигырьләр, монографияләр, мәкаләләр язылды һәм языла тора.*

*Муса Җәлилнең героик көрәш юлы һәм иҗаты белән хәзер инде күп кенә чит ил укучылары да шактый яхшы таныш. Чит ил укучылары М. Җәлил иҗаты белән беренче мәртәбә Мәскәүдә чыга торган «Совет әдәбияты» журналы аша таныштылар. Инглиз, немец, француз, испан, гарәп, поляк һ. б. чит телләрдә чыга торган бу журналның 1955 елгы 9 санында Мусаның тормыш һәм иҗат юлы турында зур мәкалә, һәм аның Моабит төрмәсендә язылган шигырьләреннән үрнәкләр китерелде. Соңыннан «Моабит дәфтәре»нә кергән шигырьләр чит илләрдә чыга торган төрле газета-журналларда һәм аерым китап булып та басыла башлады.*

*1957 елда Берлинда «Моабит дәфтәре» аерым җыентык булып чыкты. 1962 елны Лейпцигта «Моабит дәфтәре»нең икенче басмасы дөнья күрде.*

*«Моабит дәфтәре» соңыннан венгр, албан, чех, болгар, кытай һәм корея телләрендә аерым китап итеп чыгарылды.*

*Әсәрләре тәрҗемә ителгән, аерым китаплары чыккан телләрдә Мусаның тормыш һәм иҗат юлына багышланган күп санлы мәкаләләр басылган һәм басылып тора.*

*Ул героик көрәш алып барган илдә, Германия Демократик республикасында, Муса турында дистәләрчә мәкаләләр, тикшеренүләр басылды.*

*Шигырьләре журнал һәм газеталарда күп мәртәбәләр басылу белән бергә, Чехословакиядә аның иҗаты турында күп санда мәкаләләр басылып чыкты. Чех халкы Мусаны Фучикның туганы дип саный. Шулай ук Италия, Франция, Болгария, Польша, Венгрия матбугаты битләрендә Муса Җәлил турында шул ил әдәбият белгечләренең хезмәтләре басылып килә. Бу — Муса Җәлил иҗатының бөтен дөньяга тарала, билгеле була башлавы турында сөйли. Муса героик тормышы һәм ялкынлы иҗаты белән татар совет әдәбиятын бөтен дөнья аренасына алып чыкты.*

*Чит илләрдә Муса турында чыккан күп санлы мәкаләләрнең татар теленә әле аз өлеше тәрҗемә ителгән. «Казан утлары»ның бу санында моңарчы укучыларыбызга билгесез булган шундый берничә мәкалә һәм кайбер хезмәтләрдән аерым өзекләр урнаштырабыз.*

Ә. КӘРИМУЛЛИН.

## ПАЛАЧ БАЛТАСЫ АСТЫНДА ЯЗЫЛГАН ҖЫРЛАР [1]

Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» (Васлав Данек һәм Ярослав Кабичекнең чех теленә тәрҗемәсе. Шамил Махмудовның татар теленнән ясаган подстрочнигы буенча, Прага, «Свет Советы» нәшрияты, 1958 ел) үзенең рухы белән Фучик репортажы белән тәңгәл килә. Алар икесе дә палач балтасы астында язылган әдәби документлар...

Татар шагыйре һәм чех халкы героеның сугышка хәтле үк, художник буларак, бик зур уртаклыклары булган. Алар икесе дә бик тыйнак, киң лирик күңелле, үз халыкларының фольклорын яратып үсәләр. 20—30 еллардан алып әсирлеккә төшкәнче һәм әсирлектә коточкыч шартларда да алар табигый рәвештә совет халкының героизмына ышандылар. Бу героизм җиңүгә китерде.

---

[1] Мәкалә «Literat. noving»ның 1959 елгы 4 саныннан алынды. Чех теленнән Ә. Кәримуллин тәрҗемә итте.

Хәрби әсирләрдән легион оештырып, фашистлар аны Совет халкына каршы сугышка җибәрделәр. Ләкин Муса Җәлилнең легионда алып барган аяусыз тырышлыгы аркасында, легиондагы әсирләр, баш күтәреп, фашист башлыкларын үтереп, партизаннарга кушылдылар.

Совет язучыларының икенче съездында Муса Җәлилнең батырлыгына тиешле югары бәя бирелде. Шагыйрь исеме кабахәт яла ягулардан чистартылды. Җәлилнең «Моабит дәфтәре» аның әсирлектә, төрмәдә алып барган поэтик көндәлек дәфтәре ул.

Аны укыганда шагыйрьнең нинди газаплар кичүен аңлавы читен түгел. Үлем алдында, таш капчыкта газапланучы шагыйрьнең шундый ирекккә чакыручы оптимистик җырлар яза алуына сокланмый кала алмыйсың. Ул бөтен рухы белән туган иленең кайнар патриоты, аның шигырьләре — Ватанының азатлыгы өчен көрәштә соңгы өлеше. Минә шуның өчен ул үлемнән курыкмый. Бу хакта күп сөйләргә мөмкин булыр иде.

Коммунист менә шулай үлә.

*М. ЧЕРВЕНКО.*

* * *

Фучикның дусты! [1] Муса Җәлилне без шулай атый алабыз. Дөрес, ул безнең геройбызны белмәгән. Ләкин аларның уртак язмышы, эшләре, үлем аша төрмә рәшәткәләре арасыннан киләчәк буыннарга җибәргән посланиеләре белән уртаклыгы — Фучик белән Җәлилне дуслар дип атарга хокук бирә.



ПОЕТ — ГЕРОЙ

15 години от гибелта на Муса Джалил

Муса Джалил е от онея творци, които, слели литературното дело с живота си, обличат своето име с неувяхващия венец на безсмъртието. И животът, и стиховете на поета-герой са проникнати от безпримерно родолюбие и жертвоготовност в името на свободата, от несразима вяра в победата на комунистическите идеи.

Муса Джалил

Моите песни

Песни, в душата ми никнехте вие,
в моята родина цъфтите сега.
Колко надежди и жар всяки крие,
колко живот ми е даден в света!

Влях ви аз моето вдъхновение,
пламенни чувства и топли сълзи.
Ако умрете — умирате с мене,
ако живеете — с вас ще съм жив.

В песен сърдечния зов се отлива,
заповед, воля народна е тя.
Простата песен другарят обиква,
в бой побеждава врага песента.

Радости низки, дребничко щастие —
аз се присмивам над тях, не скърбя.
Моята песен е правда и страсти —
туй, за което живея, горя.

С моя дъх сетен в килиите тесни
клетвата аз ще напълня със чест:
пях за родината радостни песни,
давам за нея живота си днес.

Пях аз напролет под белите вишни,
в бой за родината пях вдъхновен.
Ето че сетната песен днес пиша,
чувствайки брадвата вече над мен.

Волната песен ме прави свободен,
учи — да падна в борбата без скръб.
Песен бе моят живот сред народа,
песен да бъде и мойта смърт!

26 юни 1943 г.

Превел от руски: Вл. Голев

Ще забравиш


1943 г.

Превел от руски: П. Стефанов

Болгария газеталарының берсендә М. Җәлилгә багышланган сәхифәнең фотокүчермәсе.

---

[1] Муса Җәлилнең 1958 елда Чехословакиядә чыккан «Моабит дәфтәренә» язылган рецензиядән өзек. «Mlado fronta»-ның 1958 ел 12 октябрь санында басылган. Чех теленнән Ә. Кәримуллин тәрҗемә итте.



Берлин. Плетцензее төрмәсе. М. Җәлил һәм аның иптәшләрен шушы төрмәдә җәзалап үтергәннәр.

**Кем генә Җәлилнең шигырьләрен укымасын, ул һәркемгә якын. Аның шигырьләре һәркемнең күңеленә үтеп керә. Хрусталь кебек орылуга батылыр төсле, тулысынча мелодияле бу җырлар зур көч белән тулы. Бу кешеләр турында иң матур, иң кешелекле җыр түгелме соң?**

*ОЛЬДРИЖ КРИСТОФЕК.*

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ҮЛЕМЕ[1]

Берлинда Лертер вокзалыннан ерак түгел биек кирпеч стеналы бер караңгы йорт бар: бу — Моабит төрмәсе. Бу бина фашистлар власте чорында бөтен Европага дәһшәтле күләгә төшереп тора. Шушы төрмәнең бер юеш бүлмәсендә Эрнст Тельман интегә, шушы төрмәдән патриот-антифашистларны җәзага озатып торалар: алар арасында руслар, французлар, бельгиялеләр, украиннар һәм поляклар була.

1944 елның башында газ машинасына охшаган караңгы, ябык автомашинада үлемгә хөкем ителгән бик күп тоткыннарны Моабит төрмәсеннән алып китәләр, шулар арасында бик алҗыган, ләкин нык кыйналуга карамастан, рухи көче сынмаган, ягымлы чырайлы, үткен карашлы бер кеше дә була. Бу — үзенең бөтен мәхәббәтен поэзиягә, тормышка, кешеләргә багышлаган татар шагыйре Муса Җәлил иде.

Эсэсовчылар, көчле сак астында, үлемгә хөкем ителгән тоткыннарны машина белән Плетцензее төрмәсенә китерәләр, биредә фашист-палачлар үзләренең явыз эшләрен башкаралар. Һәм шунда Муса Җәлил дә җәзалап үтерелә.

[1] «Tribüne»нең 1957 ел 9 март санында авторсыз басылган мәкаләдән өзек. Немец теленнән Ф. Ганиев тәрҗемә итте.

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ «МОАБИТ ДӘФТӘРЛӘРЕ»[1]

Татар шагыйре Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» исемле шигырьләр җыентыгы турында гади сүзләр белән тенә сөйләп булмый. Аның шигырьләрен шигырь белән генә тәбрикләргә була: Германиягә мәхәббәт белән караган, ә немецлар тарафыннан җәзалап үтерелгән шагыйрьне тантаналы итеп котлаганда, бу — бердәнбер дөрес юл булыр иде. Аның язмышы фашистлар геополитигының нацистлар тарафыннан үтерелгән батыр улы Альбрехт Һаусһофер язмышына охшаш. Альбрехт үлгәннән соң, аның кулында да үзе язган «Моабит сонетлары»н тапканнар. Ләкин, төрмә ишегендәге кечкенә тишек аша үтеп кергән зәгыйфь яктылыктан файдаланып, үзләренен кыю шигырьләрен иҗат иткән бу ике шагыйрь бер-берсенә һич тә охшамаганнар. Муса белән Альбрехтне, каршыларына рәхимсез үлем килеп баскан чакта очраштырып, «власть» турында үзара сөйләшү күренешен күз алдына китереп карыйк. Бу сөйләшү вакытында Муса Җәлил эшчеләр хакимлек иткән җирдә «власть» белән кеше рухы арасындагы каршылык ничек чишелә, шуны аңлатыр иде. Бу сөйләшү Муса өчен җинел булмас иде. Ул Советлар Союзын күрсәтә алыр иде. Бу вакытта Германиядә эш ничек тора иде? Әллә эшчеләр сыйныфы үз бурычын үтәми башлаган идеме? Фашист солдаты формасын киеп, Җәлилнең туган илен басып керүчеләр арасында эшчеләр юк идемени? «Алман илендә» исемле күңел тетрәткеч шигырендә («Алман» яшерену максатыннан чыгып кулланылган сүз) шагыйрь үзенең конфликтын тасвирлый. Ул да Һаусһофер шикелле үзен Шиллер, Гете һәм Гейне турындагы фикерләр белән юата. Ләкин болай үзен юату аны канәгатьләндерми. Ул, Германиягә мөрәҗәгать итеп, шикләнеп сорый.

Арагызда кем бар Цеткин улы,
Тельман егетләре кайсыгыз?

«Арагызда бармы шундыйлар?» — дип шигырьне тәмамларга булыр иде. Минем күз алдыма китерүем буенча, шагыйрь бу урынны соңыннан катгый итеп әйтү өчен бераз суза төшкән:

Төрмәләрне безнең ачыгыз!

Саф-саф булып тагын 19 нчы
Елгы төсле җырлап килегез.
Һәм күтәреп өскә уң йодрыкны,
«Рот-фронт» дип җавап бирегез.


һәм шигырьдәге сорау аның ачыну көчен түгел, ә бәлки, таләп көчен арттыру өчен кабатлана.

Арагызда кем бар Цеткин улы,
Тельман егетләре кайсыгыз?

Бу шигырь көрәшкә чакыра. Шагыйрь үзенең мәхәббәтен гимннарда түгел, бәлки шундый шигырьләрдә ышандырырлык итеп чагылдыра. Бу мәхәббәт бик нык сыналган, аның ни дәрәҗәдә көчле икәнен белү өчен Муса Җәлилнең немец телендә басылган, кулга алынганчы һәм кулга алынгач язган шигырьләрен чагыштырып карарга була. Башта Җәлил романтик җырлар яза. Бу шигырьләрдә шул вакытта бара торган сугышның дәһшәтләре чагылмый (Бу хәл «Чишмә һәм Сандугач» исемле озын шигырьдә дә күренә).

Җәлил ул вакытта совет солдатына кичерергә туры килгән иң ачы язмышка дучар була. 1942 елның июлендә комиссар Җәлил яраланган хәлдә немецларга әсирлеккә эләгә. Бу гына әллә нәрсә булмас иде. Ләкин Җәлилнең югары социалистик морале әледән-әле үз алдына газаплы сораулар куя: «Үз бурычымны үтәдемме мин?». «Кичер, илем» исемле шигыре бу газаплы борчылута җавап бирә. Юк, ул начар сугышмады, ул киләчәктә дә көрәшне дәвам иттерәчәк. Әсирлектә ул фашистларга каршы көрәш оештыра. Аның бу эшен ачалар һәм аны Моабит төрмәсенә ябалар. Шушы

[1] «Forum»ның 1957 елгы 21 санында басылган. Немец теленнән Ф. Ганиев тәрҗемә иткән.



Берлин. Моабит төрмәсе.

көннән башлап аның гомере үлем күләгәсе астында үтә. Ләкин төрмә аның ихтыярын сындыра алмый. Монда ул, тирән уйларын, үзенең хәле һәм гомумән тормыш турындагы фикер йөртүләрен, туган илгә бәйләнешле истәлекләрен чагылдыра торган шигырьләр белән берраттән, шулай ук әче нәфрәт шигырьләрен дә иҗат итә. Ул палачка болай дип мөрәҗәгать итә:

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.
Мәңен түгел, бары йөзен генә
Юк итәлдем синең сыңарның,
Һәм халкымнан кайткач шуның өчен
Мин тезләнеп гафу сорармын.

«Кандала» шигыре аның нәфрәтен тагын да ныграк чагылдыра. Кандала аның ачуын чиксез кабарта:

Һәм уйлыйм үзем: төрмә нигезен
Ватасы иде, сүтәсе иде,
Кандала итеп хуҗаның үзен
Тотасы иде, сытасы иде.

Бирелә «политика» кешеләрен генә үзенә тарта торган һәм аларга юнәлеш бирә торган хисләр генә чагылдырыла дип әйтү дөрес булмас иде. Җәлилдә политика кешесе белән шагыйрь арасында аерма юк. Социализм иле шагыйре менә шулай булырга тиеш тә. Җәлилнең шигырьләрендә чагылдырылган «карангы дөнья»дагы көрәше 1957 елда Ленин премиясенә лаек булды.

Үзем үлсәм, исемем, жырым үлмәс,
Ул яңгырар илнең кырында,
Сөйләп илгә торткын күңелләрдә
Чәчәк аткан дуслык турында.

*АДОЛЬФ ЭНДЛЕР.*

## АЧЫ НӘФРӘТ һӘМ КАЙНАР МӘХӘББӘТ

*(Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»ндәге шигырьләр циклына карата)* [1]

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә,
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хакыгыз!

Татар шагыйре Муса Җәлил менә шулай җырлый. Ул, намуслы, сугышчан тормыш юлы белән беррәттән, шигъри әсәрләре белән дә дан казанды. Муса үлгәннән соң унөч ел ярым үтүенә карамастан, безнең игътибарыбыз аның шәхесе белән бәйләнешле өч вакыйгага юнәлә:



# Flammender Haß und flammende Liebe

## Zu Mussa Dshalils Gedichtzyklus „Moabiter Heft"

**Hab euch gehegt und gepflegt,
meine Lieder,
mögt nun im Heimatlande gedeihn.
Groß wie die Freiheit, die in euch
siedet,
möge die Zeit eures Fortlebens sein!**

So singt Mussa Dshalil, der tatarische Dichter, der durch sein dichterisches Werk ebenso bedeutend ist wie durch sein bewußtes, kämpferisches Leben. — Drei Ereignisse sind es, die jetzt, dreizehneinhalb Jahre nach seinem Tode, unsere Blicke auf diese Persönlichkeit lenken: Die Verleihung des Lenin-Preises, die im April 1957 posthum erfolgte; die Verfilmung der letzten Jahre des Dichters, an der das Mosfilm-Studio zur Zeit arbeitet und deren Handlung im wesentlichen in Deutschland spielen wird; letztlich die erste deutschsprachige Auswahl aus Mussa Dshalils Lyrik, die der Verlag Kultur und Fortschritt in Übertragungen von Franz Leschnitzer herausgab.

Bereits in diesem schmalen Bändchen offenbart sich die ganze heroische Größe des Dichters, von dem wir bisher fast alle nur vom Hörensagen wußten.

Im Juli 1941 wurde Dshalil, bereits ein anerkannter Schriftsteller und Vorsitzender des tatarischen Schriftstellerverbandes, Soldat, erlitt im Sommer 1942 eine schwere Verwundung, kam in deutsche Kriegsgefangenschaft, organisierte dort eine Widerstandsgruppe, wurde verraten und nach einjähriger Haft hingerichtet. Während dieser letzten Monate seines Lebens entstand der Gedichtzyklus „Moabiter Heft", der erschütternd und mahnend seinen Schöpfer überdauerte als Krönung eines dichterischen und kämpferischen Lebens.

**Hat mein Gedicht stets zur Freiheit
erzogen,
fordert es jetzt meinen Tod als
Soldat.
Ist als ein Volkslied mein Leben
verflogen,
ruft als ein Kampflied mein Sterben
zur Tat.**

Es ist ein Zeichen der Größe Mussa Dshalils, daß sein grenzenloser Haß gegen den Hitlerfaschismus niemals den Glauben an jenes andere, bessere Deutschland verschüttete; denn er mußte vom Haß singen, damit jenes andere Deutschland wieder Wirklichkeit werden konnte. Sein Lied klingt so:

**Das lügst du, Henker: ich und
niederknieten!
Ward mir auch Kerker, Sklavenfron
zuteil —
nicht flehend, daß von euch mir sei
verziehen,
steh ich noch aufrecht, köpft mich
schon dein Beil.
Daß Scheusale wie dich aus euern
Reihen
ich hundert nur, nicht tausend
weggemäht,
das ist die bittre Schuld, die zu
verzeihen
mein eigen Volk ich auf den
Knieen bät.**

und auch so:

**Sag mir, dem Begeist'rung für
Goethe verliehn:
Kannt ich dich solcherart dazumal?
Die Sturmflut der Beethoven-
Sinfonien —
erschüttert sie nicht mehr den
Marmorsaal?**

Wir können heute des Dichters Haß verstehen; uns wird sein Gedicht jetzt — fünfzehn Jahre nach Stalingrad — Dshalils bezwingende Größe offenbaren. *U. D.*

«National-Zeitung»та М. Җәлил иҗатына багышланган мәкаләнең фотокүчермәсе.

[1] Мәкалә «National-Zeitung»ның 1958 ел 7 февраль санында чыккан. Немец теленнән Ф. Ганиев, Г. Мостафиннар тәрҗемә итте.

1957 елның апрелендә аңа Ленин премиясе лауреаты дигән мактаулы исем бирелә. «Мосфильм» тарафыннан шагыйрьнең соңгы елларына багышланган һәм вакыйгалар башлыча Германиядә барган нәфис фильм төшерелә; ниһаять, немец телендә Муса Җәлилнең сайланма әсәрләрен «Культура һәм үсеш» нәшрияты бастырып чыгара, бу әсәрләрне Франц Лешнитцер тәрҗемә иткән.

Шул кечкенә китапта шагыйрьнең бөек батырлыгы ачык чагыла. Моңа кадәр без аның турында бары ишетеп кенә белә идек.

1941 елның июлендә күренекле шагыйрь һәм Татарстан Язучылар союзы председателе Муса Җәлил армия сафына баса. 1942 елның җәендә ул каты яралана һәм әсирлеккә төшә, анда фашистларга каршы көрәш группасы оештыра, хыянәт аркасында кулга алына, бер ел төрмәдә утырганнан соң, җәзалап үтерелә. Гомеренең соңгы айларында шагыйрь «Моабит дәфтәрләре» циклын иҗат итә. Бу әсәрләр Муса Җәлил иҗатының һәм сугышчан тормышының үлемсез чәчәге булып торалар.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңгырар җыр булып.

Бу — Муса Җәлилнең бөек кеше булуы билгесе. Гитлер фашизмына каршы Муса Җәлилдә булган бетмәс-төкәнмәс нәфрәт һичкайчан да аның башка, яхшы Германиягә булган ышанычын юкка чыгармый.

Шулай дипме сине белә идем,
Гете белән шашкан чагымда?
Бетховенның кыю симфониясе
Ник яңгырамый мәрмәр залында?

Без бүген шагыйрьнең нәфрәтен аңлыйбыз, аның шигырьләре бүгенге көндә — Сталинградтан соң 15 ел үткәч — Җәлилнең тез чүкмәс бөек кеше икәнен күрсәтәләр.

*У. Д.*

# ХИМКИДА ҖӘЛИЛЧЕЛӘР

Химки (Мәскәү өлкәсе), илебезнең бик күп яңа шәһәрләре кебек, хезмәт белән кайнап яши торган порт каласы ул.

1964 елның февраль аенда безне — Гази ага Кашшафны һәм бу юлларның авторын Химки шәһәренә, 3 номерлы политехник мәктәпкә кунакка чакырдылар. 26 җәлилче шушы мәктәптә башта пионер булганнар, хәзер алар комсомолецлар.


Бу хәрәкәт ничек башланган?

1962 елда Арча мәктәбе балалары Химки шәһәренә экскурсиягә барган. 1963 елны Химки балалары Арчага юл тоткан, бару юлында алар Казанның матбугат йортына — Язучылар союзына керәләр һәм Муса Җәлил турында күбрәк һәм тәплерәк белергә теләүләрен әйтәләр. Герой шагыйрь турында материал туплау әнә шулай башлана. Тынгысыз балалар шагыйрьнең гомер юлдашы Әминә ханым һәм кызы Чулпан янында булалар; Уфага Рахманкуловка хат язалар, аның әтисе Җәлил белән бергә укыган кеше икән.

Җәлил хатирәсе, аңа булган кайнар мәхәббәт һәм горурлык хисе балаларны илебезнең күп төрле кешеләре, мәктәпләре, шәһәрләре белән дуслаштыра. Казанда чакта Химки пионерлары интернат мәктәптә торалар, шушы мәктәпнең художнигы, балаларның матур тойгыларын аңлап, аларга Муса Җәлил портретын бүләк итә.

Җәлилчеләр ГДРга язучы Эрих Миллерга хат язалар, ул яшь дусларына үз тәрҗемәсендә Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәреннән» дигән китабын бүләк итеп җибәрә.

Без килгәндә Химки җәлилчеләре үзләренең классына бик зур ике стенд һәм стена газетасы элгәннәр иде. Беренче стендта Җәлил тормышы: фотолар, төрле-төрле



«Муса Җәлил турындагы бу материалларны без озак җыйдык», — ди Юра Прозоров.



Яшь җәлилчеләр татар әдәбиятының бүгенге яңалыкларын да бирелеп тыңладылар.

газеталардан кисеп алынган материаллар һәм аның үз китаплары. Икенче стендта (монысы безгә аеруча дулкынландыргыч булып тоелды) — укучыларның Муса Җәлил әсәрләренә үз куллары белән ясаган иллюстрацияләре.

Класс старостасы Ася Павлова, укучы Юра Прозоров ничек материал җыюлары хакында сөйләделәр. Узган елны, ниһаять, алар классының Җәлил исемендәге класс дигән мактаулы исем яулап алуын әйттеләр. Класс бер генә «икеле» дә алмаган, бары отлично һәм яхшы билгеләренә генә укыган. Мактаулы исем шуннан соң гына бирелгән.

Наташа Дубавина Җәлил шигырьләрен яттан укыды. Тормышка әле яңа гына аяк баса торган яшь комсомолканың эчке бер ярсыну һәм Җәлилгә карата гаять зур ихтирам белән укуы барлык тыңлаучыларны дулкынландырды.

Аннары сүзне Гази ага Кашшафка бирделәр. Муса Җәлилне якыннан белгән язучының патриот шагыйрь тормышы турында, «Җыр йомгагын» илнең барлык республикаларыннан, Җәлилнең исән калган көрәштәшләреннән барып табу турындагы сүзләрен Химки җәлилчеләре тын калып тыңлады.

Бу көнне безнең өчен кызыклы бер сюрприз да булды. Очрашу инде тәмамланып килгән чакта, Химки мәктәбенә Арча җәлилчеләре килеп керде. Аларның Киевка, герой шагыйрь турында яңа материаллар эзләп барулары икән. Арча мәктәбе пионер вожатые Людмила Шипинаның бу хакта әйткән хәбәре укучыларны янә бер мәртәбә сөендерде. Химки комсомолецлары үзләренең якын дусларын шунда ук чолгап алып, сораштыра башладылар.

Мәктәп директоры Антонина Григорьевна Старухина кичәне тәмамлаганда болай диде:

— Үлгәннән соң да үлмәслек итеп яшәү турында әйткән Җәлил. Мин, педагог кеше, сәгатькә карап, без бу вакытны нәрсәгә багышладык, дип уйлап утырдым. Без бу вакытны иң кешелекле кешенең — Муса Җәлилнең якты истәлегенә багышладык. Рәхмәт сезгә, Гази Кашшаф, сез үзегезнең Җәлил турындагы зур һәм түземле эшегез белән безнең йөрәкләрне ашкынып тибәргә мәҗбүр итәсез. Татарстан язучылары оешмасына — Җәлил кебек буйсынмас җанлы олы шагыйрь тәрбияләгән оешмага — безнең кайнар рәхмәт хисләребезне тапшырыгыз.

*Г. АХУНОВ*




*Шәукәт Галиев*

# СӨЗГӘК ҮГЕЗ МАҖАРАЛАРЫ

### АЛТЫНЧЫ ӘКӘМӘТ

Халык: «Туа мөгез чыкмый—
Тора мөгез чыга»—дип,
Дөрес әйткән, әнә Хамис
Йөри мөгез чыгарып.

Сугышырга йомарланган
Зур йодрык кебек башы;
Һаваны да сөзеп йөри,
Пәке кебек карашы.

Әйтәләр дә: «Сүзенең дип,
Юк атасы-анасы»,
«Атасы» юк, ә «анасын»
Гел кабатлый баласы...

Торреодорлык булса булыр
Сөрхәнтәйдә өлешчә:
Дүрт аякланып баскан да
Үгез белән сөзешә...

Бер кавым шулай алышкач
Чамалар аңлашылды:
Хамис тыкырыкка шылды,
Күренеш алмашынды...

Кайсы якка сугылса да,
Мөмкинлекләр бик чикле;
Кагучысы шул бик шикле,
Ишекләр шуңа бикле.

Йөри торгач очрый Хамис
Бер ташландык коега.
Ахры кое, качар өчен
Җайлы булып тоела;

Атылып килә дә мүкле
Чылбырына тотына...
Сүз дә юк анысы, үгездән
Котылуын котыла,

Ә менә кое төбенә
Бик әйбәт кенә — гөмберт!
Бу эшне без бик хуп күрдек,
Рәхәтләнеп бер көлдек!

---

* Ахыры. Башы 1 санда.

Тынчыган кое төбенә
Төшкән икән — чукынсын,
Көндез йолдыз күренә ди,
Шуны санап утырсын.

Ә без Хамис кыйссасының
Җепләрен төйни торыйк;
Ни кылмышын, ни кырмышын,
Тормышын сөйли торыйк...

Үсте безнең күз алдында,
Мәгълүм һәрбер адымы;
Шундый иде әтисенең
Тәрбияләү алымы:

«Малай булса — үткен булсын,
Боевой булып үссен,
Үз дигәнен йолкып алсын,
Капкан җиреннән өзсен!

Шунысыз бит ул яшәп булмый,
Юаш булсаң, басалар.
Усал булсаң асалармы?
Асалмыйлар — качалар!

Җебегәннәр җебеп торсын,
Көчленеке замана!..»
Хамис шушы кодексны
Истә тотты һаман да.

Юаш малай-шалайларны
Ул акыртып кыйнады.
Үсә төшкәч, кыланышы
Мәктәпкә дә сыймады;

Сабыр сабакташларының
Йөрде ул башларыннан.
Алдан йөреп артта калды
«Дөнья юашларыннан»...

Җитте гомердә шундый чак —
Йодрык йомарлап кына,
Кызган баштан, кешеләрнең
Тешләрен барлап кына

Яшәп булмый башлый икән.
Ә теге «пешмәгәннәр»
Кай арада ВУЗ бетереп,
Кай ара эшләгәннәр?!

Шуңа Хамисның эчендә
Ут зурая башлаган,
Юньле кеше күргән саен
Үч кайтара башлаган.

Колак-борын тешләп кенә
Инде нича кермәгән —
Әвәрә булып беткән ул,
Сирәк кайткан төрмәдән.



Эш кырмаган, тәрәз кырган,
Сугышмыйча тормаган,
Күпме генә утырса да
Акылга утырмаган.

Әнә, тозлы сүзләр кила
Коедан тонык кына...
Авылдашлар сөйләшәләр
Еректан торып кына:

— Җебенсенме?
— Җебенсен лә!
— Коенсынмы?
— Коенсын!
— Коесы җәл түгел, әйдә,
Юньсезлеге коелсын!

Галәветдин бабай әйтә:
— Яшьләр бик бозылдылар...
Лотфи абзый:
— Тормыш яхшы —
Менә ник узындылар!

Миргалифан:
— Сәбәп бүтән —
Өркер нәрсә калмаган;
Курыкмыйлар райкомнан да,
Курыкмыйлар алладан!

Тимербулат:
— Абзыкаем,
Куркытып яки алдап
Тоткан заман — тю-тю,
Кеше
Яшәргә тиеш аңлап!

Шиһап:
— Җитеп бетми бездә
Политагарту эше.
Җәгъфәр:
— Мең ел каралган шул,
Бик тиз агармый кеше!

Хаҗи:
— Алайса коеда
Бусы агарсын әле,
Чыннач колак тынып торыр,
Кычкырып арысын әле!

Садыйк:
— Авыз ермагыз сез,
Ул да әдәм баласы,
Харап булганчы, җәһәтрәк,
Тартасы да аласы!

Тартуын тартып алды да,
Әмма әзрәк ялгышты —
«Нигә тизрәк алмадың!» дип,
Якасына ябышты...

Карап-карап тордык та без
Алдык үзен боргычлап,
Син күр, мин күр, шуннан бирле
Тора әле тынычлап.

Ни килешкәндер, тәгаен
Әйтер идек, белмибез —
Әллә кое, әллә үгез,
Әллә инде үзебез?..

## ҖИДЕНЧЕ ӘКӘМӘТ

Һәр кеше сата базарда
Товарын мактый-мактый.
Берсе биграк килештереп,
Биграк чая такмаклый:

— Алмасы да алмасы —
Яшь кызлар бит алмасы!
Тышы — шикәр, эче — бал,
Исме — алма, төсе — ал,
Алып җибәр, тизрәк ал!

Биграк оста сатучы бу,
Кырыкка бөгеләдер,
Ничек сөйләп, ничек көйләп
Һәм «чөйләп» өлгерәдер?

Үлчәвенең үрдәкләре
Чүгәләп биеп тора,
Алар да баш иеп тора,
«Рәхим ит!» диеп тора.

Тәмле телгә тартылганны
Сизмичә дә каласың,
Бармас җирдән барасың да,
Алмас җирдән аласың.

...Иртәгесен әллә инде
Сул ягы белән торган,
Әллә, әбиләр әйтмешли,
Төнлә җен алмаштырган?!

Акаеп кына карый ул
Уңга да сулга гына,
Гердәй авыр сүзләр белән
Ора да суга гына.

Сикереп кенә кунмый да,
Ырылдап кына капмый —
Гүя сиңа гомер бакый
Җан ачулары саклый.

— Абый, алмагыз кыйммәтме?
— Язган! Күрмисеңмени!
Сукыр түгелдер бит! Кара!
Укый белмисеңмени!

Нәкъ шомарган кибетче күк —
Алдың ни, алмадың ни...
Бу үзгәрешнең хикмәтен
Соңыннан аңладым мин;




Кичә саткан үзенекен,
Бүгенгесе — колхоздан.
Кичә эш эшләнгән, бүген —
Көн узганмы — көн узган...

Гыймран бу. Ләкин аңарга
Дәшмиләр «Гыймран» диеп,
Кушаматсыз заманда да
Йөртәләр «Йомран» диеп.


Үзе ул һәрчак муенын
Алгарак сузып йөри,
Мылтык төзәгән аучыдай
Бер күзен кысып йөри.

Копилка ярыгы төсле
Сыңар күзе — караңгы,
Дөньяга ул гомер буе
Йотам кебек каранды.



«...Актарган, ди ул, актарсын,
Лом белән, кәйлә белән,
Без яшик әмәлен белеп,
Җай белән, хәйлә белән!

Сүзләрне дә зирәк кенә,
Сирәк кенә кыстырыйк,
Җитәкчеләр сөйләгәндә
«Дөрес!» диеп кычкырыйк.



Активка да кертмәсеннәр,
Пассив дип сукмасыннар,
Бик күреп тә тормасыннар,
Күрми дә үтмәсеннәр.

Тормыш ул кирә кәҗә күк,
Бармый, белмәсәң җаен,
Кемнәр — йоклый, кемнәр — йолкый,
Дөнья бу, абзыкаем!



Белештерми чапкан аттай
Яна бирсен тиләләр,
Андыйларга ядрәләр дә
Иң әүвәле тиделәр.

Беркатлылар кайтса кайтты
Имгәнеп, канын коеп,
Без кайттык медальсез генә,
Әмма ләкин мал җыеп.

Инде колхоз диеп алар
Көне-төне чабалар,
Гыймран да хәрәсән түгел,
Гыймран үзен чамалар.

Булмаса — кеше бирәлми,
Булса — сине күрәлми.
Күмәк эшнең шунысы яхшы —
Син тартмый дип терәлми.

Бөкре чыгарган без түгел,
Белмәбез тормыш хутын,
Миңа — үгезе үлсә — ит,
Арба ватылса утын...

...Артта калды базар шавы,
Алда — авыл тынлыгы.
Каян гына килеп чыкты,
Аһ, бу гөнаһ шомлыгы!

Нишли дә алмыйсың, үгез
Биетә үз көенә,
Көреп качмак булып Гыймран
Йөгерә үз өенә.

Өе дә өе! — ДОТ кебек,
Тәрәзә — амбразура,
Имән капка, нарат коймә,
Мәңгелек абзар-кура.

Тоз белән корган мылтыкны
Ничек төбәү хакында
Һәм кая төбәү хакында
Әйтеп киткән хатынга.

Гыймран алты-җиде тапкыр
Әйләнә йорт тирәли,
Үгез кермәве шәп-шәбен,
Ләкин үзе керәлми.

Уй — тиз диләр, чаба Гыймран
Узып хәтта уйларын...
Шактый ураттыргач үгез
Биек коймә буйларын,

Мөгезенә эләп кенә
Чөйде дә атты тыштан!
Шытырт итеп кенә китте
Трофейный муртыштан.

«Шытырт»тан соң яңгырады
Колак яргыч «Шарт!»ы да,
Аяз көнне яшен суккан
Кебек булды артына.

Тимерчыбыкка эләккәч,
Төшмәк булып тартына;
Әңгер-меңгердә хатыны
Тагын өсти картына!

Форточкадан карап кенә:
— Шап булдымы? Йөрмәссез!
Үзе юк дип, алмаларын
Ботарларга кермәссез!

«Ай-вай... тоз...» дип, тыз-быз килеп
Йөри Гыймран котырып,
Әчетүгә чыдый алмый
Кычкыра торып-торып.

Утыра торган төштәрәк —
Шунсы бигрәк уңайсыз.
Кемдер әйтә, мондый нәрсә
Төзәлми ди ун айсыз.

Авылдашлар юаталар:
— Алай ук газап чикмә —
Тозың үзеңә булды ич,
Әрәм китмәде читкә!

## СИГЕЗЕНЧЕ ӘКӘМӘТ

Хәбәр булды Мәүлиягә
Күргәзмәгә барырга.
Җыелды ферма кызлары
Аны озатып калырга.

Үгезне күргәч, нигәдер
Куя куркып кычкырып —
Сыза кызый дусларының
Кочагыннан ычкынып...

Кузгалып китә машина,
Әлгерми кала үгез,
Чак-чак кына алдынгыга
Эләкми кала мөгез.

Мөдир алдында үгезнең
Абруе төшә язды,
Җенләнеп китеп Карибҗан
Мөгезен кисә язды:

«Мәүлияны сөзмәк була!
Ә бит ул безнең маяк!
Димәк, бу очракта мөгез
Безнең көпчәккә таяк!

Дөрес әйтәмме? Бик дөрес!
Мәүлия аркасында
Фермабыз һәм колхозыбыз
Гәҗитнең уртасында...»

Чыннан да ник карый үгез
Күзенең агы белән,
Ошамый башлаган аңа
Кыз кайсы ягы белән?

Элек бит күргән саен ул
Каршысына ашыккан,
Иркәләнгән, сырпаланган,
Мөгез төбен кашыткан.

Мәүлия бигрәк оялчан —
Авызыннан сүзе чыкмый.
Эш дигәндә, ут уйната —
Кулларь-кулга йокмый!

Бер сүз белән әйтсәк, кызкай
Эш өчен яратылган!
Вакыт тапмый, диләр, хәтта
Егетләр яратырга...

Тыныч кына эшлим дисәң,
Шулай бит ул кай чакта —
Әйләндерделәр куйдылар
Мәүлияны маякка!

Китте шуннан, китте кәмит,
Теләсәң ничек чыда...
Сыер белән бергә төшкән
Портретлары да чыга.

Районында, өлкәсендә
Мактыйлар да зурлыйлар,
Шагыйрьләре җырга сала,
Җырчылары җырлыйлар.

Журналистлар бигрәк җитез —
Көн аралаш киләләр,
Әйтергә тиешле сүзен
Сырлап кына бирәләр.

Мөнәвир бабай әйтмешли,
Уйламыйча языкны,
Мәүлия улакларына
Салалар бар азыкны;

Шуңа күрә, сыерлары
Су эчә дә тоз ялый.
Бүтәннәрнекенә ярый —
Салам чәйнәп боз ялый...

Гап-гади кызга да, ахры,
Ошап куйды дәрәҗә,
Күзләрне томалый бугай
Мактау — матур пәрәнҗә...


Әйләнә шулай карусель —
Күзләрне бәйләндерә,
Алга барган күк булса да,
Бер төштә әйләндерә...

Мәскәүләргә җиткәч кенә
Үзе һәм яхшы аты,
Мәүлиябызның беркөнне
Килде шушындый хаты:


«Ялганлап яшәргә бүтән
Түзәр хәл калмагачтын,
Чирәм җирдән кайтучыга
Кияүгә чыгып, качтым...









Мактау арта, сөт артмый, дип,
Йөргән чакта ми түнеп,
Кариб абый сыерларны
Күрсәтте ким иттереп;

Имеш, бүтәннәрне әйдәр
Минем уңай үрнәгем.
Гаеп — миндә, хәйлә корып
Йөрүләрен күрмәдем...»



Бу хәл ачылгач, бар кеше
Аһ итте, исе китте.
Ә мөдир Карибҗан исә,
Мыегын да селкетми:

— Кызмагыз әле, һәр эшкә
Сәбәп була бит аңа —
Кирәк иде чыгарырга
Колхозны орбитага.



Агымга каршы кем йөзсен —
Тормыш ул шулай бара,
Шома гына үтәләме
Берәр җаваплы чара?

Шулчак үгез, дәррәү кубып,
Екты да Карибҗанны,
Мөгез белән укол ясап
Дәвалый гарип җанны.

Ә халык карый да көлә:
— Тормыш ул шулай бара,
Шома гына үтәләме
Берәр җаваплы чара?

## ТУГЫЗЫНЧЫ ӘКӘМӘТ



Йөри торгач урамнарны
Урап буйдан-буена,
Җитеп килә үгезебез
Район сабан туена...

Бер-бер артлы алмашынып
Тора монда күренеш,
Халык куйган комедиядә
Рольләр болай бүленмеш;

Кем нинди һөнәргә маһир
Шул тирәгә сырыша,
Шул тармакта осталыгын
Күрсәтергә тырыша.

...Әнә кассир Сәфәргали
Башын чүлмәккә тыккан,
Җитешмәгән акчаларын
Тапмакчыдыр катыктан.

...Колхоз һәм авыл рәисе
Усал караш атыша:
— Минемчә!
— Юк, минемчә! — дип,
Икәү аркан тартыша.

...Ким белән Рим йөгерәләр
Кабып кукәйле кашык —
Күнеккән алар кукәйне
Фермадан өйгә ташып.

...Урынбасар Мөстакыймов
Капчык белән сугыша,
Директоры Яхъяевны
Түнтәрергә тырыша.

...Селькор Сабит гомер буе
Күрәшкән яклап чынны,
Бүген ул егып салмакчы
Әхмәтҗан ялганчыны;

Ә тегесе аяк чалды,
Һич кенә китми исе!
Ялганны «Чын» диеп раслый
Комиссия рәисе.

...Күзен бәйләгән танкыйтьче
Гайрәт чәчеп йөрмәктә,
Кизәнеп иман кусәкне,
Юнәлә буш чүлмәккә.

Тик шәһәрдән кайткан кунак
Эш чыгара алмады,
Әдәбият түгел шул ул
Сабан туе мәйданы!..

Күтәреп алды кусәкне
Парторг Гарифулла,
Снайпер була торып та
Тидермәс микән ул да?

«Уңга, уңга!» дип карадык,
Колак салмады агай,
Җәһәт кенә атлый торгач,
Китте чүлмәк ягалай.

Өстәл янына җитәрәк
Күтәрде ул кусәген...
...Тидерүен-тидермәвен
Соңрак әйтү исәбем.

Шау-шу булгач сизелмәгән,
Мәйданга кергән үгез,
Җәядән атылган уктай
Выжылдап килә мөгез.

Ялганны чын диюченең
Тавышы калтырады,
Тавышы калтыраса да
Күзлеге ялтырады:

— Бүгенгесе көндә миндә
Гаять мөһим миссия —
Сабан туен үткәрттерү
Буенча комиссия!

Ник бәйрәмнең шундый җитди
Програмын өзәсең,
Һәм дә нигә безнең белән
Киңәшмичә сөзәсең?

Әйтү шушы, сез, үгезләр,
Гомумиләштермәгез,
Ә гомумиләштерсәгез —
Гомуман дәштермәбез!

Үгез: «Сайрап кал»,— дигәндәй
Сүзе беткәнне көтте.
Көтте, иплән килеп төртте,
Өстәл аша сикертте;

Ялгышыпмы, чынлапмыдыр
Ни булса булды, шунда
Фәлән Фәләнев башына
Тамызды Гарифулла!

Әйтерсеңлә буш чүлмәккә
«Гөрс!» иттереп кундырды—
Бик еракларга кайтаваз
Озак яңгырап торды.

## УНЫНЧЫ ӘКӘМӘТ

Төшләрендә мөгез күреп
Кемнәрдер уяналар,
Бер туңып, бер эсселәнеп
Төн буе әйләналар.

Очрашкач та киңәшәләр:
— Бу үгезне, нишләргә? —
Күрә торып, тормышны бит
Әйләндерә махшәргә...

— Гафил булырга ярамас,
Кирәк тозак корырга,
Үгезлеген сылтау итеп,
Иткә озаттырырга!

Калды алар җиңел сулап:
— Әҗәл китте каһәргә!..
Көтү белән җибәрделәр
Үзен ерак сәфәргә.

Тузан йотып ничәмә көн
Бара колхоз терлеге,
Тояк астына коелып
Кала малның көрлеге.




Көч-хәл белән комбинатка
Җиткәч тә өстерәлеп,
Ун көн торалар капкага
Мөгез белән терәлеп.

Ашатмыйлар, шәп саклыйлар
(Кәгазьдә мал саны бар!)
Сөякләре төртеп тора —
Саны бар да җаны бар...


Комбинатның директоры
Бигрәк калын тиреле.
Капшап карамакчы үгез
Үзе барып тегене.

Килсә, күрә — начальникка
Көтүдәй чират тора,
«Кайчан кабул итәр диеп?»
Һәрберсе сорап тора.



Карлыгып беткән секретарь
Игълан итә һәркемгә:
— Өченчекөн язылганнар
Килсеннәр берсекөнгә.

Анысы дөрес, көтәр өчен
Шартлары тудырылган:
Газет-журнал, шашка-шахмат,
Домино куйдырылган;



Әрәм итмәсен вакытын,
Файда алып утырсын!
Башыңа төшкәч, нишләрсең,
Баш мәкалә укырсың...

Тик газета-журналларның
Сорама яңаларын —
Син чират көткән арада
«Хуҗа» укый аларын!

Мөгамәлә бик әйбәт тә,
Каеф кенә кырыла.
Чират бозарга базмыйча
Үгез кире борыла.



Берсекөн җиткәч секретарь
Тагын әйтте һәркемгә:
— Өченчекөн язылганнар
Килсеннәр берсекөнгә!

Башын айкый башлый үгез
Түземе тәмам бетеп.
Катлы-катлы ишекләрне
Мөгезе белән төртеп,

Кабинетка барып керә.
Күрә, утыра түрдә
Өстәлгә ябышып каткан
Такыр башлы бер түрә.

Шундый такыр, шундый якты.
Күренә күк үтәли...
Үтәли күренгән башын
Кәгазьләрдән күтәрми.

Булмый моны урыныннан
Һич кенә дә аерып,
Өстәлләре-ние белән
Ташлый үгез каерып!

Мәталдергәч бу түмгәкне
Юнәлә ул капкага.
Караса, бер юан корсак
Бик сәер атлап бара.

Бу нинди гуҗ тагын диеп,
Бара да бәреп ега —
Йөрәге, үпкә-бавыры
Әләгеп килеп чыга...

«Бетте!..» димсез? Ашыкмагыз,
Торып йөгерде, әнә;
Менә хикмәт, әллә инде
Ике йөрәкле бәндә?!

Җиңеләеп калгачтын ул
Йөгерә бар көченә —
Көн дә урлап ташый икән,
Бәйләп шулай эченә...

...Капкадан чыккачтын үгез
Беравык карап торды,
Карашларын күз күрмәгән
Бүтән якларга борды.

Алда яңа маҗаралар,
Яңа сәфәрләр көтә.
Бәлкем эле очратырсыз —
Сезнең якларга китә!

1964—1965.

# Укучылар сүзе

## Хатлардан юллар

Минем җиңгәм кече күнелле, олы җанлы кеше иде. Авылдашларым үзләренең үтенечләрен җиңгәмнең бер вакытта да кире какканы булмавын әле дә булса искә алып сөйлиләр.

Ләкин ул бик яшьләй үлеп китте...

Кешенең кешелеклелеге гомер буе онытылмый икән. Мин ятимнең бала чагы иде. Ләкин мин шундый олы җанлы җиңгәбез янында ятимлекне сизмәдем дә диярлек. Ә мин аңарга бары тик «каенсеңел» генә идем бит!

Бервакыт ул мине авыл башына алып барды да:

— Әнә, күрәсеңме офыктагы яктылыкны? Ул Казан утларының шәүләсе инде,— диде.

Без ул яктылыкка сокланып, озак карап тордык. Аннан соң да мин җиңгәмнең шул якка карап хәрәкәтсез торганлыгын бик еш күрә идем. Күңеленнән ул нәрсәләр кичергәндер — анысын әйтә алмыйм. Бәлки, ул шул утлар яктысында үзенең балалары да йөриячәк дип хис иткәндер, ә бәлки ул үзенең Казан больницасы утлары яктысында ятачагын күңеле белән сизгәндер (мин аны 5 нче шәһәр больницасыннан ярым үлек хәлдә авылга алып кайттым, ә 6 көннән соң ул инде үлде).

Әмма ул үз балаларының Казан утлары яктысында яшәгәннәрен күрә алмады шул. Аның өч кызы да хәзер Казанда. Берсе повар, берсе квалификацияле тегүче, ә өченчесе, минем кебек әнисен хәтерләми торганы, 9 нчы класста укый. Улы Әтнә РТСында столяр. Инде минем дә олы улым Казанда — 30 нчы ГПТУ да укый.

Мин еш кына кичләрен Казан утлары нурларын карап торам һәм шул вакытларда җиңгәм дә минем белән рәттән басып, Казан утлары балкыган якка карап торган кебек тоела.

Бәлки, Казан кешеләре үзләренең ут нурлары шәһәрдән йөз километрдан да артыграк ераклыкта күренгәнен белмиләрдер. Ә без беләбез, хәтта аның җылысын да тоябыз шикелле.

Менә нинди нурлы ул Казан утлары!

«Совет әдәбияты»н «Казан утлары» дип атап бик яхшы иткәнсез. Исән булса, җиңгәм дә бик шатланыр иде аңа.

Т. Сибаева, Әрчә районы,
Симетбаш авылы.

* * *

Равил Фәйзуллинның «Казан утлары» журналының 1965 елгы унберенче санында басылган «Нюанслар иле»н укыгач, мин үземдә гаҗәеп хисләр, тойгылар, уйлар дулкыны күтәрелгәнен тойдым. Алар матур да, моңлы да, искиткеч якты да булып, мине били бардылар. Бу әйберләр тәэсирендә озак вакыт калдым. Минә, гади кешегә,

автор бу әйберләрендә кешеләрнең уен еш-еш кисеп үтә торган фикерләрне тотып алып, аларны бер бөтен итеп төзегән һәм искиткеч җылылык белән әйтеп биргән кебек тоела.

Ф. ШАКИРОВА,
«Волга» тегү берләшмәсе эшчесе.

* * *

Г. Тукай, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Н. Исәнбәт, Һ. Такташ, С. Хәким, Х. Туфан, З. Мансур, З. Нури, С. Баттал, М. Кәрим, М. Сөндекле, Г. Афзал, Н. Арсланов, Г. Латыйп, Ә. Баянов, И. Юзиев, Ш. Галиев, Х. Камалов, М. Шабаев, Р. Гатауллин әсәрләрен бик яратам мин. С. Есенин һәм А. Твардовский, Р. Гамзатов һәм П. Хузангай әсәрләре дә миндә соклану тудыра. Соңлабрак булса да, Овидий, Петрарка, Шекспир, Гете әсәрләрен дә өйрәнә башладым.

Хәзер поэзия мәйданында шагыйрьләр нык алышалар. Анда иң көчлеләре генә җиңеп чыга. Гади һәм хикмәтле, көчле публицистик шигырьләр укыйсы килә.

Татар әдәбиятында сонетлар һәм шигъри романнар күбрәк тусын иде.

Әмма мин Р. Фәйзуллин кебек формализм белән шөгыльләнүчеләрне, әдәбиятта стиляга булып күренергә тырышучыларны яратмыйм. Эзләнү, минемчә, әдәбиятыбызның зур һәм матур традициясе нигезендә алып барылырга тиеш. Дөнья әдәбияты, рус һәм совет әдәбияты, шигъри энҗеләр тудыруга этәргеч була ала.

Казан университетында: шушы арада гына да Р. Фәйзуллин татар поэзиясен йөз еллар дәвамында үскән кадәр үстерде, дип сөйләүчеләр бар. Бу бөтенләй урынсыз. Татар поэзиясе, гомумән әдәбият, андый фальшька мохтаҗ түгел. Матур әсәрләр язу чыганагы да Фәйзуллиннарда түгел, халыкның үзендә.

Р. МӘСӘЛИМОВ,
Башкортстан, Караидел районы.

* * *

Без, Акъяр мәктәбе укытучылары, «Казан утлары» журналын яратып укыйбыз. Аның яңа исемен дә чын күңелдән хуплап кабул иттек. Чөнки бу матур яңгырашлы исем сөекле язучыларыбызны искә төшереп, күңелләргә рәхәт биреп торыр төсле. «Казан утлары» дию белән күңелгә кылт итеп татар халкының Г. Тукае, Г. Ибраһимовыннан башлап Һ. Такташы, М. Җәлиле, Ф. Кәриме йолдыз булып кабына. Шунда ук хәзерге татар совет әдәбиятының күренекле язучылары Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, А. Расих, М. Әмир, шагыйрьләребез С. Хәким, З. Нури, И. Юзиев һ. б. бер-бер артлы күңелләрдә тезеләләр. Менә шулай итеп, «Казан утлары» дигән сүз безгә күренекле исемнәрне хәтерләтеп тора.

Л. ХӘБИБУЛЛИНА,
Түбән өлкәсе, Акъяр авылы.

* * *

Мин «Казан утлары» журналын 1965 елдан укый башладым. Бу журналга язылуыма бик шатмын, үткән ел аның битләрендә Ш. Маннурның «Муса» романы басылды. Мин күптән инде Муса Җәлил башыннан үткән хәлләр турында белергә теләп йөри идем. Ләкин аның турында тик кешеләр сөйләве буенча гына сокланып тыңлый идем. Мусаның яшьләй безнең арадан югалуы кешеләр өчен авыр кичереш ул. Фашист тылында Муса кебек кыю хәрәкәт итүчеләр туган илгә әйләнеп кайтмадылар шул. Романнан күренгәнчә, Муса чын йөрәктән туган илен яраткан һәм аны яклаган. Үзе яшәү өчен генә көрәшмәгән, барлык совет халкы өчен янып яшәгән. Күп санлы совет әсирләре арасында дошманга каршы агитация эшләре алып барган, бөтен җаны-тәне белән туган илен яклаган. Шуңа күрә дә кешеләр күңелендә мәңге сакланыр ул.

Батыр яуда беленә, диләр. Хак сүз бу. Сугыш вакытында бары тик үз башын саклап калу өчен генә тырышып йөрүче куркак җаннар да булды бит.

Г. ШӘЯХМЕТОВА,
Свердловск шәһәре.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ӘДӘБИЯТ АТНАЛЫКЛАРЫ

Соңгы елларда, бигрәк тә 1965 елда, татар язучылары киң катлау укучылар, әдәбият сөючеләр белән бәйләнешне шактый көчәйттеләр. Урыннарга барып, хезмәт ияләре арасында чыгыш ясау, әдәбият яңалыклары, иҗат планнары белән укучыларны таныштыру матур бер традициягә әверелде. Татарстан язучылары республикабыз районнарында гына түгел, илебезнең бүтән шәһәрләрендә дә әдәбият, поэзия атналыкларында катнашалар. Мәскәү, Ленинград шәһәрләрендә татар әдәбияты һәм сәнгате атналыкларының зур уңыш белән үтүе инде укучыларга билгеле. Шундый атналыкларның берсе **декабрь аенда** Төмәндә һәм Төмән өлкәсе районнарында булды.

Бу атналыкка Ф. Хөсни, Ә. Исхак, А. Расих, З. Нури, Ш. Галиев, А. Гыйләҗев, И. Юзиев, М. Фәйзуллина һәм Т. Миннуллин катнашты.

Әдәбият атналыгы КПССның Төмән өлкә комитетының Зур залында ачылды. Анда Ә. Исхак һәм З. Нури чыгыш ясап, татар әдәбиятының бүгенге торышы, көрәнекле татар язучыларының иҗатлары турында сөйләделәр, яңа әсәрләрен укыдылар. Укучылар белән очрашулар, әдәби кичәләр Төмән шәһәренең Санитария мәгарифе йортында, Тоболь шәһәре Культура йортында, шул ук шәһәрнең 15 мәктәбендә, Тоболь районы Ленин юлы колхозы клубында, Вагай районының Тат. Вагай сигезьеллык мәктәбендә, Первухин исемендәге совхоз клубында, Тоболь районы Төрби мәктәбендә һәм клубында, Яркәү районының Бурбар мәктәбендә һәм Куйбышев исемендәге колхоз клубында, Төмән районының Акъяр мәктәбендә, Червишевский совхозы клубында, Шыкча авылы мәктәбендә һәм клубында, Ялутор районының Аслан урта мәктәбендә, шул ук авылның клубында, Киндерле авылы мәктәбе һәм клубында, Ямбай урта мәктәбендә, Төмән шәһәренең 10 номерлы китапханәсендә, Урай шәһәре нефтьчеләре янында һ. б. урыннарда зур уңыш белән үтте. Татарстаннан еракта яшәүче татар хезмәт ияләре яраткан язучыларын зурлап каршы алдылар, кунак иттеләр һәм аларга яңадан яңа иҗат уңышлары теләделәр.

* * *

Шул ук **декабрь аенда** татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгы Пермь өлкәсенең Барда районында булып үтте. Район Культура йортында, авыл клубларында, китапханәләрендә, мәктәпләрендә үткәрелгән әдәби кичәләргә, очрашуларга, китап укучылар конференцияләренә Г. Әпсәләмов, Н. Арсланов, композитор З. Хәбибуллин, Г. Латыйп, Ә. Маликов һәм яшь шагыйрь Р. Гатауллин катнашты.

* * *

Чирмешән районында **10 декабрьдан 17 декабрьга** кадәр булган татар әдәбияты атналыгы КПСС райкомы бинасында ачылды. Әдәбият атналыгын үткәрүгә катнашкан Г. Минский, И. Гази, Г. Бакиров, С. Баттал, Р. Төхфәтуллин, С. Шакир һәм Ш. Шаһгалиев анда районның партия һәм совет работниклары белән очраштылар, район хезмәт ияләренең уңышлары белән таныштылар, әдәбият яңалыклары турында сөйләштеләр. Аннары XXII партсъезд исемендәге колхозда Муса Җәлил исемендәге Культура Сарае ачуга багышланган тантаналы кичәдә алар үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, бу зур культура учагы ачылу уңае белән колхозчыларны чын күңелдән котладылар.

Шул ук колхозның терлекчеләре, Лашман, Бәркәтә урта һәм Югары Чыгыдай, Үтәмеш сигезьеллык мәктәпләре укытучылары һәм укучылары белән очрашулар, Орджоникидзе исемендәге, «Бүләк», Жданов исемендәге колхозларның клубларында уздырылган әдәби кичәләр бик җанлы үтте.

Тукай исемендәге колхоз клубында И. Газиның «Онытылмас еллар» романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Әдәби конференцияләр шулай ук Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым» (Бәркәтә урта мәктәбендә), Г. Бакиров (Югары Каменка авылы клубында) китаплары буенча да үткәрелде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

**22 ноябрьда** республиканың нефть районнарыннан Әлмәткә семинарга җыйналган мәктәп директорлары алдында Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин, Г. Афзал, С. Сөләйманова



Язучыларны Норлат районының «Дружба» колхозында каршылау. Колхозчылар исеменнән ипи-тозны язучы Г. Минскийга Мостафа ага Алиев тапшыра.

үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Соңыннан әдәбият турында фикер алышу булды, сорауларга җаваплар бирелде.

* * *

Гариф Ахунов **ноябрь ахырында** Баулы районында яшәүче авторлар белән индивидуаль семинар үткәрде. Семинарда яшь хикәячеләрдән Мөсәгыйть Хәбибуллин, К. Гарифуллин һ. б. иптәшләрнең әсәрләре укып тикшерелде. Район газетасында басылган шигырьләр, хикәя һәм очерклар турында фикер алышу оештырылды.

* * *

**30 ноябрьда** Әлмәттәге 10 номерлы урта мәктәптә, тугызынчы класс укучылары катнашында, поэзия кичәсе үткәрелде. Кичәгә чакырылган Әдип Маликов шигырьләр белән чыгыш ясады, әдәбият турында әңгәмә үткәрде.

* * *

**Декабрь башында** Әлмәт язучыларыннан Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин, С. Кальметов, Г. Ахунов, Г. Афзал Сарман районында булып кайттылар. Алар Сарман район культура йортында, «Татарстан» колхозында һәм Сарман урта мәктәбендә район хезмәт иyяләре, колхозчылар һәм укучылар белән очраштылар. «Ленинчы» газетасы редакциясендә, Әлмәт язучылары катнашында, индивидуаль семинар үткәрелде. Семинарда «Җиңүче» колхозы парткомы секретаре Дамир Гарифуллинның кулъязма хәлендәге шигырьләр җыентыгы укып тикшерелде, авторга киңәшләр бирелде.

Язучылар шулай ук урындагы радиодан үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

**10 декабрьда** Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге нефтьчеләрнең Техника йортында зур әдәби-музыкаль кичә үткәрде. Кереш сүз белән Ә. Маликов чыгыш ясады.

Кичәдә Гариф Ахунов «Юлдаш» исемле яңа романыннан, Сәет Кальметов яңа пьесадан өзекләр, Әдип Маликов, Гамил Афзал, Сажидә Сөләйманова яңа шигырьләрен укыдылар.

Композитор Масгут Имашев Әлмәт авторларының сүзләренә язган көйләрен башкарды. Әлмәттә яшәүче үзешчән композитор Зәки Газимжанов иҗат иткән җырларны Әлфия Гайфиева, татар композиторларының көйләрен музыка училищесы укытучылары Ильяс Шәрипов һәм Диләра Алимбек иптәшләр зур осталык белән башкардылар.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР СЕМИНАРЫ

**Декабрьда** Татарстан язучылар союзы идарәсе Казанда яшь язучылар семинары үткәрде. Семинарга яшь язучылардан ВЛКСМның Саба район комитеты секретаре З. Шәйхетдинов, шул районның 1 Май колхозы умартачысы Р. Шәрифуллин, Алабуга авыл хуҗалыгы профтех мәктәбе укытучысы инженер Ф. Шәехов, Минзәлә районы Ургыды авылы колхозчысы Ф. Әгъзәмов, Сарман районы Яңа Әхмәт авылы тимерчесе Ә. Фазлиев, Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия училищесы укучысы Э. Шәрифуллина, Октябрь Норлаты район газетасы сотрудниgы Р. Закиев, Тәтеш районы «Авангард» газетасы сотрудникы Н. Хәйретдинов, «Татарстан яшьләре» газетасы сотрудникы Д. Сенгатов һәм К-



Язучылар Норлат шикәр заводында.

зан дәүләт педагогия институты студенты М. Гаскәров чакырылды.

Семинарга катнашучылар филология фәннәре кандидаты, тәнкыйтьче Х. Хәйринең «Татар әдәбиятының бүгенге торышы һәм алда торган бурычлар», Н. Исәнбәтнең «Халык иҗаты һәм язучы» дигән темага укыган лекцияләрен яратып тыңладылар. Ф. Хөсни иҗади осталык турында алар белән әңгәмә үткәрде.

Тәҗрибәле язучылардан Х. Туфан, А. Расих, М. Садри, Г. Хуҗи, Ш. Галиев, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов һ. б. лар яшь язучыларның әсәрләрен укып, аларның уңышлы һәм кимчелекле якларын күрсәттеләр, файдалы киңәшләрен әйттеләр.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Казан шәһәренең Дербышка поселогы культура Сараенда Муса Җәлил истәлегенә багышланган әдәби кичә үткәрелде. Кичәгә катнашучыларга филология фәннәре кандидаты Н. Юзиев герой-шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында сөйләде. Н. Исәнбәт, А. Расих, Ә. Еники, А. Гумеров, К. Фәсахов, А. Сәләхетдинов Муса Җәлил турында истәлекләр сөйләделәр, аңа багышлап язган әсәрләрен укыдылар.

* * *

Г. Әпсәләмов Казан гарнизоны солдатлары һәм офицерлары белән очрашып, аларга хәрби темага иҗат иткән әсәрләренең язылу тарихы, татар әдәбиятының бүгенге торышы турында сөйләде һәм киләчәккә планнары белән уртаклашты.

* * *

Гази Кашшаф Әлмәт нефтьчеләре янында булып кайтты. Ул анда алар белән герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормышы һәм батырлыгы турында әңгәмәләр уздырды.

* * *

Мәскәүдә Атеистлар йортында Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы буенча китап укучылар конференциясе үткәрелде. Конференциягә автор үзе дә катнашты, фикерләрен белдереп чыгыш ясаган әдәбият сөючеләргә рәхмәт әйтте, романның язылу тарихы турында сөйләде, сорауларга җавап бирде.

* * *

Язучы Э. Касыймов декабрь башларында Алабуга районы Камай авылы клубында укучылар белән очрашты һәм «Дин турында халык ни әйткән?» дигән темага әңгәмә уздырды. Әңгәмә җанлы үтте. Соңыннан Алабуга педагогия институты студентлары зур концерт бирделәр.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬ

Галиасгар Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры Ә. Баяновның «Күзләре нинди иде...» исемле пьесасы буенча эшләнгән яңа спектакль күрсәтте.

Спектакльдә баш рольләрдә ТАССРның атказанган артистлары Ш. Биктимиров, Г. Фәтхуллин, артистлардан Н. Ихсанова, Д. Нуруллина, Г. Исәнгулова, Б. Әшрәпов, К. Газизова һәм Х. Җәләлов уйныйлар. Спектакльнең режиссеры — РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Ш. Сарымсаков, художнигы — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе М. Сутюшев, музыкасын ТАССРның халык артисты А. Ключарев язган.

## АТКАЗАНГАН КОЛХОЗЧЫЛАРГА «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ

Республикабыз районнарында һәм аерым авылларында «Казан утлары» журналына язылу торган саен киңәя бара

Минзәлә, Актаныш һәм Әгерҗе районнарында колхоз идарәләре алдынгыларны «Казан утлары» журналына еллык подписка белән бүләкләүне практикага кертә баралар.

Мамадыш районы колхозларында колхоз эшендә фидакарь хезмәтләре белән танылган кешеләргә **Атказанган колхозчы** дигән мактаулы исем бирелә башлады. Бу мактаулы исем бирелгән колхозчылар ел саен санаторийларга путевкалар, район газетасына һәм «Казан утлары» журналына еллык подписка белән бүләкләнә.

Мамадыш районында бу мактаулы исем «Чулпан» колхозы тимерчесе Яхъя ага Мусинга, колхозчы Вагыйзь ага Гыйззәтуллинга, «Кызыл флаг» колхозы члены Хәсән ага Мәхмүтовка бирелде.

## ТАТАРСТАН МУЗЕЕНА 70 ЯШЬ

Узган елның **декабрь** аенда республикабыз җәмәгатьчелеге Татарстан АССРның дәүләт музееның 70 еллыгын билгеләп үтте. Шул уңай белән музей гыйльми советының юбилей сессиясе үткәрелде.

Гыйльми совет сессиясе **9 декабрьда** Казан галимнәр һәм студентлар йортында ачылды. Беренче көнне музей директоры В. М. Дьяконовның музейның 70 еллыгы турында доклады тыңланды. Сессия өч көн буена дәвам итте. Анда Л. Сабитова «Музей һәм хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү», А. Мирлин «Музей фонды — халык байлыгы», К. Синицина «Музейда фәнни-тикшеренү, җыйнау һәм нәшрият эшләре», Е. Халикова «Археология буенча яңа экспозицияләр», Ф. Вагазова «Музей һәм татар әдәбияты тарихын өйрәнү», С. Хасанова «Музей һәм тарихи истәлекләрне саклау» һ. б. темаларга докладлар укыдылар.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ КЛУБЫНДА

**26 ноябрьда** Татарстанның атказанган артисткасы С. Садыйкова җырларына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Танылган җырчыларыбыздан РСФСРның халык артисты Ф. Насретдинов, Татарстанның халык артисткасы Р. Билялова, Татарстанның атказанган артисты И. Шакиров, Татар дәүләт филармониясе солисткасы Д. Сиражетдинова Сара Садыйкованың татар шагыйрьләре сүзләренә язылган җырларын башкардылар.

Татарстанның атказанган артисты Ф. Биккенин, баянчылардан Р. Ибраһимова, М. Әхмәдиев һәм пианист Н. Алексеев Сара Садыйкова көйләрен уйнадылар. Кичә җанлы, матур үтте.

# Хөсни Кәрим

**27 декабрьда, озакка сузылган каты авырудан соң, иң карт әдипләребездән берсе, СССР Язучылары Союзы члены, 1919 елдан бирле КПСС члены, персональ пенсионер Хөснетдин Минһаҗетдин улы Кәримов (Хөсни Кәрим) үлде.**

**Хөсни Кәрим 1887 елның 9 июнендә элекке Уфа губернасының Тумырҗа авылында, ярлы крестьян семьясында туып үсә. Тормыш шартлары кысынкылыгы аркасында, ул 14 яшеннән Самара-Златоуст тимер юлы төзелешенә кара эшче булып керә.**

**1911 елда зур кыенлыклар белән «Галия» мәдрәсәсен тәмамлап чыга, һәм Царицынга барып, андагы реальное училище каршындагы комиссиядә экстерн тәртибендә сынау үтеп, учитель исеме ала. Яшь учитель Астраханьга бара һәм андагы татар-рус школасында укыта башлый. Астраханьдагы газеталарның берсендә басылган фельетоны өчен полиция эзәрлекли башлагач, ул Уфага күчеп китә. Бөре районы китапханәләренең берсендә мөдирлек итә, төрле тарихи-политик һәм фәнни темаларга лекцияләр укый.**

**Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң өяз халык мәгарифе комиссариатында инспектор булып хезмәт итәргә тотынган Хөсни Кәрим Бөре өязендә Совет органнарын оештыру буенча актив эшли. 1919 елда ул Коммунистлар партиясе сафына керә һәм шул вакыттан бирле бөтен тормышы белән партия-совет эшенә бирелә.**

**Хөсни Кәрим, педагоглык эшчәнлеге белән бергә, зур җәмәгать эше дә алып барган кеше.**

**Хөсни Кәримнең әдәби-иҗат эшчәнлеге 1907 елларда, «Галия» мәдрәсәсендә укыган чагында башлана. Башта ул вак-вак хикәяләр, шигырьләр яза. 1910 елдан башлап Хөсни Кәримнең татар телендә чыга торган газета-журналларда 175 тән артык хикәя, очерк, шигырь, новелла һәм публицистик мәкаләсе басыла. Аның аерым китап булып чыккан җыентыкларының саны дистәгә якын.**

**Хөсни Кәримнең заманның актуаль темаларына багышлап язылган әсәрләренең аеруча зурларыннан «Җан исәбе алганда», «Калмык сахрасында» һәм «Ертылган приказ» хикәяләрен күрсәтергә мөмкин.**

**Хөсни Кәрим 1949 елда пенсиягә чыгарга мәҗбүр булды һәм әдәби-иҗат эшен дә авыру хәлендә алып барды. Соңгы елларда ул «Истә калганнардан» исемле мемуар язмалар өстендә эшли иде.**

**Партиябезгә, халкыбызга чын күңелдән бирелгән күркәм табигатьле, саф йөрәкле өлкән язучының якты истәлеге күңелләребездә озак сакланыр.**

*БЕР ТӨРКЕМ ИПТӘШЛӘРЕ.*

## Алдагы саннарда:

**И. Гази.** Канатланыр чак. Повесть.
**Г. Гобәй.** Корьән серләре. Повесть. Дәвамы.
**С. Баттал.** Чирмешән якларында. Шигъри роман.
**С. Сөләйманова.** Язылмаган җырлар. Поэма.
Яшь шагыйрьләр иҗаты.
**Г. Ахунов, Г. Бакиров** очерклары.
**С. Кальметов.** Бер пәрдәлек комедия.
**Д. Гыйймранова.** Актерлык осталыгы һәм бүгенге таләпләр. Мәкалә.
Г. Тукайның тууына 80 ел тулуга карата мәкаләләр, истәлекләр.
Г. Тукайның яңа табылган хатлары.
Юмористик хикәяләр, шигырьләр.
Интермедияләр, эпиграммалар.
Укучылар сүзе.
Хатлар.
Җырлар.

Җаваплы редакторы Рафаэль Мостафин.
Редколлегия: Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники,
Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский,
Сибгат Хәким, Нил Юзиев.

Производствога бирелде 14/XII-1965 ел. Басарга кул куелды 20/I-1966 ел. ПФ 07008. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 36800 экз. Заказ № Л-1603.
Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1966 ел.

«КАЗАН УТЛАРЫ» — Бөтенсоюз каталогына кертелгән журнал, аңа Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә һәм «Союзпечать» агентлыкларында чикләүсез язылырга мөмкин.

Әгәр сез журналга язылырга теләгәндә «Союзпечать» органнары теге яки бу сәбәп белән тоткарлык ясасалар, түбәндәге адрес белән редакциягә хәбәр итүегезне сорыйбыз:

*г. Казань, ул. Баумана, 19, Дом печати, редакция журнала „Казан утлары“.*

ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ БӘЯСЕ:

Елга — 4 сум 80 тиен.
6 айга — 2 сум 40 тиен.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73210

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал

КАЗАН УТЛАРЫ

(Огни Казани)

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ